Р. Фәхреддиннең «Асар» китабында (Т. 2, 139 б.) «Бөгелмә өязендәге Камы Исмәгыйль авылы имамы Гайсә бине Габделмәҗиднең... 80 яшеннән узып 1872 елда мәрхүм булуы әйтелә. Бу кеше кайсыдыр елда, «Казан-Уфа юлы өстендә булган Мактама авылында мәдрәсә оештырып, шәкерт җыеп дәрес белән шөгыльләнде. Соңрак, ни өчендер, шәкертләре таралып бетте, һәм ул, үз авылына кайтып, рәсми рәвештә имам булды...»

Әхсән Зәйнелгабидин улы (1824–1877) Бөгелмә өязендәге Микулинская волостена кергән Кодаш авылында 1860 елдан имам. Ир туганы Мөхетдин бине Зәйнелгабидиннең улы Гатаулла (1850) Бөгелмә өязендәге Спиридоновская волостена кергән Яңа Иштирәк авылының беренче җәмигъ мәчетендә 1877 елдан имам-хатыйп.

Азанчы Һидаятулла Зөбәеров 1850 елларда Мактамадан Бөгелмә өязендәге Варваринская волостена кергән Урмышлы авылына күчеп киткән. Мактаманың гади крестьяны Сафа Сәйфелмөлековның улы Мөхәммәтвәли Мөлеков (1888) – Бөгелмә өязендәге Түбән Үтәмеш авылында имам. Совет чорында үз вазифасыннан ваз кичкән.

Шакирҗан Хәсәнша улы (1892) – совет чорында Казандагы бишенче мәчетнең мөтәвәллие. Беренче мәртәбә аны 1935 елда «дини төркем оештыручы, дини дәгъватчы» дип кулга алганнар. Дәлилләр җитмәү сәбәпле, иреккә чыгарылган. Шакирҗан хәзрәтне 1937 елның декабрендә янә кулга алалар. Бу вакытта ул матбугат йортында караул торып тамагын туйдырган. ТАССРның НКВД өчлеге 1938 елның 6 гыйнварендә 58–10 (2 бүл.) маддәсе белән кабат гаеп тагып, аны 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерена хөкем итә («пораженческая, повстанческая агитация, провокационные слухи о войне»). Шакирҗан хәзрәт динне генә түгел, сәясәтне дә яхшы белгән. «Допрос» протоколларында мондый юллар бар. Ул болай дигән: «Халык тагын да дини булсын өчен, дингә ышанган халык бервакытта да социализм элементларын кертмәскә тиеш». Кировны үтергәннән соң, имештер: «Ике-өч грузин белән бер дистәләгән яһүдләр миллион кешеләрнең башын әйләндерделәр. Кировны да урыс кешесе булганы өчен үтерделәр, чөнки урынына, яһүд яки грузинны утыртырга кирәк», – дип сөйләп йөргән. Ул Зөя (Свияжск) утравының 5 нче колониясендә 1943 елның 6 октябрендә вафат. 1957 елда гаепсез дип акланган (С.С. Баһаветдинова китабын файдаландык).

Габдерәүф Хәмидуллин – Бөгелмә өязендәге Кодаш авылында имам-хатыйп. Совет чорында Урта Азиягә китеп, кулга алынудан котылган. Сугыштан соң Бөгелмә шәһәрендә мулла булып йөргән, дигән хәбәрләр бар.

Әлмәт районының совет чоры документларында Түбән Мактама һәм башка авыллар

Үзебезнең карамакта булган бер документта Әлмәт районы башкарма комитеты рәисе Фазлыев ТАССР Югары Советы президиумының мәгълүмат группасына 1939 елның апрель аенда яшерен хат юллый: «Альметьевский РИК по запросу о состоянии использования молитвенных зданий сообщает: по району ранее всего имелось мечетей – 14,

церквей – 2, из них закрытых до 1935 г. мечетей – 15, с 1935 по 1939 гг. мечетей – 8, закрытых в 1939 г. мечетей – 6, церквей – 1, в настоящее время действующих – 16. Списки прилагаются». Түбәндәге исемлектә 1935 елга кадәр ябылган мәчетләр күрсәтелә. Чупай, Миңлебай, Мәмәт, Бигәш, Түбән Мактама, Сөләй авылларының һәм Ак Чишмә, Болгар поселоклары мәчетләренең колхоз клубларына әйләндерелеп файдалануы белдерелә. Әлмәттәге ике мәчеттә, тагын Бикәсаздагы һәм Камы Елга, Гөлбакча поселокларындагы мәчетләрдә совет мәктәпләре ачылган. Яңа Кәшер белән Колшәрип авылларының ябылган мәчетләре фельдшер пункты итеп үзгәртелгән. Зурырак авылларда берничә мәчетләр булуын истән чыгармыйк, шуңа күрә алар башка исемлекләрдә дә яңадан күрсәтелә, мәхәлләләре аерып әйтелмәгән. 1935–1939 елларда мәчетләре ябылып колхоз клубы ясалган авыллар Шарлама (16.09.1935), Тайсуган (02.06.1936), Миңлебай (02.06.1936), Габдрахман (02.06.1936). Бишмунча мәчетенең (31.01.1939) берсендә фельдшер пункты, Кошәрипнекендә (02.01.1937) китапханә ачыла (»изба читальня»).

Ябылган дин йортларының ТАССР Югары Советы боерыгы белән рәсмиләштерелмәгәннәренең дә (оформить ителмәгән, язылмаган) аерым исемлеген төзегәннәр. Мәчетләр авыл халкының соравы буенча гомуми җыелышларда кабул ителгән карар нигезендә ябылганнар. Әлеге «мөһим эшләр»не җирле совет һәм Әлмәт РБК әгъзалары башкарган. Шундый ябылган мәчетләрдән Габдрахман (17.3.1939), Нәдер (25.3.1939), Кәшер (өченче мәхәллә мәчете 25.03.1939, икенче мәчете 07.02.1939, мәхәлләсе күрсәтелмәгән), Кичүчат (13.03.1939) авыллары һәм Бикмурас поселогы (25.10.1937). Документларда Әлмәт районы башкарма комитеты яптырган мәчетләрнең вакыты бер төрле булса, шул ук мәчетләрнең ябылуын Югары Совет раслаган указларда икенче вакыт күрсәтелгән. Бер мәчет ике мәртәбә ябылган икән дип уйлап була. Мәчетләрнең ябылуы турында ике юридик документ әнә шулай төзелгән. Ул инкяр итеп булмастай канунга әйләнгән.

Әлмәт РБК рәисе Фазлыевның «по району ранее всего имелось мечетей 14», а «в настоящее время действующих 16» дип язган сүзләренә игътибар итсәк мондый фикер туа. Мәчетләрнең кайберләре ябылып, яңадан ачылганнар, аннан соң озак та тормаган мәчетләрне янә ябтыру очраклары да булган икән. Районның 14 авылында эшләүче мәчетләр исемлегендә: Чупай, Мәмәт, Әлмәт, Бишмунча (ике мәчет), Кичүчат, Кәшер, Бигәш, Түбән Мактама, Югары Мактама, Тайсуган,, Нәдер, Камы Исмәгыйль (ике мәчет), Урсалыбаш авыллары һәм Ак Чишмә поселогы. Әле генә булып үткән коточкыч репрессияләрдән соң Әлмәт районында шуның хәтле мәчет эшләвенә ышануы да авыр. Эшләсә дә, анда

елына берничә тапкыр дини бәйрәмнәрдә генә җыелганнардыр, мөгаен. Дини оешмалар совет тарафыннан катгый күзәтү астында торган, мәчетләрдән зур салымнар түләткәннәр. Яшь комсомоллардан «Алласызлар оешмасына» («Союз воинствующих безбожников») язылучылар да дин тотучыларга кискен рәхимсезлек белән караганнар. Шундый шартларда беркемнең дә күңелендә мәчеткә бару теләге уяна алмаган, билгеле Югары Совет президиумының Әлмәт районындагы мәчетләр турында хәбәр җибәрүне таләп итүе дә очраклы хәл түгел. Республика мөселманнарының дини эшчәнлеген тулысынча туктатып, булган мәчетләрнең соңгыларын да ябып, биналарын колхоз мәнфәгатьләре өчен талап алу хакында кайгыртканнар булса кирәк. 1940 елда ябылган Түбән Мактама мәчете моның ачык мисалы. Фазлыев биргән докладттан соң калган барлык мәчетләр, мөмкин булганча оформить ителеп, 1939 елның ахырында ябылып беткән диярлек. Документлар буенча районда 1940 елда соңгы ике мәчет ябылган, Нәдер авылының өченче мәхәллә мәчете 1940 елның 1 февралендә ябылса (протокол саны 5-737), Түбән Мактама авылының беренче мәхәллә мәчете август аенда ябылган дигән идек. Гомумән, Әлмәт районында 1941 елның сентябренә бер генә мәчеттә дә дини вазыйфалар башкарылмаган. Җирле түрәләр өстән килгән партия бурычларын әнә шулай бер карусыз үтәгәннәр.

Бигәш мәчете

Әлмәт һәм Бигәш авыллары 1953 елдан Әлмәт шәһәре биләмәсендә калды. Бигәш авылының да үзенә генә хас милли үзенчәлекләре, көнкүреше, бай тарихы бар. Монда абруйлы мәдрәсәләрдә гыйлем алган дин әһелләре тормышның көн кыйбласын, барыр юлны дөрес билгеләп, халыкны хак дингә күндергәннәр. Бигәшлеләр бик тә дини халык булган. Бер генә мисал: әби патша Екатерина авыл аша юл, күпер салдырмакчы була, ләкин муллалар сүзеннән чыкмаган авыл халкы моны чукындыруның бер галәмәте дип аңлый һәм шуңа җан-фәрман каршы төшә. Бабаларыбыз хәтта юллар, төрле корылмалар төзүне дә дингә, милләткә каршы эш итеп кабул иткәннәр һәм үзләренчә хаклы да булганнар. Алар урыс патшаларыннан явызлыктан башка нәрсәгә өмет итмәгәннәр.

Авылга якынча 1725–1746 елларда чукындырудан качыптыр, беренче булып Бигәш б. Дияш б. Тугаш дигән кеше Оренбург губернасы Минзәлә өязеннән күчеп килгән.

Бигәштә ике мәчет эшләгән. Кайбер мәгълүматларда авылда мәчет 1719 елда ук булган дип сөйләнелә. 1792 елдан мәдрәсә ачылган. Мәдрәсәне XX гасыр башында Дәүләтша Якупов һәм Әбелкасыйм Мансуровлар җитәкләгән. Әбелкасыйм хәзрәтнең 1907 елда Бөгелмә өязе земский собраниедан мәктәпне тоту өчен 200 сум сорап язган гаризасы тарих бит-

ләренә теркәлеп калган. 1859 елдан авылда манаралы мәчет һәм 5 вакыт намаз уку мәчете дә (манарасыз мәчет) булган. Беренче мәхәллә мәчете 1801 елдан билгеле дигән архив документлары да бар. Бу искесе урынына яңа мәчет салу вакытыдыр, мөгаен. Шул мәчет 1829, 1863, 1874, 1899 елларда яңартылып төзелгән. 1905 елдан мәчетнең яңа мәктәбе дә эшләгән. Анда 1843 елда ук мәдрәсә эшләгәнлеге дә билгеле. Икенче мәчет становой пристав әмере белән 1902 елда төзелеп бетә. Мәктәбе 1903 елда ачыла. Авылда Дәүләтша бабай Якупов балалар укытып мөдәррис булып йөргән. Бигәш бабай нәселеннән Фәхрулла бай Хөснуллин мәчет төзелешләренә бик булышкан, төзү документлары да аңарда сакланган.

Әлмәт волостена кергән Бигәштә 1910 елда 385 йорт, 1028 ир-ат, 1027 хатын-кыз, 2625 дисәтинә уңайлы һәм 290 уңайсыз җирләр, 2 мәктәп, су тегермәне, Зәй елгасы булган. (Самара губернасының халык яши торган урыннары исемлеге. Самара, 1910 ел).

Бигәштә Мөхәммәтвафа хәзрәт Гобәйдуллин (1791–1859) Тайсуган мәдрәсәсендә укып 1821 елдан биш вакытлы намаз уку мәчетендә мулла. Фәридетдин Габдрәшит улы Муллин (1808-1880) Бигәш авылына 1836 елда имамлык өчен хокук ала. Әтисе Габдрәшит хәзрәт (1747–1830) Колшәрип һәм Шөгер (Лениногорск районы) авылларында имам мөдәррис булган. «Төхфәтел-мөлек», «Ширгател-Ислам», «Шәрхе Җами» кебек китаплар язган. 1826 елдан авылда Тайсуган мәдрәсәсендә укыган Хәмидулла хәзрәт Вәлитов (Камы-Исмәгыйль авылыннан, 1778–1872) мәзин булып йөргән. Фәридетдиннең улы Нуриәхмәт Муллин (1848–1918) Түбән Чыршылы авылында Габделфәттах хәзрәт мәдрәсәсендә укып 1876 елдан имам хатыйп.

Мотыйгулла Төхфәтулла улы Мансуров (1830–1880, Чистай өязе Кармыш авылыннан) 1863 елдан беренче мәхәлләдә мулла. Уллары Әбелкасыйм (1871–?) белән Мәүләви-Шәриф тә ((1877–?) Бигәш муллалары. Әбелкасыйм Чистайда Закир хәзрәт мәдрәсәсендә, Казанда Габдулла Апанаев мәдрәсәсендә укыган. 1905 елдан ахун дәрәҗәсендә йөргән. Ике хатын белән яши. Икенче хатыны Кичүчат мулласы Фәхреддин (Риза Фәхреддиннең әтисе) кызы Маһирә (1878–1915). Балалары Габдерәшит белән Гариф Совет властеннән кимсетелеп яшәгәннәр. Мәүләви-Шәриф тә Чистайда һәм Казанда дин сабагы алган. 1903 елдан икенче мәчеттә имам хатыйп мөдәррис. Җәмәгате Галимә абыстай вафат булгач, үзеннән 26 яшькә кече булган Өммегөлсем Мөхәммәтҗан кызына никахлаша. Алты кыз балалары туа. Мәүләви-Шәрифне 1930 елда совет дошманы дип авылдан сөрәләр.

Корбангали Габдерафыйк улы Баһаутдинов улы Зәй-Каратай авылыннан. Корбангали (1844–1923) 1871 елда мәзин булып Бигәшкә килгән.

Мотыйгулла Мансуров мәдрәсәсендә укып мөгаллим, имам ярдәмчесе вазыйфаларын ала. Шулай ук авыл имамы Хөснетдин (Хөснелгата) Идиятуллин (1870 елда туган) үз вазыйфасына 1914 елдан билгеләнә. Мөхәммәтҗан Габдулла улы Габбасов (1876 елда туган) 1903 елдан мөгаллим.

Зөфәр Гыйрфанов 1894 елда Азнакай районы Чалпы авылында туган. 1921 елдан беренче мәхәлләдә имам. Совет чорында муллалыгын ташлап туган ягына киткән. Бу куркынычлы 1930 елларда Хаҗи хәзрәт Вилдановны кулак мулла дип авылдан куалар. Ул урман кисүдә эшләп Бөгелмәдә чирләп үлә. Дүрт баласын җәмәгате Факия абыстай тәрбияләп үстерә. Хаҗи хәзрәт Әстерханда укыган. Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан. Хатыны Сәйдә абыстай Тайсуган мулласы Мостафа кызы. Бигәштән Нурмөхәммәт Хәйретдинов (1889 елда туган) Чирмешән районы Түбән Чыгтай авылы мулласын 1930 елда кулга алып биш елга иреганнән мәхрүм итәләр. Совет чорында Бигәштә Һидаятулла Хәбибулла улы (Тайсуган мәдрәсәсендә укыган), аның улы Шакирҗан, мөтәвәлли Сәлман Кәлимуллин, Мортаза Мөдәррисов, Шәйхаттар бабайлар муллалык иткән. Хөсәен Сибгатуллин, Миннекәрәм Шәйдуллин, Сабира Хөснетдинова, Салих Мөхәммәтҗанов һ.б. үз өйләрендә намаз укыталар. Тарихи язуларда 1930 елга кадәр үк имамнар Мәүләви Мансуров, Хаҗи Вильданов, азанчылар Мөхәммәтҗан Габдуллин, Гата (?) Рәфыйков дини мәгърифәтчелектән баш тартканнар диелә.

Беренче мәхәллә мәчете түбәсе калай белән ябылган алты почмаклы бина. Ул 1939 елда ябылган. Анда мәдәният йорты ачыла. Мәчетне ябу актына район башкарма комитеты вәкиле С.Шәйдуллин һәм РОНО мөдире Абдуллин кул куйганнар. Икенче мәчет бинасыннан файдалану өчен мөселманнар белән килешү 1926 елда төзелгән. Бу вакытта анда рәсми дин әһеле булмаган. Ул 1939 елда ябылып мәктәп итеп файдаланылган. Бу карарга Динмөхәммәтов, Якуповлар кул куйган.

1994 елның сентябрендә Бигәштә 6 нчы мәхәллә оеша. Рәисе итеп Җәмил Сәхапов, имам итеп Хөсәен Сибгатуллин сайлана. Соңыннан мәхәллә имамы итеп Әбүзәр хаҗи Хәсәнов билгеләнә. Тырышсалар да элекеге мәчет урынын алалмаганнар. Мәчет төзү эшенә Ильяс Кашапов, Җитез Сәхапова, Әбүзәр хәзрәт, Мансур Габдуллиннар һәм күп санлы бигәшлеләр, предприятие җитәкчеләре алына. Мәчет проектын Самдун Фәрхетдинов ясый. Проектны Марсель Шакиров әзерләп бетерә.

1996 елның 26 октябрендә мәчет нигезенә таш салына. Мәчет диварларын таҗик егетләре күтәрә. Мәхәллә әгъзалары барлык өмәләрдә дә күңел биреп катнашалар. Моңарчы намаз укыган иске мәктәп бинасында мәдрәсә ачып Хәниф Әбүнәгыймов, Разыя Рафыйковалар (Бигәш мулласы Корбангали хәзрәтнең килене) шәкертләрне гарәп графикасында укы-

рга һәм язарга өйрәтәләр. Әбүзәр хәзрәтнең җәмәгате Рафыйка абыстай Лениногорск районы Куакбаш авылы мулласы Гыймадетдин улы Мөхәммәтфазыл хәзрәт (1870–1950) оныгы. Гыймадетдин хәзрәт Котлыбаев дин галиме, шәрекъ телләре белгече һәм шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең (1754-1834) кызы Бибиҗамалга никахланган.

«Бигәш» мәчете 1999 елның 16 гыйнварендә ачылды. Тәбрикләүчеләр «Татнефть» ААҖ (иганәчеләр) җитәкчесе Ринат хаҗи Галиев, җирле хакимият вәкиле Рәсим Хәйретдинов, Әлмәт төбәге мөхтәсибе Наил Сәхибҗан, Әбүзәр хаҗи, Наилә абыстай Шәмгунова, бигәшлеләр. Тантананы «Татнефть хәбәрләре» телевизион тапшыруы мөхәррире Илшат Мингәрәев алып барды.

Төзүгә өлеш кертүчеләр Әлмәт милли хәрәкәте (Марсель Зиннәтулла), Камил Галиев, Рафыйк Мөбәрәкшин, Вячеслав Чичков, Рафис Вәлиев, Шәех Гарифуллин, Равил Һидәятуллин, Миңнегаян Биктимеров, Радмир Әфләтунов, Ардинат Нугайбеков, Нил Фәрхетдинов һ.б.

2004 елның октябрендә Бигәш мәхәлләсенең мәдрәсәсе ачылды. Уку йортын төзүдә Рөстәм Мөхәммәдиев, Равил Җәләев, Ардинат Нугайбеков, Илшат Вәлиуллин, Радик Әфләтунов, Җәүдәт Харис улы һ.б. булыша. 2006 елдан мәчет имамы Разыйф Габбас улы (1986). Мәгълүматлар Д. Гарифуллинның «Герәнтау итәгендә» (Казан, «Идел-Пресс», 2007. 73–98 бб.) дигән китабыннан һәм мәчет турында картлар язган кулъязмадан, архивлардан алынды.

(Дәвамы бар).

Р.Ф. Сафиуллина

ӘЛӘЗӘН ЭКСПЕДИЦИЯСЕ КӨНДӘЛЕГЕ

Гуманитар фән галимнәре ел саен, көннәр җылыту белән, ил буйлап фәнни экспедицияләргә таралыша. Әлеге традициягә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белгечләре дистә еллар дәвамында тугры. Нинди язмышлар, нинди максатлар йөртә аларны илнең татар яшәгән төбәкләрендә?

Экспедицияләргә чыгу – әлбәттә, Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ хезмәткәрләренең гадәти эше: калын-калын томнар, фәнни китапларга материал, бөртекләп эзли торгач, халыкның үзеннән табыла. Гомумән, фольклорчы, телче, этнограф, милли сәнгатьнең төрле тармакларын өйрәнүче галимнәр өчен Г. Ибраһимов исемендәге институт оештырылганнан бирле изге бер төшенчә ул: экспедицияләргә мәшһүр Латыйф Җәләй дә, Хәмит Ярми дә, башкалар да йөргән. Күренекле язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт тә, фольклор җыючылар сыйфатында, экспедиция сукмакларын байтак таптаган.

Татар галимнәренең бүгенге буыны төрле максатларны берләштергән комплекслы экспедицияләргә чыгып китә. Ягъни, алдан планлаштырылган сәфәрдә төрле фән белгечләре катнаша. 2021 елда институтның музыка белгече Наилә Нургаянова, эпиграфист Венер Усманов, текстолог-археограф Гөлнара Зәйниева, ике Алсу: телче Бәдретдинова һәм сәнгать белгече Борһанова, төркемебезнең җитәкчесе Илмир Ямалтдинов һәм мин (фольклорчылар) Пенза өлкәсенә барып кайттык.

Комплекслы экспедициябез **Городище районы Югары Әләзән авылында** башланды. Әләзәннәр, билгеле булганча, районда өчәү: Югары, Урта һәм Түбән. Өчесе дә зур, нык. Территориаль яктан бер-берсенә якын гына урнашкач, алар өчесе дә аралашып, кыз алышып-бирешеп яши. Ә татар дөньясында Урта Әләзән дигәне бигрәк тә мәшһүр – аның халкы тугыз-ун мең, кайбер әләзәнлеләр белдерүе буенча – хәтта унике меңгә җитә. Ул хәзерге вакытта илдә генә түгел, дөньяда иң зур татар авылы булып санала.

Әләзәннәрнең сөйләмнәре, гореф-гадәтләре, матди һәм матди булмаган мәдәнияте бик охшаш – бертөрле диярлек. Әмма ерактан килгән без мөсафирләр карашына, холыкларында бераз аерма да сиземләнә сыман. Мәсәлән, эшкуарлыкка иң хирыс халык – Урта Әләзәндә дигән тәэсир калды. Бизнесның монда нинди генә төрләре чәчәк атмаган! Чат саен кибет анда, урам саен диярлек ат казысы (без казылык дип йөрткән тәгамнең дөрес атамасы нәкъ шулай була!), пилмән, ит консервлары, сувенирлар һ.б. тауар җитештерәләр. Урта Әләзән, авылдан да бигрәк, бөтен инфраструктурасы, унбер мәчете, ике урта мәктәбе булган район үзәген хәтерләтә.

...Сүзем бит Югары Әләзән турында иде. Монда өч мең ике йөз чамасы кеше яши, диделәр, сигез йөз тирәсе хуҗалык бар. Килеп төшү белән урта мәктәпкә юнәлдек. ТӘҺСИ экспедицияләренә бер үзенчәлек хас: институт авыл мәдәният йортларына һәм мәктәпләргә бүләккә үзендә нәшер иткән китап комплектларын җибәрә. Шулай итеп, татар гуманитар фәненең иң яңа казанышлары: аңлатмалы, диалектологик, төрле тармак терминнары сүзлекләре, «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясе һ.б. затлы басмалар иң беренче итеп монда тапшырылды.

Экспедициядә йөргәндә фольклорчылар җирле халыктан төбәк тарихына кагылышлы риваятьләр, сөйләкләр һ.б. әсәрләр белән кызыксына. Без дә һәрбер торак пунктында иң беренче эшебез итеп шуларны барладык. Югары Әләзәндә язылганнар укучы игътибарына да лаектыр сыман.

Рәсми кәгазьләрдә Югары Әләзән дип язылган авылны халык телендә Аенбура (Аембура) дип атыйлар. Авылның халык телендәге исеме турында күбрәк беләсебез килде.

«Аенбура» атамасының килеп чыгышы турында халыкта төрле фараз йөри. Беренчедән, бу якта инеш булган. Аның тирәсендә, имеш, элек заманнарда паслен (аенбура) котырып үскән – атама шуннан калган. Бу версияне безгә мәдәният йорты методисты Рәмзия Назирова сөйләде. Рәмзия ханым милли фольклор буенча да кайбер мәгълүмат бирде. Мәсәлән, аңардан 1970 еллар башларында туган балаларның балачакларында лапта, ашык, черта (сызыклы уены) «туй-туй» (кияү-кәләш булып киенеп) һ.б. уйнап үсүләрен белдек.

«Аенбура» атамасы турында икенче бер фаразны «каен+бура» сүзләре белән бәйләп карыйлар. «Кайчандыр йортлар каен бурасыннан салынган икән, авыл исеме шуны аңлата», – диләр. Кайсы гасырда булгандыр ул

хәлләр – хәзер инде авылда, гомумән, агачтан салган йортлар сирәк күренеш. Төзелеш материалы буларак, әләзәннәр кирпечне үз иткәне күзгә ташлана. Ә нишләп «Каенбура» түгел, дисезме? Бу яклар сөйләмендә «к» авазы калын итеп әйтелми, ә ашыгып сөйләшкәндә, имеш, ул бөтенләй дә төшеп калган. Бу версия белән безне урта мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укытучы Галия Рәүф кызы Байбекова таныштырды.

Билгеле, авыл атамаларының халык телендә сакланган әлегедәй версияләре фәнни раслаудан ерак тора. Шулай да фольклорчылар өчен алар халык авыз иҗаты буларак кызыклы.

Бәет, шигырь чыгаручы Румия Сәлимҗан кызы Булатова өч Әләзән тарихы турында үз балачагында ишеткәннәрне сөйләде: «Бу якларга элек Әләзән атлы бер бай кеше килгән. Аның өч улы бар икән. Өч улына бай өч җирдә төпләнергә кушкан. Шуннан Югары, Урта, Түбән Әләзән авыллары барлыкка килгән, имеш».

Югары һәм Урта авылларда татарлар гына яши. Түбән Әләзәндә татардан тыш, урыс һәм мукшы да яши. «Әләзән бабайның төпчек малаеның да өч улы булган икән. Менә шулар татар, урыс, мукшыга өйләнгәч, Түбән авылда өч милләт бергә көн күрә башлаган».

Румия ханым фольклорчыларны өенә чакырды, чөнки аның әсәрләре берничә калын дәфтәргә тупланган. Ул урта мәктәптә рус теле һәм әдәбиятын укыткан, шактый еллар директор вазифасын биләгән. 42 ел эшләп, лаеклы ялга чыккач, үзендә шигъри сәләт сизеп алган. Гадәттә, һөнәрмәнд шагыйрьләр гади халык вәкилләренең шакмаклы дәфтәргә кулдан язган мондый әсәрләренә өстәнрәк карый. Ләкин шигырьләредәй самими тоелган авыл иҗатчылары татарлыкны һәм телне саклауга, әлбәттә, өлешне күп кертә. Иҗатлары Коръән мәҗлесләрендә, гаилә очрашуларында халык телендә даими яңгырый. Алар авылдашларына тормыш сынауларын сабырлыкта үткәреп җибәрергә булышалар. Авылның ватсап төркемендә һәрбер вакыйга турында оператив шигырь-бәетләре эленгән булыр. Юкюк та, халык көйчеләре көйләгән йөз бәет-мөнәҗәтнең берәрсе барыбер оныклары колагына кереп калыр, дип өметләник. Экспедициядә йөргәндә Румия Булатова кебек бәетче-мөнәҗәтче әби-апалар һәр авылда диярлек очрый. Җырчы-бәетче апаларны татарлык һәм татар телен саклаучы мөһим бастионнарыбыз дип әйтсәк тә, ялгышмабыз...

Һәр авылда беренче чиратта мәктәпкә, мәдәният йортына кердек. Гомумән, укытучылар һәм клуб хезмәткәрләре – иң зур ярдәмчеләребез. Кайда гына булсак та, үзем дә гел татар теле укытучыларын эзләдем. Алар – олы һәм урта буын вәкилләре, татар фольклоры белән яхшы таныш, күбесе үзләре дә студент чакта экспедицияләргә йөргәннәр. Хәтер сандыгы төпләреннән берничә оригиналь уен (дистәләгән варианты

белән бергә), әкият, такмаклар һ.б. әсәрләр «алып бирделәр». Югары Әләзәннән Галия Байбекова, Урта Әләзәннән пенсиядәге укытучы Алия Сәнҗапова, музыка укытучысы Асия Синҗапова, Түбән Әләзәннән Сания Абхаерова-Кузгуновага аерым рәхмәтләремне әйтәм.

Экспедициядә һәр көн иртәдән кичкә кадәр халык белән аралаштык. Олырак яшьтәгеләр, җирле фольклор хәзинәсе белән уртаклашканчы, башларыннан кичкән авырлыклар турында сөйли башлый. Әйе, татар халкына кайда җиңел булмаган. Әмма нинди генә авыр елларда да кешеләр милли гореф-гадәтебезгә тугрылык сакларга тырышкан, әби-бабайларыннан ишеткән хикмәтле сүзләрне күңеленә сала барган.

«Яңгыр, яу, яу!
Иләктән, чиләктән!
Пәрәмәчкә, коймакка
Арыштан, бодайдан
Без сорыйбыз ходайдан»

– дип балачакта яңгыр теләп ялваруларына хәтле исләренә төшерәләр ак яулыклы әби-апалар. (Борынгы гадәтебезне хөрмәт итеп, Югары һәм Урта Әләзән хатын-кызларының күбесе яулык бәйләп йөри). Бишек җырлары, санамышлар, мәкаль-әйтемнәр, әйтешләр, җырлар, такмаклар, уеннар – Пенза татарларыннан без күбрәк фольклорның шушы жанрларын ишеттек. Һәр төбәктә, танылган фольклорчы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов әйтмешли, аерым фольклор жанрлары үсеш алган була, ә кайберләре – юк. Мәсәлән, хәзерге заманда бу якларда әкиятләрне ишетмәдек, диярлек. Ике атналык экспедициябездә нибары ике әкият яздырдык, алары да киң таралган «хрестоматияле» әсәрләр иде. Аның карауы, җырга һәм уен-көлкегә баеп кайттык, тормышның төрле вакыйгалары белән бәйле йолаларны күп язып алдык.

«1969 елны Урта Әләзәннән килен булып төштем, – дип сөйләп китте безгә 1945 елгы Сафура Али кызы Жаркова. – Башта инде, никахка кадәр кыз өендә «сүз бетерү» була. Булачак кода-кодагыйлар никах, туй шартлары, кунак чакыру, придан турында сөйләшәләр. Каенанам Әбушахман кызы Әсмә 1908 елгы иде, ире сугышта үлгән – улын ялгызы үстергән. Акча да юк, килен төшерергә тырантаслы алашалар да юк – чылдырдатып утырттылар бензовозга да китеп бардым Аенбурага. Приданга бер күлмәклек материя тоттырып йибәрделәр. Кияү ягы калымга (мәһәр) 10–20 сум акча биргәндер инде, акчага интеккән чаклар иде бит әле…

Яшь килен булып төшкәч, кызлар су юлын күрсәтергә алып киттеләр. Барысы да иремнең ырулары, беренче чиләкне тутырып алгач, аяк астыма салып агыздылар. «Су кебек җәел, урман кебек тамыр җибәр», диләр безнең якта. Су юлын күрсәтүчеләргә яулыкмы, тасмалмы (тастымал) бирдем инде».

Хәзерге көндә дә авылда килен төшерү йоласы саклана әле. Заманына күрә гореф-гадәтләр кайбер үзгәреш тә кичерә – монысы табигый процесс. Бүгенге туй-никах йолалары турында урта мәктәп укытучысы Гөлсинә Ядкәр кызы Ханбекова да сөйләде:

«Хәзер киленнәрне машина белән төшерәләр. Башта малай (кияү) чыга, уң аягы белән. Килен дә машинадан төшкәндә уң аягы белән атлый. Аның аяк астына ак җәймә җәйгән була. Кайнана подноска куеп, кечкенә чәйнек белән ширбәт алып чыккан, яшьләрне каршылый. Ширбәтне башта чәйнек авызыннан улына каптыра, аннан – килененә, аннан үзе йотып куя. Ширбәтне шулай өч кеше йотканнан соң, башка кунакларга да берәр йотым каптыралар».

«Нәрсә соң ул ширбәт һәм нигә кеше саен берәр генә йотым?» дигән сорау туды. Гөлсинә: «Ширбәт ул – шикәргә су кушып ясаган эчемлек, «бал сывы» да диләр. Бик баллы була, бер йотымнан артык эчеп булмый аны», – дип аңлатты. Йоланың мәгънәсе – яшь гаиләнең тормышы ширбәт кебек татлы булсын (әмма нык баллыга да түзә белергә кирәк икән әле). Йоланың тагын бер варианты: киленгә, татлы булсын дип, ширбәт каптыралар, йомшак булсын дип, мендәргә бастыралар икән.

«Аннан соң никах укыйлар, өстәлгә табак белән су куелган була. Аны «никах сывы» диләр. Никахтан соң шушы су белән кияү-кәләш, караватка утырып, битен юа. Килен кияүгә үзе алып килгән өр-яңа майка белән күлмәк кидерә дә мәҗлес дәвам итә. Кунаклар киткәч, өч көн кыз балы була». Ягъни кияү өендә яшьләр аулакта кала. Яшьләрнең тынычлыгын чит-ятлар бозмасын өчен сакчылар кую гадәте дә бар, ләкин анысы инде онытыла башлаган. Шулай ук «өч көн» шартын үтәү-үтәмәү дә гаиләнең үз иркендә.

Сафура апа Жаркова өендә фольклор-этнографик материал яздырганда, Казан кунакларына җырлап күрсәтер дип, аның күршесе Хасибә Билал кызы Медведеваны да чакырып керделәр. Ул шушы Аенбуранык, 1943 елда туган, мәктәптә 8 сыйныф укыган. Гади татар апаларының фамилияләре русча яңгырашлы булуына игътибар иттек. Бу якларда еш очрый торган күренеш. Хасибә апа да моны элек аларның нәсел исеме Аюевлар булуы, документ тутырганда фамилияләрнең кайчагында урысчалаштырып язылуы белән бәйләп аңлата.

Сафура апа белән Хасибә ападан үзләре уйнап үскән берничә уенны яздырып алдык. Шуларның берсен укучыга да тәкъдим итәбез.

«Ялкын». Әлеге уенны вичерларда[1] уйный идек, яшьләр җыела, түгәрәккә баса. Идән уртасына чыга идек тә, ике кеше урындыкка утыра, тагын ике кеше – алар тирәли әйләнә идек. Утырганнар кыз белән малай була инде.

[1] Вичер – яшьләрнең кич утыруы яки кичке уеннар («вечер» сүзеннән). Бу текстта байтак сүзләрне, оригиналь яңгыраш саклансын өчен, җирле халык куллана торган сөйләм вариантында бирәбез.

Йөрәкләре җитсә, сүләшәләр. Дәшмичә генә дә утыралар. Әйләнә торган егет белән кыз берәр озын җыр җырлый, башта егет йөри, аның артыннан – кыз.

Җыр беткинчә тегеләр бер урындыкта утырырга тиеш. Җыр бетүгә утырганнар түгәрәккә баса, хәзер инде җырлап әйләнүчеләр икесе бер урындыкка утыра. Әйләнергә тагын бер пар чыга да уен тагын башлана. Яратышып йөргәннәрне атына[1] чыгаралар иде, әгәр белсәләр. Белмәсәләр теләсә кем белән дә чыга. Кыз белән кыз да булырга мөмкин. Озын ерлар гына түгел, такмаклар да ерлый идек:

«Яшь вакытта һәркемнең дә
Бик күп була сөйгәне.
Ләкин арада бер була
Гомерлеккә дигәне.

Яшь вакытта яшьнәргә дә,
Күкрәргә дә көч җитә.
Ләкин кадерен белү кирәк,
Яшь вакытлар тиз үтә».

Апалар бу уенны безгә сөйләп, җырлап, хәрәкәтләрен дә аңлатып бирде. Мондый җор телле, тормыш авырлыкларын гадәти бер нәрсә дип кабул иткән информантларны авыл саен очраттык без. «Нык буын, матур кешеләр» дип сокланырлык апа-әбиләр. Алар белән рәхәтләнеп фотога да сугылдык (бу якларда фотога төшермиләр – сугалар).

Кадерле кунаклар дип, Пенза якларында безгә авыл саен диярлек мәшһүр алаша (ат) пәрәмәченнән авыз иттерделәр. Иң беренче сыйлаганнары – Югары Әләзәндә иде. Күз алдыбызда ук, авыл мәдәният йортында пешерделәр. Әле кайда диген – клуб сәхнәсендә. Һәм совет-студент елларыннан ук күбебезгә таныш гап-гади электр плиткасында! (Өч Әләзәндә пешерелә торган пәрәмәч ысуллары журналыбызның 2022 елының 3/4 санында дөнья күрде – ред.).

[1] Атына – махсус.

Маршруттагы икенче авылыбыз – Урта Әләзән. Шәхсән үземнең бу авылга икенче мәртәбә килүем. Кабат-кабат бер сукмактан йөрткән сәфәрне, әлбәттә, язмыш бүләге дип кабул итәргә кирәк, чөнки кешене эчәсе суы һәм ризыгы гына түгел – истәлекле очрашулар, онытылмас тәэсирләр дә йөртә. Беренче экспедиция вакытында очраткан шәхесләрне исән-имин күрү бик сөендерде. Фатир хуҗабыз Алия Абдулла кызы, авыл буйлап озатып йөрткән Асия Сенҗапова һ.б. белән шатланышып күрештек, фольклор сандыгыбызны баеттык.

Беренче, 2007 елгы экспедицияне, Казанда БТК Башкарма комитеты ягыннан Мөнирә Сәгыйдуллина һәм кабул итүчеләр ягыннан Урта Әләзән авылының бөтен татар дөньясына мәшһүр кешесе Кязим Дебердеев оештырырга ярдәм иткәннәр иде. Кязим абый Пенза шәһәренә килеп, безнең дүрт кешелек төркемне машина белән каршы алган, урнаштырган, барлык очрашуларны оештырган иде.

Әләзәнгә икенче баруыбызның җитешсез һәм үкенечле ягы булса, ул, әлбәттә, Кязыйм Дебердеевның юклыгы. Заманында совхоз җитәкләгән, Городище районы башлыгы, өлкә губернаторы ярдәмчесе булган көчле, абруйлы, сүзе үтә торган шәхес иде. Урта Әләзәннең гомум татар дөньясына интеграцияләвенә бик күп өлешен керткән, авылда Сабан туен үткәрү гадәтен тергезгән, Татарстан белән икътисадый-мәдәни элемтәләрне җайга салган кеше ул. Атаклы иганәче Дебердеевлар нәселенең лаеклы вәкиле булган Кязыйм Шаһазам улы 2018 елда йөрәк чиреннән китте. Авылдашлары әле дә аны сагынып сөйли. Татар дөньясының алтын баганаларыннан иде шул ул, сүзебез дога булып барсын...

Урта Әләзәннең йортлары аеруча матур итеп эшләнгән. Бизәкле тәрәзә йөзлекләре, өй кыеклары, капкалар һ.б. – күбесе шушы җирлеккә генә хас. Ишегаллары, өй эчләре дә гади авыл йортлары кебек кенә түгел – затлылыкка, купшылыкка омтылыш көчле. Өйләр, каралты-кура катлы-катлы, чәчәккә күмелеп утыра. Муллыкка хезмәт белән ирешәләр. Байтак ирләр читкә китеп эшли, вахта ысулы белән Мәскәүгә, Төньякка йөрүчеләр шактый.

Эшчән, оптимистик рухлы әләзәнлеләрдән мин бик күп такмаклар, байтак мәзәкләр язып алдым. Ләкин «сандыгым»ның иң түрендә – чын әләзәнчә пәрәмәч пешерү рецепты. Аны бу эшнең профессионалы – мәктәп ашханәсендә ашчы булып эшләүче Румия Таһир кызы Тюгаева (1963 елда туган) тәкъдим итә. Румия Тюгаева оста җырлый да икән. ТӘҺСИ

ның фольклор коллекциясе аның һәм хезмәттәше Адилә Адикаева (1972 елда туган) такмаклары ярдәмендә берничә дистә берәмлеккә артты.

Әләзәндә барысы да җырлый, йә бәет-шигырь чыгара, телгә оста, шат күңелле, дигән тәэсир кала. Динә Бибарсова, Наилә Чумгалакова, Райсә Бухминова, Асия Синҗапова, Гүзәл Әлмәшева, Исмаил Дебердеев, Алия Сеньжапова, Әлфия Уразаева, Наилә Дулатова, Алия Мукаева, Разыя Адикаева, Җәфәр Адикаев һ.б. белән аралашу бездә шундый тәэсир калдырды. Милләтебезнең гади бер вәкилләре – аларның татар халкы кебек үк моңлы да, кирәгендә төртмә телле дә булулары җыр-такмакларыннан ук күренә:

«Хәсрәт хәсрәттин охшамый,
Хәсрәт урыны бушамый.
Һәркемдә дә бар хәс(е)рәт –
Минекенә охшамый.

Кызыл миләш күмере дә,
Кызыл миләш күмере.
Кияү белән яшь киленнең
Озын булсын үмере (гомере).

Әниемнеңме каргышы,
Әтиемнеңме каргышы?
Ник каргасын үз баласын –
Бер Аллаһның язмышы.

Урманнан килә лиса,
Урманнан килә лиса.
Килен шунда яхшы була,
Кайнана телен тыйса».

Сары сундук нигә кирәк?
Сабын төяргә кирәк.
Кара чәчең агарса да
Сабыр итәргә кирәк.

Өченче барган авылыбыз – Түбән Әләзән.

Халкы ике меңнән артык, диделәр. 90%ка якын татарлар булса да, биредә рус белән мукшы да яши. Шуңа күрәме икән, мондагы татарлар «аурупача»лыгы, күңел ачарга маһирлыгы белән аерылып тора. Безнең төркемне җигүле атлар белән, гармуннар, җыр-бию һәм «Каз өмәсе» фольклор йоласын күрсәтеп, авыл башына җиткәнче үк каршы алдылар. Авыл советы рәисе Галия Исляева әйткәнчә, кунак һәм милләттәшләр хакын хаклап, монда «лексус» иярләгән җирле эшкуарлар, район депутатлары да килгән иде. Бу, әлбәттә, Түбән Әләзәнлеләрнең абруен нык арттыра. Дөресен әйтик, кайбер төбәкләрдә фәнни экспедицияләр белән эшләү әле һаман да мәктәп һәм клуб хезмәткәрләре җилкәсенә генә төшә, моны милләт һәм дәүләт өчен, мәсәлән, җанисәп кебек үк әһәмиятле эш дип аңлау җитенкерәми. Түбән Әләзәнлеләр исә үрнәк итеп күрсәтерлек.

Түбән Әләзән апалары Хава Шакир кызы Бикмаева, Раисә Сәлимулла кызы Морозова, Октябрина Шиһап кызы Давыдова-Бахтеева, Рәмзия Җиһанша кызы Бичурина, Наҗия Касыйм кызы Севастополева, Фәтхия Ариф кызы Севастополева, Наҗия Абдулкадыйр кызы Галкина, Сания Ибраһим кызы

Абхаерова-Кузгунова, Нурия Искәндәр кызы Кудюшкина, Дамира Феать кызы Вяселева һ.б. дан байтак фольклор материалы яздырдык.

Алар яшь чакларында кичәләрдә уйнаган уеннарын искә төшерде. «Армиягә озатканда, йә туйдан соң, йә болай гына да яшьләр җыелышканда кичләрен вичер була иде, – дип сөйләде апалар. – Иң якын дус кызлар килә башта, туган тиешле кызлар. Алары – хуҗалар чакырып. Аннан соң инде малайлар килә, үзләре килергә теләгән яшьләр. Туйдан соң булса, аларга өстәл дә коралар. Биюләр, уеннар шунда. Авылыбыздан йөзгә якын кеше җыела иде». Бу – узган гасырның 60–70 нче еллары турында сүз бара. Соңрак инде яшьләр клубка, «танцыга», аннары, 80 нче елларда дискотекаларга йөргән, ди апалар.

Укучыга бу якларда яшьләр яратып уйнаган «Перәшкә»не тәкъдим итәбез.

«Утыра идек түгәрәкләп клубның бөтен эстәналары буйлап, эскәмиядә. Бер егет әйтә:

Миңа фәлән кыз кирәк!

Шул кыз чабып барып теге егетнең янына утыра. (Егет тә булырга мөмкин). Шул арада уен хуҗасы кызга перәшкә белән сугарга өлгерсә, димәк кыз йә җырлый, йә бии, йә бүтән төрле җәза үти. Кызлар суктырмаска тырыша, чөнки каеш сыртка каты төшәргә дә мөмкин, чыдап кына тор. Сугарга өлгермәсә, уен хуҗасы алмаша, бүтән кешеләр дә алып баручы була».

Әнә шулай, татарның бер матур һәм үзенчәлекле кыйтгасы – җырлыбиюле, бай гореф-гадәтле һәм пәрәмәчле Әләзәннәр тарафына сәфәребез тәмамланды. Ләкин Пенза өлкәсенең башка районнары һәм татар авылларына сәфәрләребез әле тәмамланмады. Алары турында да көндәлек-язма булыр, дип өметләнеп калыйк.

Алсу Борһанова фотолары кулланылды.

А.И. Бугарчев

НУМИЗМАТИКА И КРАЕВЕДЕНИЕ НА КОНФЕРЕНЦИЯХ 2022 г.

За прошедший год, благодаря отмене ковидных ограничений, состоялось много международных, всероссийских и региональных конференций по истории, краеведению и археологии средневековья. Мы, казанские нумизматы, принимали активное участие как лично, так и онлайн. В первую очередь на данных конференциях мы обращались к темы золотоордынской нумизматики как важного источника по истории татарских сёл и деревень.

Перечислим конференции, съезды и форумы, где мы выступали с заявленной темой.

17 марта – участие в заседании круглого стола «Тысячелетнее наследие ислама в археологии России», посвящённой 1100-летию принятия ислама в Волжской Булгарии и выступление с докладом «Булгарский монетный двор Орда (по материалам клада «Караульная Гора» из фондов НМ РТ) (Институт археологии РАН – удалённо).

1 апреля – участие во Всероссийской научно-практической историко-краеведческой конференции «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии. Уроженец Пестречинской земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа и выступление с докладом «Клад ордынских монет начала XV в. из Дятлово (Лаишевский район РТ)».

22 апреля – участие Республиканской научно-практической, историко-краеведческой конференции «Историко-культурное наследие Высокогорского Заказанья и сопредельных районов Республики Татарстан» и выступление с докладом «Джучидские монеты из села Венета Арского района Татарстана».

16–18 мая – участие в IX Научной конференции памяти Г.А. Фёдорова-Давыдова «Диалог городской и степной культур на Евразийском пространстве» и выступление с докладом «Нумизматический материал из с. Рождествено (Татарстан) по материалам фонда Музея археологии АН РТ» (Саратов).

3 июня – участие в Международной научной конференции «Археология восточно-европейской лесостепи» и выступление с двумя докладами: «Клад булгарских монет 1280-х гг. из пос. Приволжский Спасского района Татарстана», «О двух группах ордынских пулов XIV в.» (Пенза).

26–27 сентября – участие в VII Всероссийском (Уральском) Форуме татарских краеведов «Татары Уральского региона: история и современность» и выступление с докладом «Торгово-экономические контакты Волжской Булгарии и Пермской земли в X–XIII вв.» (Пермь–Серов–Екатеринбург).

18 ноября 2022 г. – участие в Региональной научно-практической конференции «Болгарский музей-заповедник – хранитель культурного наследия», приуроченной к 1100-летию принятия ислама волжскими булгарами в 922 г. Выступление с двумя докладами: «О кладе джучидских монет начала XV в. из д. Чулла (Тетюшский район), «Джучидские монеты XIII – начала XIV вв. из находок на IV Старокуйбышевском селище (Спасский район Татарстана)». Болгар.

22 ноября 2022 г. – участие в Нумизматических чтениях ГИМ и выступление с тремя докладами: «О двух кладах джучидских монет XIII в. из окрестностей Болгара», «К вопросу о весовом параметре новосарайских пулов с датой 743 г.х. (1342/1343 гг.)» и «Джучидские монеты XV в. из Лаишевского района Республики Татарстан». Москва.

25 ноября 2022 г. – выступление с докладом «Находки джучидских монет XIII–XIV вв. в Пермском крае» (в соавторстве) на Всероссийской археологической конференции «Проблемы изучения, охраны и музеефикации памятников археологии в городском пространстве», посвящённой столетию со дня открытия комплекса памятников «Постников овраг», Самара (удалённо).

14–15 декабря – участие в VII Международном Золотоордынском Форуме и выступление с докладом «О кладе ордынских монет XV в. из посёлка Борисково». Казань.

Всего мы участвовали в 10 конференциях, из них международные – 2, всероссийских – 6, региональных – 2. Были изучены нумизматические материалы из таких населённых пунктов как д. Дятлово и с. Рождествено Лаишевского района, с. Венета Арского района, пос. Приволжский и IV Старокуйбышевское селище Спасского района, селище Мурзиха Алексеевского района, д. Чулла Тетюшского района, бывшая д. Агайбаш Лаишевского района, пос. Борисково (территория современной Казани). Кроме краеведческой направленности, в наших докладах затрагивались вопросы истории денежного обращения в Среднем Поволжье и нумизматические связи с Крымом и Приуральем.

Приложение

Статьи и доклады, изданные в 2022 г.

Бугарчев А.И. Ордынские монеты рассказывают о средневековой истории Кайбицкой земли // Кайбицкие Зори (газета) № 38 (9412), 28 мая 2021 г. С. 2.

Бугарчев А.И. Кайбыч ягынын бай хэзинэсе // Кайбыч таннары № 94 (9468), 15 декабря 2021 г. С. 3 (на тат. яз.).

Алексей Бугарчев, Олег Степанов. Питрэч районынын нумизматика ядкярлэре // Безнен Мирас. 03 (339). Март 2022. 66–67 (на тат. яз).

Бугарчев А.И., Шайхутдинова Е.Ф. Нумизматический комплекс из с. Рождествено (Татарстан) по материалам Музея археологии РТ Института археологии АН РТ // Археология евразийских степей. № 3. 2022. Казань. С. 169–174.

Бугарчев А.И., Степанов О.В. Клад булгарских монет 1280-х гг. из пос. Приволжский Спасского района Татарстана // Пензенский археологический сборник. Международный сборник научных трудов / Под общей ред. Г.Н. Белорыбкина. Вып. 5. Пенза, 2022. С. 288–292.

Бугарчев А.И., Мухаметшин И.Д., Степанов О.В., Файзрахманов П.Х. О двух группах ордынских пулов XIV в. // Пензенский археологический сборник. Международный сборник научных трудов / Под общей ред. Г.Н. Белорыбкина. Вып. 5. Пенза, 2022. С. 321–328.

Валеев Р.М., Бугарчев А.И. Серебряные монеты XIII – начала XIV вв. из раскопа CLXXIX Болгарского городища // ПА. 2 (40). Казань: «Фэн», 2022. С. 135–144.

Бугарчев А.И., Фёдорова Е.А. Находки крымских пулов XIV в. на территории Болгарского городища // Крымское историческое обозрение. Т. 9, № 1. 2022. С. 115–122.

Бугарчев А.И., Степанов О.В. Питрэч районынында табылган урта гасыр акчалары // «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии. Уроженец земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа. Мат-лы Всероссийской научно практической, историко-краеведческой конференции. // Серия «Восток – Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 22. / Под ред. А.А. Бурханова. Казань: Отечество, 2022. С. 58–59 (на тат. яз.).

Степанов О.В., Файзрахманов П.Х. Клад-кошелёк русских монет XV–XVI вв. из Ленино-Кокушкино Пестречинского района Республики Татарстан // «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречин-

ском Заказанье в историческом развитии. Уроженец земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа. Мат-лы Всероссийской научно практической, историко-краеведческой конференции. // Серия «Восток–Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 22. / Под ред. А.А. Бурханова. Казань: Отечество, 2022. С. 59–62.

Бугарчев А.И. Джучидские монеты из находок на селище Мурзиха Алексеевского района Республики Татарстан // «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии. Уроженец земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа. Мат-лы Всероссийской научно практической, историко-краеведческой конференции. // Серия «Восток–Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 22. / Под ред. А.А. Бурханова. Казань: Отечество, 2022. С. 62–64.

Бугарчев А.И., Павлов А.А. Клад ордынских монет начала XV в. из Дятлово (Лаишевский район РТ) // «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии. Уроженец земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа. Мат-лы Всероссийской научно практической, историко-краеведческой конференции. // Серия «Восток–Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 22. / Под ред. А.А. Бурханова. Казань: Отечество, 2022. С. 64–65.

Степанов О.В., Бугарчев А.И. Касыйм ханлыгында акча эйлэнеше // Безнен Мирас. № 8. 2022. С. 12–13 (на тат. яз.).

Бугарчев А.И., Петров П.Н., Шайхутдинова Е.Ф. Монеты Хаджи-Тархана XV в. из клада Караульная Гора (по материалам из фондов НМ РТ) // Европейская степная цивилизация: человек и историко-культурная среда. Материалы V Международного конгресса археологии евразийских степей (г. Туркестан, 11–14 октября 2022 г.) / Гл. ред. А. Онгар. Алматы-Туркестан: Институт археологии им. А.Х. Маргулана, 2022. Т. 5. С. 242–247.

Бугарчев А.И., Петров П.Н., Сингатуллина А.З., Шайхутдинова Е.Ф. Монеты XV века хана Барака Булгарского монетного двора (по материалам клада «Караульная Гора») // Археология Евразийских степей. № 5. 2022. Казань. С. 19–25.

Бугарчев А.И., Степанов О.В., Файзрахманов П.Х., Иванов А.А. О двух кладах джучидских монет XIII в. из окрестностей Болгара // Нумизматические чтения Государственного Исторического музея 2022 г. Материалы докладов и сообщений / Отв. ред. В.В. Захаров. Москва, 2022. С. 65–71.

Петров П.Н., Моржерин К.Ю., Бугарчев А.И. К вопросу о весовом параметре новосарайских пулов с датой 743 г.х. (1342/1343 гг.) // Нумиз-

матические чтения Государственного Исторического музея 2022 г. Материалы докладов и сообщений / Отв. ред. В.В. Захаров. Москва, 2022. С. 71–75.

Степанов О.В., Купцов А.Е., Бугарчев А.И. Джучидские монеты XV в. из Лаишевского района Республики Татарстан (предварительное сообщение) // Нумизматические чтения Государственного Исторического музея 2022 г. / Отв. ред. В.В. Захаров. Москва, 2022. С. 85–91.

ИСЕМЕ ҮК ҖЫРЛАП ТОРГАН АЗНАКАЙ УЛ!
(Дәвамы. Башы № 3, 2020)

КҮКТӘКӘ АВЫЛЫ

Өдһөд кошы[1] *(әкият)*

Элек заманда булган. Әкият. Карт белән карчык яши. Беркемнәре булмый боларның. Бер сыерлары гына була, шуны асрыйлар. Яшиләр, яшиләр. Берәүдән дә рәхмәт сүзе ишеткәннәре булмый боларның. Аралашмыйлар беркем белән дә. Боларга берәү дә керми, үзләре дә бармыйлар. Шулай берзаман уй төшә картның башына, әйтә карчыгына:

– Менә, ди, гомер яшәп, ди, берәүдән дә рәхмәт ишеткән юк, ди. Әйдә, сыер суйыйк, кунак җыйыйк, ди.

Рәхмәт ишетәселәре килеп, сыер суялар болар хәзер. Аш чакыралар. Шәһәрдәге бөтен кешене чакыралар табын ясап. Боларга берәү дә килми. Үзләре генә ашап бетерәләр пешергән ризыкларын. Сыерның башы гына кала. Аны да тазартып, пешерергә салалар. Ир урамга чыгып китә. Берәү дә күренми. Берзаман моның янына бер ап-ак сакаллы карт килеп чыга.

– Әйдә безгә, – ди, чакыра картны өенә. Бергә ашыйлар инде пешкән сыер башын. Рәхмәтен әйтеп чыгып китә теге карт. Киткәндә үзе дә кунакка чакыра боларны. Өйрәтә ничек-ничек барасын.

Моның янына дип чыгып китә карт, теге ак сакаллы бабай янына дип инде. Ул өйрәткәнчә бара да бара. Бара торгач, бер җиргә килеп чыга. Бу урында халык күп җыелган, патша сайлыйлар монда. Өдһөд дигән кошны очыралар. Өдһөд кем башына килеп куна, шул кеше патша буласы икән. Бу күрде инде бу хәлне, туктамады, дальше китте. Бара, бара. Караса, шәрә кызлар биетә торган җиргә килеп җиткән бу. Анда да туктамый бу. Карт өйрәткән юл белән бара һаман. Хәзер берзаман теге ак сакаллы карт үзе моның янына килеп чыга. Килеп чыга да әйтә моңа: син дөрес барасың, ди, алай да сиңа кире борылырга кирәк, ди. Карап бар, ни күрерсең, ди. Патша сайлый торган җирдә туктарга куша моңа. Бу әйткәнчә эшли инде. Кайта. Кайтканда теге шәрә кызлар биеткән җиргә җитсә, ни күрә, җир убылып, тегеләрне йоткан, ди. Бер әби генә утырып калган, ди. Әйткән моңа әби – җир убылды, тегеләр җир астына китте, дигән. Бу күрде инде моны, гыйбрәт алды, китте.

Кире кайта бит инде килгән юлы белән. Өдһөд очырган җиргә җитте. Өдһөдне һаман очыралар, ди. Беркемнең башына кунмаган булган, ди әле. Моның башына килеп куна. Шуннан моны патша итәләр инде, башына Өдһөд

[1] Хәзер әдәби телдә – һөд-һөд (русча – дрофа).

кошы кунды, дип. Шуннан бу баеп, патша булып кайтып керә хатыны янына. Юлында очраган теге ак сакаллы карт Хозыр Ильяс булган, Хозыр Ильяс очраганга, аны чакырып сыйлаганга, яхшылыгына күрә яхшылык күрә. Бетте.

Янган тау *(җыр)*

Янган тау баскычларының
Кемнәр койган корычын?
Әлләниләр бирер идем,
Әллә ниләр бирер идем,
Сине бер күрер өчен.

Ераклардан җырлап киләм,
Җырлар җырлап туймадым.
Җырларымның иң назлысы,
Җырларымның иң назлысы
Синдер ул, дип уйладым.

Ераклардан җырлап килеп,
Эчтем чишмә суларын,
Чишмә сулары басмады,
Чишмә сулары басмады
Йөрәгемнең ярсуларын.

Ераклардан җырлап килеп,
Җырлар җырлый башлыймын,
Җырларымны җырлаганда,
Җырларымны җырлаганда
Сине уйлый башлыймын.

Җирәнчәкәй атның, ай, яллары *(җырлы сөйләк)*

Адәме (ире. – Л.М.) үлгән берәүгә йортка кергән иде бер кеше.
Җирәнчәкәй атның, ай, ялларын
Кыйблалардан искән җил тарый,
Үз бәхеткәйләрең булмагач,
Байга хезмәт итеп кем ярый?
Шулай дип җырлар иде йортка кергән кеше. Шуның җыры бу.

Әзһәбиева Гамилә Бикморат кызыннан, 1925 елгы,
тумышы белән Үчәледән.

Инәй җыры

Хәзрәтемә кунак килгән.
Мысырдан пар күгәрчен,
Хәзрәтем сабак бирә,
Үзе елый, күрәмсең?

Хәзрәтемнең бакчасында
Чәчми үскән гөлләр бар,
Гөлләренең яфрагында
Аллаһ дигән сүзләр бар.

Марданшина Бибисәлимә Әхмәтгали кызыннан, 1927 нче елгы.

ТЫМЫТЫК АВЫЛЫ

Тымытык *(топонимик риваять)*

Тымытык – тымызык, тыныч күл дигәннән. Башкортлар белән якын яшәгәнгә, «з»ны сакау әйтү киткән, сөйләмебез шундый. Шул тымызык дигән сүздән авылның исеме. Монда күлләр күп булган. Тыныч күл дә булгандыр. Авылга исем биргән шул күл. Бу урыннар безнең җирләр булган гомер-гомергә.

Сабан туе нинди бәйрәм дә Җыен нинди бәйрәм? *(милли бәйрәм)*

Җир кардан әрчелгәндә бәйрәм итәләр иде Сабан туен. Күчмәдән утрак тормышка күчкән чорлардан бирле килә торган бәйрәм. Хәзер, дөрес, уздырмыйлар. Сабанга чыгар алдыннан уздырыла торган бәйрәм булган ул Сабан туе.

Ә менә печәнгә төшәр алдыннан Җыен була торган иде. Аны бәйге, дип тә әйтү бар иде. Күктәкә авылында Җыен тавы бар уң якта калкурак урында, җыен үтә торган урын иде ул. Авылара бәйрәм иде Җыен. Атларны өчәрләп җигеп, атларга төялеп, атны бизәп баралар иде гармун уйнатып. Сабан туеннан аермасы әллә ни юк. Шул ук ат чабышы, көрәш – төп уеннары шулар. Кунакка йөрешәләр җыенда. Кунакка баралар, кунак алалар. Сатарга теләгән кешеләр сата иде шунда вак-төяген.

Җыен уздыру бетте. Аны бетерделәр. Партия тыйды Җыен белән Сабан туен аерым-аерым уздыруны. Аларны берләштерделәр. Вакыты да күчте. Җыен, дисәң, Сабан туе, дип беләләр инде, телгә дә шулай керде. Элек аерым иде.

Миннегалиев Миңнегәрәй Миңлегали улыннан, 1927 елгы.

ӘГЕР АВЫЛЫ

Әгер *(топонимик риваять)*

Әгер ул егерь дигән сүздән килеп чыккан. Монда аучылык белән шөгыльләнгәннәр. Җиләк ягы бу. Таулы җирләрдә җиләк күп. Суыр оялары, төлке өннәре күп монда. Авылга ук килеп, зыян да китергәлиләр кайвакыт. Электән шулай җанварларга бай як булган. Шуңа егерьләр дә күп булган. Авылның Әгер дип аталуы шуннан.

Гәрәев Ришат Рәфәт улыннан, 1951 елгы.

Әгердә Каз өмәсе ничек уза? *(йола фольклоры)*

Каз өмәсе каз суюдан башлана. Ирләр суеп бирә каз санына, эшләүче кешеләр санына карап. Өмәгә апа-сеңел, туганнар җыелыша. Бер кешегә бишәр каздан да ким туры килми гадәттә. Олы чанга су куялар. Мунча ягалар. Мунчада тезелешеп утырып, суда пешекләнгән казны йолкыйбыз. Баш-аяктан башлап чистартабыз. Аннары казның үзен чистартабыз. Чистарткач, өтәбез ут өстендә тотып, эчен алабыз, юабыз.

Чистартыр алдыннан каз канаты аерым киселә алдан. Канат каурыйлары йолкып алына. Мендәр йонына буласы түш тирәсе йоннары да аерым җыеп барыла.

Кич белән, эш беткәч, бәлеш салына. Казның эчәгесен чистартып, каз аягына бәйләп, бәлешкә салып пешерү бар. Башы да салына шунда. Тәмле була. Бәлешкә өмәдә катнашкан кешеләр килә.

Миңнегалиева Илүзә Рамил кызыннан, 1983 елгы.

Абзар иясе, йорт иясе һәм бакча иясе *(мифик ышану)*

Дәү эти әйтә иде: толымнарын асылындырып, ап-ак чәчле, ап-ак озын күлмәктән карчык утыра абзарда, дип әйтә иде. Ул, абзар иясе, малларны саклый ул, дия иде. Яратмаган малларын төнозын интектерә, авызыннан күбекләре килгәнче төнозын чаптыра. Йорт иясе, абзар иясе бардыр инде ул. Көтүгә йоклап калсаң, тәрәзәгә чиертеп, йорт иясе уята. Ышанмый булмый. Алма бакчасында да каравыл өендә ия бар.

Миннегалиева Илүзә Рамил кызыннан, 1983 елгы.

СӘПӘЙ АВЫЛЫ

Сәпәйдә башкортлар, типтәрләр *(тарихи сөйләк)*

Авылда башкорт очы бар, ул бу тирәдәге һәрбер авылда бар. Әмма монда җир турында гына сүз бара, шуңа бәйле атаманың сакланып калуы турында гына. Билгеле булганча, башкортлар русларга үз теләкләре белән кушылган. Шуның өчен аларга җир бирелгән. 18әр десятина. Типтәрләргә 6 шар десятина, ә казан татарларына–3әр генә десятина җир бүленгән. Типтәрләр–дәфтәр сүзеннән килеп чыккан шартлы бер атама. Чыңгызхан вакытында халык исәбен дәфтәргә теркәп алып бару булган. Милләтне аңлатмаган ул сүз. Теркәлгән кешеләрнең нәселләре гасырлар буена типтәр исеме белән аталганнар.

Солтанов Мирфаяз Мирхазиян улыннан, 1951 елгы.

Сәпәй авылының исеме каян килә? *(топонимик риваять)*

Аны төрлечә әйтәләр. Сәфәргали исемле кеше тау башына килеп утырган. Аны Сәпәй дигәннәр, исемен бозып. Шуннан авыл да Сәпәй дип атала башлаган. Тагын әйтәләр, саперлар тау башында яшәгән, шуннан Сәпәй булып киткән, диләр.

Сәлимгәрәев Ирек Әхмәтгали улыннан, 1939 елгы.

САРЛЫ АВЫЛЫ

Сарлыда кичке уен

Ык буйларына яшьләр җыелышып төшә идек, шунда кичке уенга җыела идек.

Алын алырсың микән,
Гөлен алырсың микән,
Урталарга чыгып сайлап,
Кемне алырсың икән.

Шулай дип җырлый торган идек. Шулай җырлыйсың да яратып йөргән егетең булса, аны алып, егетләр сөйгән кызларын сайлап, әйләнә идек. Аны гына җырламый идек инде. Күп иде җырлар. «Аллиягөллия» дип тә җырлый идек. «Батыр комсомол»ны да уйный торган идек.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Әшерәф.
Кирәгеңне бирер идем,
Әгәр булсам яшьрәк.

Атап җырлау бар иде бит элек. Җырлый идек. Онытылган инде. Җырга шәп (оста. – Л.М.) кызлар-егетләр бар иде.

Бала тугач *(йола фольклоры)*

Бала тугач, коендыру була баланы.

– Бәхетле булсын! Тәүфыйклы булсын! Сәламәт булсын! Төгәл тәне сау булсын! – дип коендыралар. Көненә икешәр-өчәр җуындырыш иде безнең заманда.

Баланың беренче тешен күргән кеше аңа бүләк бирергә тиеш.

Солтанова Һидая Мәхмүтҗан кызыннан, 1933 елгы.

Мәет озатканда он куеламы? *(мөселман гореф-гадәте)*

Кәфенне әзерлибез. Кисеп куябыз. Мәетне колашага салабыз. Ике яктан ике абыстай укый-укый юалар. Госел алу тәртибендә юындыралар мәетне. Су колашадан агып чыга тора. Колашаны куя торган караваты да бар. Колашага целофан җәеп, коендырып куябыз. Мәетне юып, эшен бетергәч, колашадан алып, кәфенлеккә салабыз. Мәет астына он куялар иде элек. Хәзер куймыйбыз инде. Ашалып бетмәгән ризыгы, дип, коштабак белән он, өч-дүрт ризык куеп, аннары шуларны бирәр ятим карчыкка бирә торганнар иде. Хәзер андый әйбер юк. Мәетне кәфенләгәннән соң кабат ачып күрсәтү гадәте дә юк. Абыстайлар укып, озатабыз.

Хикмәтуллина Рәйханә Кадыйр кызыннан, 1937 елгы.

СӨЕНДЕК АВЫЛЫ

Төш юрау

Ишегалдында каз оясы. Ямь-яшел чирәм. Ике бәбкә утыра. Нәкъ шул төшне ике көн рәткә күрдем. Икенче көнне бер бәбкәне кулыма алуым булды, иии утырасың, дип, жәлләп, бәбкә кулымнан төште китте, үлгән икән, дим. Бу төшне әйбәткә юрамадым.

Үлектән әйбер алу – әйбәт, бирсәң – әйбәт түгел.

Морҗа-мазар күрү – әйбәт түгел, әйбәт булмый инде морҗа җимерек булса, каза килә.

Балык күрсәң, яңгыр ява.

Эт – дошман.

Ат, ул кая да булса алып китсә – үлем.

Сазга бату – әйбәткә түгел.

Елау – сөенечкә.

Тавык – чир инде ул.

Тавык йомыркасы – әйбәт, акчага.

Бау-мазар – юл төше.

Ризык – әйбәт.

Шомырт – әйбәт түгел анысы.

Бук күрү – акчага.

Бакыр акча – начарга.

Яшь бала күрсәң – зыянсыз.

Төш килә ул. Ышанмый булмый. Шуңа юрау бар.

Харрасова Рәсимә Миргалим кызыннан,
1930 елгы.

БҮЛӘК АВЫЛЫ

Бүләктә бәйрәмнәр

Ураза бәйрәме, аннан Корбан бәйрәме уздырабыз. Болары борынгырак бәйрәмнәр инде. Иң зур бәйрәмнәр. Сабан туе, Җыены да шул инде аның – болары бүтән. Хәзер Корбан бәйрәмен ару итеп үткәрәләр. Ураза бәйрәмен өйдә генә үткәрәбез. Коймак, табикмәк пешерәбез. Корбан бәйрәмендә сарык суябыз. Тирә-күршеләр белән үтә инде шунда.

Зәкиева Диларә Миргәгъсүм кызыннан, 1936 елгы.

ЮГАРЫ СТӘРЛЕ АВЫЛЫ

Югары Стәрле авылы турында *(топонимик риваять)*

Стәрле елгасына урнашкан Югары Стәрле. Исеме дә шул елга исеменнән. Элек өч Стәрле булган. Хәзер ике. Югары һәм Түбән Стәрле бар.

Авылга күптәннән нигез салынган. Иң башлап монда мишәр якларыннан килеп урнашканнар, дип сөйлиләр. Шуңа Югары Стәрлене мишәр авылы, дип әйтү дә сакланып калган. Бүген инде монда мишәрлек бөтенләй юк. Телләре йомшарган. Рус дәүләтен кайчандыр нугайлардан саклар өчен патша хөкүмәте күчереп утырткан булган мишәрләрне. Җир биреп.

Вәлиева Гүзәлия Миннесалих кызы, 1976 елгы.

ТҮБӘН СТӘРЛЕ

Бәди күле *(топонимик риваять)*

Түбән Стәрле – Югары Стәрледән күчеп утырган авыл. Аккошлы күл буена өй салып, шунда яши башлаганнар. Ул урыннарны су баса башлагач, түбәнрәк күчеп урнашканнар. Исеме шуңа Түбән Стәрле булып киткән. Ул вакытта әле монда куе агачлык булган.

Революциягә кадәр мондагы таллыкта Николай исемле бай тегермән тоткан. Күл янында гына шушында. Халык монда тегермән тарттырырга йөргән. 1917 елда Бәдигылҗамал исемле хатын шушы Николай тегерменэнә полк онын тарттырырга дип килә. Бәләкәй чанага он салып. Кайткан чагында буранда адашкан, катып үлгән. Шуннан бу урынны Бәди күле дип атаганнар.

Табышмак

Үзе ашыга, үзе ачыга,
Үзе баралмый, үзе таралмый. Җавабы: колхоз.

Шушы сүзне сөйләп йөргән өчен Хәйдәргали исемле бер ирне Бөгелмәгә алып киткәннәр, Бөгелмәгә җиткәнче тау битендә атып үтергәннәр. Тугыз баласы калган. Әләк аркасында шулай булган. Еллары шундый иде бит.

Гаравева Римма Мотыйгулла кызыннан, 1945 елгы.

ҖИҢҮ АВЫЛЫ

«Аллия-гөллия» *(уен-бию җыры)*

Аллия-гөллия дип җырлый идек. Бу – элекке уен. Уенда җырлый торган идек «Аллия-гөллия» дип кабатлап. Парлап басып, тотынышасың парың белән, шулай кулларны өскә күтәреп, капка ясыйлар. Икенче бер пар шул капка астыннан чыга, аларга җырлап торалар «Аллия-гөллия, гөллия тирәккәем», дип. Сүзләре күп инде аның. Матур сүзләр инде, күңелне ача торган.

Аллия-гөллия,
Гөллия тирәккәем,
Сандугачлар сайраганда
Өзелә үзәккәем, дип.

Фәттахова Гөлнәзирә Фәррах кызыннан, 1940 елгы,
тумышы белән Сарлыдан.

Җиңү авылында йомырка тәгәрәтү *(борынгы йолаларны кире кайтару)*

Борынгы йола бу. Балалар белән җыелышабыз. Арадан бер ир бала салават әйтә, укый. Аннары йорттан-йортка йомырка җыялар. Пешкән йомырка. Алдан хәбәр бирелә кешеләргә. Балалар ошатты бу йоланы.

– Игеннәр уңсын!

– Икмәк күп булсын!

– Келәтләр икмәк белән тулсын!

Шундый алгыш-теләкләр әйтеп, өйдән-өйгә йөреп, йомырка җыелып беткәннән соң кырга чыгып, түгәрәкләнеп утырабыз ашъяулык тирәли. Табышмаклар әйтешү китә. Кайсы «мин биим әле», ди, кайсының җырлап күрсәтәсе килә. Иң азакта ашъяулыктагы йомыркаларны тәгәрәтеп җибәрү була:

– Игеннәр мул булсын! – дип.

Альхамова Зөлфия Габделхай кызыннан, 1965 елгы,
тумышы белән Ютазы районы Бәйрәкәдән.

ЧӘКӘН АВЫЛЫ

Чәкәндә «Йөзек салыш» уены

Йөзек саласың да кычкырасың:

– Йөзек салдым, сикереп чык!

Сикереп чыкса, йөзекне үзе сала, сизенеп, тотып калсалар, җәза бирәләр.

Аллар алып, гөлләр сибәм,
Иркәм, баскан эзеңә,
Бакчада үскән гөлләр күк
Күренәсең күземә.

Шулай җырлап куя идек. Җырламасаң, утыртмыйлар кире урыныңа.

Җиһангирова Сафия Миннәхмәд кызыннан, 1947 елгы.

УРМАНАЙ АВЫЛЫ

Герман сугышыннан язылган хатлардан *(фольклорда эпистоляр жанр)*

Биек тауның башларында
Окопларда ятабыз,
Телеграм баганасы
Чәчәк аткач, кайтабыз.

Сызран (Сызрань. – Л.М.) күпере сиксән такта –
Ничек санап үтәрсең?
Сөйгән ярны, туганнарны
Ничек ташлап китәрсең?

Һава зәңгәр, һава зәңгәр,
Ничек зәңгәрләгәннәр?

Варшау каласын биргәннәр,
Ничек жәлләмәгәннәр?

Курка күңелем, курка күңелем
Шул наган тавышыннан.
Барыбер өметем өзмим,
Җаныем, кавышуга.

Шәфыйкова Минсафа Сәеткол кызы (1926–2009) язып калдырган истәлек дәфтәреннән.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АВЫЛЫ

Беренче май *(тарихи хикәят-истәлек)*

Өченче ферма дип йөрделәр элек. Ачлык вакытында 1936–1937 елда кыргызлар тулды монда. Алар кырылды. Монда халык катнаш, күбесе татарлар. Урыслар да күп булды. Колхозга керүдән куркып, байлар килгән монда качып. Бер байның утары булган бу. Яллап эшләткән ул бай кешеләрне. Гали бай булган исеме. Гали агачлыгы – шуннан калган исем. Совхоз оештырганнар монда соңрак. »Беренче май» совхозы булган. Сарык асраганнар. Мин үзем, Галим авылы таркалгач, монда килеп утырдым. Кече Бүләк тә бар иде, ул да бетте шулай. Шул авыллардан килгән кешеләр монда. Бетеп бара «Беренче май». Элек печән бүлгәндә 120 хуҗалык була торган иде. Зираты бар. Мәчет юк. Килмешәкләр монда. Иң беренче күмелгән кеше – Сөббүхнең атасы, 1945 елда үлде. Зират – мөселман зираты, кыргызларны да шунда күмделәр.

Дәүләтов Илгизәр Дәүләтша улыннан, 1931 елгы.

МИТРӘЙ АВЫЛЫ

Митрәй атамалары *(топонимик риваять)*

Митрәй дигән исем шуннан: Дмитрий дигән кеше беренче булып килеп утырган монда. Шул Дмитрий утар тоткан. Эре мал тотканнар. Утарга хәтле урман булган бу җирләр, урман кисеп урын ясаганнар. Күчереп йөрткәннәр малларын. Татарлар, башкортлар, типтәрләр булган монда. Башта авылны Яңа авыл дип йөрткәннәр. Кайсы авыл беткән, кайсы берләшкән бит инде. 1941 елда Митрәй авылы икегә бүленгән булган. Берсе – Сарсаз, икенчесе Чапай колхозы булган. Авыл советы Митрәйдә булган. Митрәй хәзер Әсәй авыл советына карый. Элек монда ике мәхәллә булган. Берсе – зират ягында, берсе – Яңа авыл ягында. Ике зираты бар.

Очлы тау. Очлаеп килгән, биек. Талбүләк калкулыгы белән тигез. Очлы тау – бу тирәнең иң биек урыны. Очлы тау кырыенда гына – *Бур тавы*. Бур чыгарганнар. Саттылар шуны. Бур сатып, колхозга әйберләр

ала торганнар ые. Бур тавы кырыенда – *Давыт чокыры*. Давыт исемле кеше яшәгән анда гаиләсе белән. Өске башында – җиләк, чишмәсе дә бар ые аның, хәзер ул чишмә күмелде. Шунда гына таш карьеры да бар ые. Таштан өелгән кладовой (келәт) бар анда, әле дә саклана. *Пөчти чокыры*. Ник Пөчти – белмиләр. Кеше исеме булгандырмы. Җиләкле урын. Пөчти чокырына чишмәгә баралар ые, чишмә хәзер юк, күмелде. Зур зират. Бик борынгы зират. Ары таба *Шәрәфә карчык чокыры* – шул тирәдә яшәгән ул карчык. Шуңа аның исеме белән атаганнар. Хәзер анда җиләклек. Чишмәсе булган. Хәзер юк чишмә, җимерелеп беттеләр. *Карагаш кулы* (*Карашкул*) – карагай үсә торган чокыр. Анда да куе урман булган, шундагы агачлардан бура бураганнар. *Сарсаз елгасы*. Карагаш ягыннан агып төшә, ул килеп кушыла Стәрле елгасына. Стәрле Стәрлебаштан чыга. *Шалкан тавы*. Шалкан чәчә торган булганнар анда. Шуннан калган исем. *Күҗүнни урманы* – Сарсаз елгасы тирәли. Сарсаз урманны урталай бүлеп ага. Каен, нарат, усак, зирек, шомырт – бар да үсә, катнаш урман. *Дәүләтбай коесы*. Күҗүннидән бер 500 м өстәрәк анда булган кое. Анда хәзер шәхси умарталык тоталар. Дәүләтбай җир тоткан бай булган, шуның исеме белән аталган коесы да. *Гали чокыры*. Карашкул чокырында тагын Гали чокыры бар. Печән чабалар иде элек анда, болынлык иде. Пискунов дигән бояр җирләре булган ул тирәләр. *Карай куагы*. Урманлык ул. Анда агачлык. Чаллыкаран. Кечкенә генә су. Гөрләвектән зуррак. Чишмәләрдән төшә. Ике-өч чишмәдән агып төшеп, җыела. *Таш карьеры*. *Гәрәби чокыры* да диләр аны. Шуның кырыенда гына бер урын бар ые, рус кабере, дип йөртәләр ие. Ветеринар булган ул. Зур олы таш ые каберендә. *Метри чокыры*. Митрәй тирәсеннән читтәрәк анысы. Митрәйгә карамый. Шарлык. Анысы Беренче май белән ике арадагы куаклык. Вак агачлар. Балтырганга, җиләккә шунда йөрделәр.

Латыйпов Әнвәр Хәнифовичтан, 1936 елгы;
Мөхәммәтшин Равилҗан Хәбибҗан улыннан, 1941 елгы;
Галләмов Гаяз Габделгани улыннан, 1940 елгы.

Балыкка барган *(мәзәк)*

Кышкы буран. Суык көн. Таңнан торып, бер ир-ат балыкка киткән. Хатыны йоклап калган. Бара икән, бара икән. Күз ачкысыз буран туктамаган. Ярты юлдан кире борылып кайткан бу. Кайткан да хатыны янына юрган астына кереп яткан. Хатыны сорый икән:

– Ничек анда урамда?

– Салкын, буран!

– И-и, минем дурак балыкка дип чыгып китте шул буранда! – ди икән моңа хатыны.

Мөхәммәтшин Равилҗан Хәбибҗан улыннан, 1941 елгы.

ӘСӘЙ АВЫЛЫ

Әсәй авылы *(топонимик риваять)*

Иштәк буенда башкорт урамы булган монда элек. Шулай дип йөргәннәр башкорт урамы дип. Анда Әсәй исемле карт беренче килеп утырган. Иштәк буеннан шул башкорт урамы дигән исеме генә калган. Әсәй – әни дигән сүз. Бездә инәй диләр. Әллә кайчангы әнә шул вакыйгалар авылга исем булып калган. Әсәй авылы дип йөртәләр борын-борыннан.

Идрисов Зәкуан Идрис улыннан, тумышы белән
Митрәйдән, Әсәйдә укыган, 1965 елгы.

«Кыйссаи Йосыф»тан *(дастан кыйпылчыгы)*

Агалары көнчелек белән коега салганнар Йосыфны. Күлмәгенә эт каны буяп атасына алып кайтып күрсәткәннәр. Аталары бик җылаган. Күзләре сукырайган.

Яңадан ул абыйларын таный бит. Абыйлары моны танымый. Атагызга алып кайтыгыз, дип бүләкләр биреп җибәрә. Атасы шуннан белә бит инде Йосыф турында, күзләре ачылган.

Шакиров Расих Миргалим улыннан, 1942 елгы.

Булат батыр *(риваять)*

Булат батыр исемле гаскәр җитәкчесе булган. Алтын Урда вакытында. Алтын Урдадан Казан ханлыгы аерылып чыккан 1363 елда. Шул Булат батыр җитәкчелегендә. Булат батыр Алтын Урдадан Казан ханлыгын аерып чыгарган. Батыр җитәкче булган. Көчле-куәтле. Әле ул вакытта Болгар ханлыгы булган. Булат батыр дәүләтчелекне кире торгызган. Булат батыр шул Болгардан инде. Без болгарлар, дия иде әни. Бу кем җире? Болгар җире.

Шакиров Расих Миргалим улыннан, 1942 елгы.

УРАЗАЙ АВЫЛЫ

Уразайда Чатыртау чишмәсе *(тарихи-топонимик риваять)*

Уразай авылы башта Аю булган. Аю дигәннәр авылны башта. Урманда аюлар күп булган. Монда таулар, урман тирә-як. Шуңа Уразай кешеләрен һаман да аюлар дип йөртәләр. Аннары тау башына Уразай исемле кеше килеп урнашкан да, шуннан авылның исемен Уразай дип атый башлаганнар. Танылган кеше булган Уразай. Уразай дигән авыллар күп җирдә бар. Безнеке – Чатыртаулы Уразай, Урал тауларының дәвамындагы Уразай. Чатыртау хәзер тыюлык. Чатыртауда куыш бар. Чатыртау үзе чатыр корып куйган формада. Бер ягы – текә, бер ягы – сөзәгрәк.

Чатыр чишмәсенең суы тәмле, аны яратып эчәләр. Ераклардан килеп алалар Чатыр чишмәсенең суын. Бездә чишмәләр күп-күбен. Аларның күбесенең суын эчү юк, катылыгы бик көчле. Ә Чатырныкы эчәргә яраклы.

Лотфуллина Фәйрүзә Миргали кызыннан, 1958 елгы.

Юрган сыру *(йола фольклоры)*

Сарык җонын тетеп эшкәртәләр. Тетү – йомшатып ваклау, аралау. Материалга җәеп куялар. Марляга салырга мөмкин. Ничек телисең, шуның хәтле итеп саласың йонның калынлыгын. Өстенә марля ябып, типчеп чыгасың. Җон күчеп йөрмәслек итеп. Шуннан сырасың. Тыш кидергәннән соң камыт инәсе белән йөреп чыгу сыру була.

Килен өчен дип я китәсе кызга дип әзерләү булган. Матраслар да сырганнар. Тирә-як авылларда сырганнар шулай.

– Тәннәрегез җылыда булсын! Яткан урыннарыгыз йомшак булсын! – дип әйтеп бирәләр киленгә.

Юрганны җоннан гына түгел, мамыктан да сыралар. Ул шулай йомшак була! Казның мамыгын гына алып ясау була ул мамыктан сыру.

Юрган сырганда өмәсез булмый, өмә ясыйлар. Күпләп утыралар.

Бәдретдинова Сания Дәүләтша кызыннан, 1957 елгы,
тумышы белән Мөслим районы Чакмак авылыннан.

Палас туку өмәсендә *(йола фольклоры)*

Җонны җегерләп, эрләп инде, төрле төсләргә маналар. Олы туку станогы була торган ые. Шунда тукыйлар келәмне. Олы палас булса, ике яклап эшлиләр. Өмә ясап тукыганнар. Өмә булгач, җырсыз булмаган.

Очраштык без өмәләрдә
Кавышырбыз, диеп яренгә,
Кавыша алмадык, гафу ит инде,
Бик күп гомер үтте бит инде.

Солдатка алганнар да, кавыша алмый калганнар. Ярәшелгән кызлары шуларга багышлап җырлаган.

Каурый сыдыру өмәсе *(йола фольклоры)*

«Каз сыдыру» өмәсе Каз өмәсеннән соң үткәрелә. Каз йолкыганда каурыйларны җыеп калдыралар бит, шуларны сыдырырга җыелышалар. Каурыйдан сыдырган мамыкны мендәр кабарсын өчен кушасың. Сыдырылганнан калганын юл буена сибәләр.

– Киләсе елга казлар мул булсын! – дип әйтә торган ырымы да бар сипкәндә. Шулай тели-тели сипсәң, казлар киләсе елга да уңа. Каурый сыдыру өмәсеннән соң бәлеш пешерү була. Биюләр була торган иде туера табан төшкәнче.

Әхмәтҗанова Гөлфия Мөхәммәтша кызыннан, 1952 елгы.
Тумышы белән Азнакай авылы Чуар Абдул авылыннан.

ЗУР СУКАЕШ АВЫЛЫ

Елан *(тыю)*

Елан. дип әйтергә ярамый. Урманга барсаң, «ул» дип сөйләшү кирәк.

Закирова Зөлфия Җәүдәт кызыннан, 1964 елгы.

ҮЧӘЛЛЕ АВЫЛЫ

Убыр *(мифик риваять)*

Убыр килеп ала тыңламасаң, диләр иде. Әшәке җен карчыгы, дип уйлый идек. Утлы шар булып әверелә, диләр иде. Зираттан чыга иде.

Ибраһимова Мәүлидә Гарифулла кызыннан, 1937 елгы.

КАРАМАЛЫ АВЫЛЫ

Мәдрәсәдә *(сөйләк)*

Без кечкенә вакытта әни безгә үзләренең мәдрәсәдә укыганнары турында сөйли иде. Җәдит мәдрәсәсендә укыган. Сәпәй мәдәрәсе, дип сөйли торган иде, шунда укыган.

Каргалар качты, козгыннар качты,
Яңа хәяткә яңа юл ачты.
Кадимнәр калды, юлы каралды,
Черегән нигезе
Тузды, таралды.
Әни сөйли иде шушы шигырьне.

Хәйдәров Әхмәтгали Әхмәдиша улыннан, 1934 елгы.

Л.Мөхәммәтҗанова Иректе авылында информантлар белән

Л.Р. Камалиева

СЕҖЕ АВЫЛЫ

Республикабызның Арча районындагы Сеҗе авылы бик зур булмаса да, үзенең матур табигате, эшчән һәм акыллы кешеләре белән бу төбәктә туып-үскәннәрдә генә түгел, вакытлыча яшәп, эшләп киткән белгечләр күңелендә дә зур эз калдырган авыл.

Элек авыл карчыклары, көтүләр кайтып, кичке эшләр беткәч, берәрсенең капка төбенә җыелышып, бүрәнә өстенә тезелешеп утырып, биләй-носки бәйли-бәйли, узган көн вакыйгаларын йомгаклап, иртәгесе эшләрне бәһаләп утырырга ярата иде. Шунда, үзләре дә сизмәстән, үткәннәрне дә искә төшереп, төрле вакыйгалар эченә кереп китеп, фикер алышып, кайсы-берен ачыклап, кайберләрен тәнкыйтьләп яисә бәяләп тә алалар. Ә без, балалар, колакларны торгызып, кайбер кызык вакыйгаларны хәтергә сеңдереп утырабыз.

Географик урыны

Авыл район үзәге Арчадан 25 км төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасының (Казансу кушылдыгы) борынгы сул як үзәнендә урнашкан. Килеп җитмичә, алда авыл барлыгын күрмисең. Бигрәк тә Чүриле ягыннан килгәндә, авылыбызның «символы» булган «Әһли наратлыгы» гына күренә. Ул наратларны XX гасыр башларында, йортлар шунда булу сәбәпле, Әһлиулла абзый утырта. Димәк, наратларга 100 ел, дияргә була. Шул наратларга карап барсаң, туп-туры авылга килеп керәсең. Чүриледәге тимер юл стансысы авылдан 6 км ераклыкта булыр. Көньяктан авыл башына кадәр Арчадан асфальт юл килә. Юлның дамбасы 1980 нче елларда төзелә, 1994–1995 елларда асфальт белән каплана. Казанга тимер юл буенча – 88, асфальт юл буенча – 100 км. Сеҗе – Мөрәле, Ташкич, Яңа Көлич, Пүник пүчинкәсе (Күченгән Пүник дигәнне аңлата) һәм Яңа Чүриле (19.02.44–15.05.56 елларда район үзәге) авылларын берләштергән җирле үзидарә үзәге. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, медицина пункты, кибетләр, мәчет бар.

Сеҗе Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. XVII гасырда һәм XVIII гасырның беренче яртысында халкы дәүләт крестьяннары категориясенә карый. 1920 елга кадәр авыл Казан губернасы, Мамадыш өязе, Яңа Чүриле волостена керә. Кызыксынучылар өчен: Яңа Чүриле волосте үз эченә 25 авылны ала: Курса-Почмак, аның бу ягы, Шәмәрдән һәм тимер юлның теге ягындагы авыллар (1910 нчы елгы Мамадыш өязе картасы). 1920 елдан – Мамадыш, 1922 ел башыннан – Арча кантоннары составында. 1930 елның 10 августыннан Арча, 1944 елның 19 февраленнән

Чүриле, 1956 елның 14 маеннан яңадан Арча районы (1956 нчы елны бер генә ай Саба районына кереп тә ала). 1782 елда 58 ир-ат исәпләнә; 1859да барлыгы 304, 1897дә – 540, 1908дә – 610, 1920дә – 748, 1926да – 615 кеше, 1989да – 277, 2002дә 293 кеше яши.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Борынгы заман

Тел галиме, филология фәннәре докторы Фирдәүс Гарипова үзенең «Авыллар һәм калалар тарихыннан» дигән китабында [Гарипова: 2003. Т. 2] болай дип яза: «Сеҗе – борынгы авыл. Аның исеме Казан ханлыгы чоры авыллары исемлегенә кергән [Чернышев: 1971. С. 288]. Д.А. Корсаков чыганагында (XVIII гасыр) авыл Мурья Мусич исемендә бирелгән һәм анда 58 ясаклы татар яшәгәне әйтелгән [Известия. Т. 18. Вып. 4–6: 1908. С. 132, 256]. А. Артемьев җыентыгында авыл Мурья Мусич (Сизе) дип билгеләнә һәм андагы 49 хуҗалыкта 156 ир-ат һәм 153 хатын-кыз көн иткәнлеге әйтелә. Авылда мәчет эшләгән [Артемьев: 1866. С. 65]. И.А. Износков хезмәтендә (XIX гасыр) авыл Мурья Мусич-Сизе дип бирелә. Ислам дине тота торган 191 ир-ат һәм 189 хатын-кыз көн иткән [Износков: 1884. С. 132]. К.П. Берстель авылны Мурья Мусич (Сизе) дип атый һәм анда барлыгы 541 татар кешесе яшәгәнлеген теркәп куя [Брестель: 1908. С. 86].

1890 нчы елда салынган икенче мәчет.

Күп тапкырлар кабатланган «Мурья Мусич» атамасының «Мусич» сүзе Муса исеменнән русчалатып үзгәртелгән. Авылның исеме турында берничә караш бар. Берсе буенча ул Иске Му авылыннан килгән һәм Мусич фамилиясе алдыннан аның чыккан урыны әйтелгән – Му, ягъни Му-

рия. Икенче төрле караш та бар: Мусич Мөрәле авылыннан, ягъни Муриядән килгән, биредә тегермән салган, аңарчы анда удмуртлар (арлар) солы иккән. «Сеҗе» сүзе удмуртча «Солы» дигәнне белдерә, удмуртча ул «Сезьы» дип языла, ә татарча «Сеҗе» дип язылып киткән булырга тиеш. Шулай итеп, Мурья Мусич атамасының төрдәше – Сеҗе атамасы барлыкка килә.

Р.Ә. Әсретдинова да моны удмуртлардан ачыклады. «Сеҗе» сүзе шул ук удмурт телендә «уйсулык, үзәнлек, чокырлык, батынкылык» мәгънәсен дә йөрткән, дип яза Әхмәт абый Әсретдинов. Бу мәгънә авылның урынын дөрес чагылдыра. Шул ук Әхмәт абый: «Вл. Даль үзенең аңлатмалы сүзлегендә «Мурья – лачуга (алачык, кечкенә өй), землянка, конура, тесное и тёмное жильё, пещерка», дип яза», – ди. Татарча ул «Муса яши торган урын, Муса өе», дип тәрҗемә ителә. Димәк, авылның «Мурья Мусич» дигән борынгы атамасы рус телендә бирелгән. Чынбырлыкта, Муса бабабызның кайсы яктан килеп урнашуы билгесез. Гомумән, авылда хуҗалыклар саны артуны бер Муса бабай гына тәэмин итмәгән, әлбәттә, авыл төрле яклардан күченеп килгән аерым кешеләр яисә гаиләләр исәбенә арткан. Татар халкының миграциясе бигрәк тә 1552 елларда Казан ханлыгын Иван Грозный биләп алгач көчәя. Татарлар Казаннан читкә куыла. Элек авылда арлар (удмуртлар) гына түгел, чирмешләр (марилар) дә яшәгән. Моны табигать объекты булып калган «Кирәмәт елгасы» гына түгел, ә Мөрәле як зират турысында, юлның икенче ягында безнең заманга кадәр сакланган «чирмеш зираты» калдыклары да дәлилли. 1942 елда зират агачларын кистереп, «Озын Сәлахи» Мөрәледә күпер салдыра. Шул вакытта субай сукканда бер кеше егылып төшеп үлә. Зират рәнҗеше, ди халык моны (Хаҗирә апа сөйләгәннәрдән).

Татарлар күпләп килеп утыра башлагач, марилар һәм удмуртлар кебек угыр-фин кабиләсе вәкилләре төрле якларга – Мари, Балтач якларына китә, икенчеләре Ислам дине кабул итә. Татар Милли архивында диннән-дингә күчүчеләр турында мәгълүматлар очрый.

«Безнең тирәдә яшәгән халыкларның 2 утары була», – дип сөйли Сәхрәгөл апай. Әсретдинов Әхмәт абый сөйләвенә караганда, аның берсе – татарларныкы, Кесмәс елгасы буйлап ике яклап тезелешеп урнашкан. Төрле милләт, төрле дин кешеләре үзара аралаша башлагач, алар арасында төрле каршылыклар, ызгышлар килеп чыккан булырга мөмкин. Бәлки татарлар шуңа күрә таулы-чокырлы һәм елга буендагы сазлыклы урыннарга утырырга мәҗбүр булгандыр, бәлки ул заманнарда күп җирләр урманнар белән капланган булу сәбәпле, иркенләп утырырга җир булмагандыр, яисә алар алданрак килеп, су буйларын – яшәү чыганагын үзләре биләп алгандыр – алары безгә мәгълүм түгел. Белгәнебезчә, бик

борынгы мәҗүси халыклар күбесенчә урманнарда яшәп, табигать биргән азык белән тукланып торган, аучылык иткән, балык тоткан. Ул вакытта әле иген икмәгәннәр, Россиядә бәрәңге дә булмаган.

«Икенче утар, – дип сөйли Сәхрәгөл апай, – «Алпавыт басуы» дигән урында була». 1552 елдан соң Рус дәүләте Казан краен хәрби көчләр ярдәмендә басып алуын дәвам итә һәм ул ярты гасырга сузыла, аннан соң үз дәүләтен тыныч юл белән ныгыта башлый. Бу эш өч юнәлештә бара: безнең якларга рус кешеләрен күчереп утырту, Мәскәү дәүләте строен урнаштыру һәм башка милләт халыкларын көчләп христиан диненә кертү. Бу турыда Рычков, Рыбушкин, Бажанов, Соловьёв һ.б. авторлар борынгы язу кенәгәләре һәм монастырь кенәгәләре нигезендә күп кенә тарихи китаплар язып калдырган.

Рус дәүләтендә зур дәрәҗәгә ия булган борынгы кенәз һәм бояр вәкилләренең күп булуы Явыз Иванны бик борчый һәм ул алардан котылу чарасын таба – яңа яулап алынган җирләргә – безнең якларга җибәрә. Шул максаттан аларга уңдырышлы җирләр, җәнлеккә бай урманнар бүлеп бирелә, рус утарлары, пүчинкәләре барлыкка килә. Тора-бара алар Казан краенда танылган воеводалар һәм эре җир биләүчеләргә әверелә. Казан каласы да зурая. Ә Мәскәү, Псков, Новгород, Суздаль, Ярославль кебек борынгы шәһәрләрдән сөрелгән кешеләр Казанда махсус урамнар хасил итеп утыра.

Сөрелгән кешеләр арасында һөнәрчеләр булмый, алар барысы да эре сәүдәгәрләр яисә промышленниклар. Алар түләгән салым Казан казнасын баета. Казан – Рус дәүләтенең әһәмиятле хәрби пункты да була – як-якта бит дошманнарча мөнәсәбәттәге башка милләтләр, алар еш кына сугыш ача, бер-берсенә һөҗүм итә. Шуңа күрә укчылар, тупчылар, сакчылар, барабанчылар, атлылар, пехотачылар һ.б. бик күптөрле вазыйфа үтәүче гаскәриләр кирәк була. Регуляр атлы гаскәр сафларында, гадәттә, бояр балалары тора, ә татарлар һәм яңа чукындырылган керәшеннәр кирәк вакытта гына атлы гаскәргә алына. Регуляр гаскәриләр казнадан берни дә алмый, азык һәм фураж турында үзе кайгырта. Алар кулында күп җирләр була, бояр уллары сугышка барырга ашкынып тормый, акча йә бүләк биреп, патша шымчыларының йөрәген йомшарта белә. Боярлар, гомумән, сугышчан халык булмый, тыныч тормыш эшләрен артык күрә. Сугыш вакытында аларга 1–2 атлы ялчы бирелә.

Казан краен саклау өчен Казанда 2 укчы полк тора. Бу – Рус дәүләте өчен яңа күренеш, гаскәр туплау тәҗрибәсе булмый, шуңа күрә очраклы кешеләр – батраклар, йортсыз-җирсез крестьяннар, «тик йөрүчеләр» хезмәткә тартыла. Аларны казна исәбенә тоталар. Сугыш булмаганда укчылар бәйрәмчә яши, буйсынмаучан һәм гаугачан була, күбесе кон-

трабанда белән шөгыльләнә һәм пошлина түләмичә сәүдә итә, ә бу исә сәүдәгәрләргә зур зыян китерә. Аннан тыш укчылар трактирлар тотып, яшерен аракы сату белән дә шөгыльләнә, үзләренең бердәм һәм көчле булулары белән дәүләт кешеләрен куркытып тора. Укчылар арасында төрле милләттән төрле сыйфат-фигыльле кешеләр була. Татарлардан да 7 кеше исәпләнә. Укчылар шәһәр читендәге бистәләрдә яши. Һәр полкта 300ләп кеше була. Алар община булып яши, күчемсез милеккә хуҗа була алмый. Кораллары – озын саплы балта (секира), кылыч, сөңге һәм авыр мылтыклардан (пищаль) тора.

Укчылардан кала түбәнрәк сословиегә керүчеләр – тупчылар һәм артиллериягә хезмәт күрсәтүче тимерчеләр, балта осталары, ат караучылар һ.б. хезмәтчеләр дә төрле милләт вәкилләреннән тора. Аларның күбесе кушамат белән йөртелә.

Россиядә сугышлар, бунтлар гел булып тора. Пугачёв баш күтәргәч, 1774 елның 1 гыйнварендә Казан дворяннары үз хисапларына коралланган атлы корпус оештыру турында карар чыгара. Гаскәрне һәр 200 кешедән берәр рекрут җыю исәбенә туплыйлар. Аларга палашлар – озын авыр кылычлар һәм пистолетлар бирәләр.

Рекрут хезмәте турында Россиядә Указ 1699 елда чыгып, 1705 елда гамәлгә кертелә. Мәскәү Указы нигезендә рекрутлыкка алыну община тарафыннан тәкъдим ителә. Рекрут бурычы барлык ясаклы сословиеләргә дә төшә. Баштарак рекрутлыкка алынучы гомер буе солдат буларак хезмәт итәргә тиеш була, крепостной бәйлелектән азат ителә; 1793 елдан – 25 ел хезмәт итә. 1834 елдан – 20 ел, 1855–1872 елларда хезмәт срогы 12, 10 һәм 7 елга кадәр киметелә. 1708 нче елга кадәр 17 яшьтән 32 яшькә кадәр, соңрак, 20 яшьтән 30 яшькә кадәрлеләр алына. Россия Указы буенча һәр 20 хуҗалык 1 рекрут бирә торган була. 1840 нчы елларда һәр наёмщикка 485 сумлык зачёт кенәгәсе ачыла, шуны сатып алырга мөмкинлеге булган кеше рекрутлыктан котыла, үзе урынына икенче кеше сатып алып җибәрә ала. 1874 елдан рекрутлык гомуми хәрби повинностька алышына – 21 яшьтән алынып, 6 ел (флотта 7 ел) армиядә хезмәт итә һәм 9 ел запаста тора. Хезмәт итү сроклары еш кына үзгәртелеп тора.

Безнең авылда рекрутлыкка алынучылар:

1828 ел – Шәмсетдин Әмиров, 32 яшьтә, 25 елга алына;

1836 ел – Мозаффар Мостафин, 19 яшьтә 20 елга алына (Камали нәселеннән);

1833 ел – Халит Даутов, 20 яшьтә, 25 елга алына;

1828 ел – Мортаза Бикмаметов, 24 яшьтә, 25 елга алына;

1820 ел – Бактыбай Вәлитов, 19 яшьтә, 25 елга алына;

1825 ел – Сәетдин Манасыпов, 19 яшьтә, 25 елга алына;

1849 ел – Шәрәфетдин Сәйфуллин, 20 яшьтә, 20 елга алына (бу йорттан икенче рекрут – Шәмсетдин Әмировның пләмәше).

1845 ел – Насыйбулла Халитов, 26 яшьтә, 20 елга алына.

Биктимер Гомәровның 3 улы:

1823 ел – Ихсан Биктимеров, 19 яшьтә, 25 елга алына;

1835 ел – Исхак Биктимеров, 29 яшьтә, 20 елга алына;

1855 ел – Шаһиҗиһан Биктимеров, 30 яшьтә, 12 елга алына, хатыны кала.

Искәндәр Ишкенинның 2 улы:

1835 ел – Исхак Искәндәров, 21 яшьтә, 20 елга алына;

1848 ел – Мөхәммәтҗан Искәндәров, 21 яшьтә, 20 елга алына.

Даут Актыковның (Актыкбаев дип тә язылa) 2 улы:

1853 ел – Баязит Даутов, 26 яшь, 20 елга алына;

1848 ел – Хәмидулла Даутов, 21 яшь, 20 елга алына.

Отставной солдат Сәйфи Байтаев улы:

1855 ел – Таҗетдин Сәйфиев, 25 яшьтә, 12 елга алына.

[Бу мәгълүматлар Татарстан милли архив 3 фонд; 2 опись, 73, 225 һәм 339 нчы делоларда 1834, 1850, 1858 нче еллар өчен күрсәтелде. Үзенең «нәсел агачы» белән кызыксынучылар бу архив материалы белән эшли ала].

«Җир җирәбә салып бирелә. 1899 нчы елда берничә нәселгә – Әдһәмнекеләргә, Мортазаныкыларга, Ихсанныкыларга, Әхмәдинекеләргә һ.б. җир эләгә», – дип яза Ә. Әсретдинов. Авылның 1882 елда сызылган планына күз салсак, авылның хәйран зур икәнлеген, берничә урамнан торганын күрәбез. Номерлары йорт хуҗалыгына туры китереп исемлек төзелгән, запас участоклар да номерланган һәм күрсәтелгән. Ләкин Чүриле волосте писаре төзегән исемлектәге исем-фамилияләрне укуы бик кыен, авыл старостасы бер төрле итеп татарча әйткәнне урыс писаре аны үзенчә үзгәртеп, русчалатып язып куйган. Шуңа күрә архив материаллары бик авырлык белән укыла.

Җир 12 елга бер мәртәбә генә бүленә. Бик теләгән кеше икенче кешенең шәхси җирен сатып ала ала. Шулай итеп, урамнар хасил була, хуҗалык җирләре киңәя, каралты-кура төзелә, бакчалар җәелә, авыл зурая. 1858 елгы ревизия материалларында Сизедә (икенче җирдә «Сизи» дип тә язалар) 41 гаилә теркәлгән, ир-атлар саны – 259, хатын-кызлар – 152. 1887 елда – 71 хуҗалык, ирләр – 259, хатын-кызлар – 232. Гаилә башы булган ир-ат – авыл сходы (җыены) члены. 4 гаилә җирсез, ир-ат булмаса, аның җире юк. 37 хуҗалык үз инвентаре белән җир эшкәртә, 32 хуҗалык ялланып эшли. Кызганычка каршы, аларның исемлеге китерелми. 2 йортта ялгыз карчык яши.

Авыру яисә бик ярлы кешеләргә волостьтагы «Кызыл хач» кайгыртучанлык җәмгыяте бүлекчәсе һәм Казан губерна земствосы матди ярдәм күрсәтә. Аңа түбәндәге әйберләр кирә: сары май, такта чәй, шикәр, крендель, арыш оны һәм крупчатка, йөзем, как, шырпы, керосин, манный ярмасы, ипи, тоз. Җирсез крестьяннарга акчалата да ярдәм күрсәтелә [Татарстан милли архивы. Ф. 81. О. 2. Д. 782, 783]. Биредә кемнең нинди ярдәм алуы турында исемлек бар, исемлектә – 36 кеше, ярдәм фәкать олылар санына карап кына бирелә.

Революция еллары

1905–1907 елгы Рус революциясе җилләре безнең якларга да килеп җитә, халыкның зиһенен уята, күзен ача. Патша хөкүмәте дә халыкка кайбер демократик ирекләр бирергә мәҗбүр була. Авылның хәллерәкләре үз балаларын якын-тирәдәге мәдрәсәләргә укырга бирә: Камалетдин Вахитов, Кәрим, Габдерахман, Рөфәгать, Ләбибә, Гандәлиф Яхиннар, Фазыйл мулла балалары Курса мәдрәсәсендә; Әсретдинов Бәдгытдин (Гөлебшан атасы), Һадиев Газиз (Газизова Мәдинә атасы) Саба ягы Сатыш мәдрәсәсендә укый. Шуңа күрә дә аларның имзалары архив материалларында ап-ачык булып ярылып ята. Газиз, Камали, Кадыйров Сабир, Җамали бабай (Гайфи атасы) солдат хезмәтендә унтер-офицер чины ала. Ул вакытта солдат хезмәте – 5 ел.

Гражданнар сугышы елларында да авылдан хәрби хезмәткә китүчеләр күп була. Мәсәлән, Вахитнекеләрдән – аның оныгы Габдерәүф (Байракның бабасы), Әсретдиннекеләр, Җиһаншаныкылар һ.б. Ул еллар ачлык, тиф белән дә атаклы. Фәһметдин ага сөйли иде: «Казан бүлнисләре, госпитальләр яралы һәм тифлы кызылармеецлар белән тулы. Бөтенесе диярлек үлеп бара. Мин дә үземнең Гыйззениса сеңлемнең ире Габдерәүф кияүне җеназалап, Яңа Бистә зиратына илтеп җирләдем. Яшь хатыны тол, 1 яшьлек кызы Фәхрелбәнат ятим калды».

Гражданнар сугышы турында Шәмгун абый хатирәләре дә гыйбрәтле. Аның атасы – Мифтахетдин бабай Җиһанша улы Беренче Бөтендөнья сугышында катнашып, революция «боткаларын» да татый. Гражданнар сугышында да катнашып, немец офицерлары белән йөзгә-йөз килеп, аларның погоннарын йолкып алган вакытлары да була. Сугыштан кайтып өендә 3 көн тора – хәрбиләр килеп, Габделбәр абый белән икесен тотып, Мамадышка озата. Хәрбиләр – аклар армиясен тупларга дип авыл саен кеше җыеп йөрүчеләр икән. Өенә кайтып җиткәнче үк аклар кулына эләгәчәге турында поездда кайтканда бер кызыл офицер аны кисәтә, үзенә денщик булырга тәкъдим итә, ләкин Мифтах абыйның өенә кайтасы килә. Мифтах абыйның бер ир туганы, казармадан тизәк чиләген чыгарып түкмәгән өчен, ак офицерның камчысыннан бер күзен

югалта. Моның күзе атылып чыкканны күргән солдатлар, офицерларны кулга алып, үзләренчә суд ясый, ә бер күзсез Җиһаншин армиядән качып авылга кайта. Ләкин аны да тотып алып китәләр. Ходайның рәхмәте, ике Җиһаншин бер полкка эләгеп, аклардан качып кызылларга килеп керә, чөнки авылга кайтудан мәгънә юк. Болар Азин армиясенә эләгә һәм Оренбург якларына җибәрелә. 1918 нче елда Мифтах абыйга 24–25 яшьләр була.

Җиһанша бабайның төпчек улы Ахунҗан да бөтен сугышларда катнашып, өенә кайтып барганда, бер Краснодар бае үз якларын мактап, күндереп, моны көньякка алып китә һәм кызын аңа кияүгә бирә. Шулай итеп, Ахунҗан агай Афанасий Михайловичка әверелә, 5 баласы туа. Үсеп җиткәч, уллары авылга кайтып йөри. Үзе бала чактан ук гармун уйнарга өйрәнә, армиягә китүче авыл егетләре аны чанага утыртып, өйдән-өйгә тартып йөрткән.

Гражданнар сугышы беткәч, Мифтах абый Себергә барып акча эшләп кайта да, атасыннан калган 2 катлы йортны сүтеп, 6 почмаклы итеп 2 якка караган зур өй сала. Ул сугыштан винтовка һәм 40 патрон алып кайта. Район уполномоченныйлары авыл саен йөреп, йорт саен кереп, корал җыеп йөри, ә патроннарны таба алмый. Соңрак ул патроннарны тегермән бөясендә шартлатып, малайлар балык «глушить» итә.

Мифтах абый белән Габделбәр абый кызылларга каршы фетнәдә катнашуда гаепләнеп, кулга алына. Аларны хәзерге артиллерия училищесы казармасына ябып куялар. Бервакыт үзләрен тезәләр дә, һәркемнән фамилиясен, взводын сорыйлар. Взвод номерына карап төрлесен төрле төркемгә аералар. Бер төркемне шунда ук ишегалдына алып чыгып аталар. Боларныкы кала.

Фәһметдин абый Әсретдинов Оренбург ягында хезмәт итә. Шулай бервакыт 20 кеше разведкага китә. Разведчиклар арасында Җиһанша бабайның да бер улы – Фазыйл була. Гомумән, аның 4 улы да Гражданнар сугышында катнаша. Җиһанша бабай турында, сүз уңаеннан, шуны да әйтеп үтү урынлы булыр – аның 14 баласы була (9 малай, 5 кыз). Беренче хатыны кечкенә балаларын калдырып, яшьләй үлеп китә, икенче хатыннан да балалар була. Иң олы бала Маһиҗамал тәтә (Мортаза Заһрие карчыгы, Ибнеәмин анасы) кечкенәләрне – Хәким, Фатыйма һәм башкаларны карап үстерә. Разведкага киткән 20 егетнең берсе генә исән калып, кире отрядка әйләнеп кайта. 19 егетне тураклап бетерүчеләр аклар булмый, басмачылар була. Алар безнекеләрнең атларын җыеп алып китә. Бу хәбәрне алгач, безнең атлы гаскәр дошманнарга каршы чаба. Фәһметдин абый туракланып беткән егетләр арасыннан Җиһанша улы Фазыйлны таба алмый, калганнарны шунда җирләп калдыралар.

Авыл егетләре ул елларда Оренбург якларында гына түгел, Украина, Кырым, Кара диңгез буйларына барып җитә. Махно белән дә сугыша, Кырымда Врангель гаскәрләренә каршы тора, Көньяк Украинада деникинщинаны бастыруда катнаша, тәүлегенә 60 км араны җәяү үтәргә туры килгән чаклар була, кылычтан, пулядан, тифтан кырыла алар. Шәкүр абый, мәсәлән, Будённый гаскәрендә сугышып, аяксыз кайта, аның каравы күп кенә медальләр белән бүләкләнә, ләкин пенсия алмый.

1920 елда Татарстанга автономия бирелә, 20 августта Татнаркомпрод (Татарстанның азык-төлек буенча Халык комиссариаты) продразверстка үткәрү турында карар чыгара, авылларга продотрядлар җибәрелә. Хөкүмәт башында торучылар «дөнья революциясен коткарырга кирәк», дип, халыктан азык-төлек җыя. Хәтта печән дә җыялар. Шуның өстенә 1920 нче елның җәендә корылык та була. Ул елны эт, мәче, әтәчләр күренми генә түгел, аларның тавышы да ишетелми. Баздан кеше башлары табып алган очраклар да була. Авыр Гражданнар сугышы, ачлык еллар үтеп китә, илдә Совет власте урнаша башлый. Старосталар бетә, иң соңгы староста – Таҗетдин улы Садретдин. Ярлылар комитеты (комбедлар) оеша, аның председателе итеп Шаһиҗиһан улы Әшрәфҗан сайлана. 1920 нче еллар ахырында инде авыл советлары формалаша булса кирәк.

Сугыш афәтенә ачлык өстәлә. 1921 нче елгы ачлык безнең якларны да читләтеп үтми. Бер гаиләнең хуҗасы сугышка китә, хатыны, 2 баласы кала. Өйдә запас булмый. Кыш. Ашарга бернәрсә дә юк. Төнлә белән боларга бер ир-ат килеп керә дә, «кайсысын?» дип сорый. Хуҗа хатын: «Кызны, анысы итчәнрәк», – ди. Ә кечкенә малай мич эчендә йоклап ята. Ярым йокымсырап яткан 12 яшьлек Бәдәр, боларның сөйләшкәнен аңлап җиткермәсә дә, пычак кайраган тавышка йокыдан уянып та китә, тәрәзәгә тартылган карындыкны тибеп тә төшерә һәм кышкы төндә, шашкан җәнлектәй калтыранып, күршеләргә барып керә. Ачлыктан, чарасызлыктан акылы зәгыйфьләнгән ана мичтән кечкенә улын өстерәп чыгарып сугымчыга бирә. Баланы шунда ук суеп, пешереп ашыйлар. Бәдәр авылдан чыгып китә. Шул китүеннән тиз генә әйләнеп кайта алмый. Шулай да, еллар үтеп, карт әби булгач, Оренбургтан үзенең карты белән туган авылына кайтып китә. Бу хәл бездән ерак түгел күрше авылда була...

Сәяси үзгәрешләр белән беррәттән, кешедә психологик үзгәрешләр дә бара. Мәсәлән, Әсретдинов Бәдегытдин, бер төркем гаиләләр белән килешеп, хөкүмәт кешеләре белән сөйләшеп, Починок Поник басуы артындагы урман эченнән җир бүлеп алу хокукына ирешә һәм берничә

хуҗалыктан торган бу төркем – Шәрәфиев Латыйп, Мортазин Бәдретдин, Хөснетдинов Шәех, Рус Понигыннан – Алексей һәм Василий Никитиннар, Яңа Чүриледән – Мелюшин Николай, соңрак безнең авылда тегермәнче булып торган Дорофеев Александр һәм тагы берничә хуҗалык яңа җирләргә күченеп утыра, утарга «Маркс» дип исем бирелә. Халык биредә яхшы яши, ләкин мондый яшәү рәвеше Совет хөкүмәте мәнфәгатьләренә җавап бирми һәм утар 1930 нчы еллар уртасында тарала. Гаиләләрнең төрлесе төрле якка китә. Кайберләре урман эчендә урнашкан кечкенә генә авыл – Гарь-Хуторга күченә. Әле бүген дә халык телендә «Маркс басуы» дигән атама яши. Кеше анда гөмбәгә, җиләккә йөри, печән чаба. Хәзер инде Гарь-Хутор да, аның янәшә-тирәсендәге кечерәк авыллар – Тырыш, Ирек тә юк.

Колхозлашу чоры

1930 нчы еллар якынлаша. Бу чор тарихка күмәкләшү чоры булып кереп кала. Авыл халкы 1932–1933 елларда колхозга кереп беткән диярлек. Бу эш шома гына бармый. Колхоз берничә тапкыр оешып, берничә тапкыр таркала. «Колхоз оештыру җиңел булмый. Саба районыннан килгән яшь укытучы Вәлиева Сара, балаларга мөстәкыйль эш биреп, үзе колхоз турында берни белмәсә дә, халыкны колхозга керергә өндәп йөри – район күрсәтмәләрен үти», дип сөйли Фәһмиева Гөлниса апай. Ул вакытта колхоз турында нинди генә әкиятләр сөйләнми – маллар да, өйләр дә, ир-хатыннар да, балалар да уртак булачак, имеш, диелә. Ике яклы көрәш бара: бер якта – ярлылыктан котылу чарасын эзләп, ирекле рәвештә колхозга керергә теләүчеләр; икенче якта – аңа каршы торучы, аерым хуҗалык алып баручы таза тормышлылар. Мондый гаиләләрдә таза-таза ирләр бар. Мәсәлән, Кадыйрныкылар кайберәүләрне язган гаризаларын кире алырга үгетләп карый. «Ә Мәдиярнекеләр, – дип сөйли Галиев Әхмәт абый, – кул уйнатырга да күп сорамый. Аның уллары безнең әтине, башына арба кендеге белән сугып, үтерергә теләгән. Аны «Озын Сәлахи» Чишмә елгасыннан табып алып, ватылган сөякләрен чүпләп, ярасын бәйләп, ярдәм күрсәтә һәм үлемнән алып кала». Акыллы әби-бабайлар исә агымга каршы бармаска үгетли. «НКВДдан 12 кешене раскулачивать итәргә», дип нәрәд килә», – ди Әхмәт абый Галиев. Ә Кәшиф абый Латыйпов – 26 кешегә нәрәд килә, ди. Бер Ахун бай сөрелә, башкаларны халык яклап, алар китеп бетсә, безгә кем эш бирер, дип, каршы чыга.

Ахун байның тарихы болай. Ул үзе бик эшчән, бик коры һәм кырыс кеше була. Беркөнне ике шаян – Гөлҗиһан белән Гөлниса моңар нидер әйтә, күрәсең, һәм Ахун абый боларны тотып пешермәкче була, телләрегезне кисәм хәзер, ди. Балаларның коты чыгып, кайсы кая кереп

кача. Ахун бай эшкә кеше яллап баемый. Авылда аннан да баераклар була. Бай дип, ул кадәр бай да түгел инде, әмма таза тормышлы. Ахун байның оныгы Суфия үзенең Магнитогорскидан җибәргән хатында болай дип яза: «Ул 1886 нчы елда Сеҗедә туа. Урта хәлле крестьян санала. 30 нчы елларда авыл яшьләре гармун уйнап авыл буйлап йөри торган була. Бер кичне авыл активистының улын тотып кыйныйлар. Моны бабай оештырган, дип уйлап, аны кулга алалар һәм төрмәгә ябалар да, Беломор-Канал төзелешенә җибәрәләр. Ул анда 1938 елга кадәр була. Үзе тоткында вакытта, 1931 елда гаиләсен сөрәләр, башка авыллардан җыелган крестьяннар төялгән товарный вагонга утыртып, Магнитогорскига җибәрәләр. Алар күп газаплар күреп, 8 көннән соң Магнитогорскига барып җитә». Илдә зур төзелешләр бара – Ахун бабай Беломор-Канал төзүдә катнаша, 1929–1931 елларда Магнитогорск металлургия комбинаты төзү максатыннан, Магнитогорск шәһәре барлыкка килә башлый. Бирегә китерелгән «раскулаченныйлар» – иң булдыклы, эшчән нәсел халкы. Алар илнең төрле ягыннан китерелгән, әле шәһәр төзелмәгән, халык бала-чагасы белән кайсы брезент палаткада, кайсы баракта яши. Бет, корчаңгы, юынырга мунча юк. Буржуйка миче вакытлы торакны җылытып җиткерә алмый. Берничә ярусллы караватларда, сәкеләрдә яталар. Матрас та, мендәр дә, юрган да – салам, камыш. Ашау – суга болгаткан баланда. Эш авыр, көне-төне туктатылмый, шәһәр төзү белән беррәттән комбинат та төзелә. Магнитная тавыннан хәзер чокыр гына калган. Анда тарихи истәлек булып, беренче магнит рудасын чыгарган вагонетка тора.

Ахун бабайның олы кызы Әминә авылда Мәдиярнең Мөхәммәтша (аны Миша дип йөртә торган булганнар) исемле улына кияүгә чыга да, урта хәлдәге гаилә члены булып китә һәм сөрелми кала. Кызлары Әлфия авылга еш кайтып йөри, хәзер исә күбрәк Хөсәен Фәүзиясенә кайта. Әле ярый, бөтен кайтучы-китүчеләрне кабул итүче «гостиница» – Фәүзия апаебыз бар.

Ахун байның җәмәгате – Шәмсеһилал тәтә дә Сеҗенең Мортаза бабай кызы (Заһри бабайның сеңлесе) була. Менә шушы апа үзенең 6 баласын – 5 улын һәм кызы Хәҗәрбануын алып, сөргенгә чыгып китә. «Халык дошманы» булган кешенең 4 улы – Муллаҗан, Салихҗан, Сәлимҗан, Галимҗаннар илебез азатлыгы өчен җаннарын бирә. Кечесе – Шәрипҗан сугышка эләкми. Кече кызлары Хәҗәрбану Олы Әтнәдән куылган бай улы Габидуллин Гарифҗанга кияүгә чыгып, Уралда кала.

Суфия ханым яза: «Бер тапкыр Муллаҗан абый 5 минутка эшкә соңга кала. Шуның өчен бөтен гаилә җәза ала – Чиләбе өлкәсенең Сим шәһәр-

чеге тирәсенә тайгада урман кисәргә җибәрелә». Бушлай эшләтер өчен нинди генә хәйләләр тапмыйлар ул вакытта!

Ахун байның Заһри бабайларга кайтып йөргәнен мин дә хәтерлим әле. Ул бик чибәр кеше иде. Башында – өр-яңа кара түбәтәй, өстендә – ак күлмәк өстеннән кара камзул, аның өстеннән кара костюм кигән. Муенда әллә кара күбәләк, әллә кара галстук – нидер булганы хәтердә. Сакал-мыек пөхтәләп кырылган. Театр уйнаучы артистны хәтерләтә. Авыл буенча йөреп чыкты. Бу – 1950 нче еллар иде. Аның нигезе иске клуб урынында була. Каралты-курасын сүтәләр дә, өлешчә анықын, өлешчә яңа агач материалы кушып, ике катлы бина итеп салалар. Аскы каты – клуб, өстә –мәктәп, китапханә, авыл Советы, колхоз идарәсе булды. Ахунның анасы үги була, ул һәм атасы Фәттахетдин куылмый. Йорт-җир тар-мар китерелгәч, картлар Гөлебшан абыйның анасы Кәримә түтиләрдә тора (ул урында председатель Габделбәр абый торды).

Ахун бай үзе 83 яшьтә, 1969 елда, ә карчыгы Шәмсеһилал әби 1957 елда вафат булып, шул урман кисәргә җибәрелгән җирдә калып, гүр иясе булалар.

Әйе, үзгәртеп корулар да, революцияләр кебек үк, кансыз-көрәшсез генә бирелми. Атларны, сбруйларны да алалар. Ашлык сакларга амбарлар, мал тотарга абзарлар юк. Кемнең абзары, лапасы иркен – шуларда ашлык саклана, атлар асрала. Колхозга Тельман исеме бирелә, аның беренче рәисе – Мифтахов Бәдретдин (Мәүгыйзә апа ире) була. «Ул үзе урта хәлле крестьян гаиләсеннән чыккан», – дип сөйли улы Борһан абый. Кулыннан килгәннең барысын да эшли. Сугышта кала. Бәдри абый 1931 елны күрше колхозга – Мөрәлегә күчерелә, 1934 елны яңадан Сеҗегә кайта; ул вакытта колхоз рәисе булып беренче авыл советы рәисе Галиев Мөхетдин ага тора. Әле ул волость рәисе булып та, бригадир булып та эшли, 1938 елда вафат була.

Колхоз тормышының бик авыр һәм горурланып искә алырлык көннәре дә була. Сугыш алды елларында «Тельман» колхозы куян үрчетү буенча Бөтенсоюз күләмендә дан казана, һәр ана куяннан 37 бала алып, колхоз бер елда бу тармактан гына да 21 мең сум табыш ала. Куян фермасында эшләгән Нуриҗанова Фәсихелбәян 1937 елда СССР Югары Советы депутаты булып сайлана. Аның хезмәтләрен хөкүмәтебез югары бәяли – ул Ленин ордены белән бүләкләнә. Татарстан Дәүләт музеенда, авыл хуҗалыгы алдынгылары бүлегендәге экспонатлар арасында Гыйльмулла, Нурислам, Бәяннар куян тиресе санап торган фоторәсем бар.

Илдә барган үзгәрешләрне тормышка ашыруда комсомол оешмасы да читтә калмый – иң җаваплы, иң авыр урыннарда һәрвакыт алар була.

Сеҗедә комсомол ячейкасы 1928 елда төзелә. Секретаре – Гатауллин Шәйдулла (Гатин Гыйльмулла энесе), ә беренче комсомоллар – Хәкимов Шәрип, Гарифуллин Хисмәтуллалар була. Укытучы Галиева Сафура (Алия белән Алисәләр анасы) – иң алдынгы комсомолларның берсе. Ул вакытта аңа 17 яшь. Уртача буйлы, ак, ябык йөзле Сафураны кайда гына очратмыйлар – бер караганда, ул пионерлар арасында, икенче караганда, кулларына карандаш та тота белмәгән олы яшьтәге кешеләр арасында, аларны укырга-язарга өйрәтә. Әле кырда колхозчылар арасында агитация эшендә, әле сәхнәдә үзенең матур тавышы, җиңел хәрәкәтле биюләре белән тамашачыны гаҗәпләндерә. Аның тормышы күпләргә үрнәк була. Комсомол оешмасы аның хезмәтен эзсез калдырмый – авылдашлары аны Татарстан комсомол оешмасы конференциясенә делегат итеп сайлый, ә конференция Мәскәүгә, ВЛКСМ съездына делегат итеп җибәрә. Аның кулы җиңел була. Сеҗе комсомол оешмасы члены, Ташкич егете Әскәров Әнәс эстафетаны лаеклы кабул итеп, ВЛКСМның XX съездына делегат итеп сайлана.

Үз тарихында колхоз «Тельман», «Ленин», «Коммунист», «Кесмәс», «Туган як» исемнәренә ия була. 1930 нчы елларны авылга беренче трактор кайта. Тракторчылардан – Гөлебшан абый хатыны Миңсафа, Хәер абый хатыны Нәгыймә апаларны, Җиһанша Хәкиме, Садыйк, Фазыл, Гыйлемҗан абыйларны искә төшереп үтә өлкәннәребез. Сәкинә, Гөлниса, Гөлҗиһан апаларның «үгездән дә каты үкереп» кайткан тракторны карарга баштарак йөрәкләре җитми. «Бу өйне дә таптап китәргә мөмкин, дип, келәт астында качып ята идек», – дип сөйләгәннәре истә. Инде тракторлар, машиналар, кинолар авыл тормышында гадәти булган чорда – 1950 нче еллар уртасында да малайларны шиккә салган очраклар булгалый иде.

Колхозлар оешып аякка басканда, халыкта патриотизм, революцион аң көчле була, яшьләр бер-берсе белән ярышып эшли, алдынгылыкны алырга тырыша, «ударник» исеме ала. Һәрнәрсәнең алды-арты бар, дигәндәй, ударникларга каршы карашлылар да була, күрәсең.

Халык әкренләп мунчалар салу хәстәренә керешә. Чөнки бөтен авылга берничә генә кара мунча. Бет белән дә көрәшергә мунча кирәк. Ул сирәк кенә булган кара мунчаларны, безгә дә эләгер, дигән өметтән, күрше-күлән яга торган була. Элеккесенә, әлбәттә, хуҗалар үзләре керә, ә калган мунчага – ягучы, аның балалары керә. Ул кара мунчага керә дә, яга да белү кирәк була әле.

Авылда 2 ташлы көчле су тегермәне эшләгән. Бер ташы он тарта, икенчесе – ярма. Тегермән булу сәбәпле, сугыш алдыннан халык азмы-күпме тук яши. Ул елларда хезмәт көненә 2 кг икмәк бирәләр, келәт-

ләрдә он запасы да булгалый. Корылык булган елларны гына үзәккә үтә ул ачлык.

Сугыш вакыты

Бу дәһшәтле чор турындагы кичерешләр, күренешләр, вакыйгалар Әхмәт абый Әсретдинов һәм Гөлниса апа Фәһмиевалар, Хаҗирә, Сәхрәгөл, Нажия, Гөлҗиһан апалар, Гатин Хәбир, Бәдриев Борһан, Мифтахов Шәмгун һ.б. сөйләвенә нигезләнә.

«Сугышка китүчеләр көне буе атка утырып, гармун уйнап, авыл буйлап җырлашып, саубуллашып йөрде, – ди Шәмгун абый – Мортазин Заһри туганы – Гәрәй Мортазин улы Рәкыйп, Сабир Касыймы кебек егетләрнең киткәнен хәтерлим әле. Бигрәк тә исемдә калганы – Риза абый. Аның сүгенә торган иң әшәке сүзе – «чәперем» иде, шуңа күрә «Чәперем Риза» дип йөрттеләр. Ул кушамат улы Ринатка да күчте. Риза абыйның арбага менеп басып, җиңнәрен сызганып, «Гитлерның муенын борып, бетереп кайтабыз, безне тиздән көтегез», дигән сүзләре берәүне дә тетрәндерми калмагандыр. Камалиев Фәрт абый да нәкъ шулай егетләрчә китте. Без яшьләр, үзебезнең сугышка китәргә яшебез җитмәвенә офтанып калабыз, безнең дә Гитлер этнең муенын борып карыйсы килә...».

1941 елның 27 июне көнне иртән тагы 27 кешегә сугышка китәргә повестька килә – кичен чыгып китәргә кирәк. Ул көнне яңгыр ява. Көтү чиратында Нуруллалар атасы Рәфикъ абый. Атка атланып чабып килгән малайлар аны ашыктыра, ул көтүне ташлап кайтып китәргә мәҗбүр була. Көтү таралып, клевер җиренә керә, сыерлар күбенә. Кайсын суеп өлгерәләр, кайсы үлә. Хәвефле көн кыямәт көненә әверелә. Бөтен халык урамда – китүчеләр, озатучылар, саубуллашу, елашу, җырлашу, шунда ук мескен сыерлар да кычкырыша. Маллар белмәгән шул аксымга бай яшел массалы басуда 15 минуттан артык йөрергә ярамаганын.

Бәла бер килсә, килә бит. 11 ел буе шылт та итмичә эшләгән тегермән бөясен 1941 елгы язгы ташу ерып китә. Субайлары кала. Нык какканнар, күрәсең. Элек субай сугучыларның «субай, һоп!», дип хор белән кычкырулары бөтен авылга ишетелеп торган. Бөя алдына очлатып бозваткыч һәм дулкын сүндергеч ясыйлар. Эш белән тегермәнче Зарыйф һәм бригадир командалык итә. Шул эшләрне башкарып ятканда малайлар йөгерешеп килеп, сугыш башланганын хәбәр итә.

Тылдагы халыкны окоп казырга алалар. Идел буйлап Казан тирәсендә дә буйдан-буйга окоплар казыла. 16 яшьлек Фаягөл дә, сугыш яшеннән чыккан Мифтах абый да, башкалар кебек үк, окопка алына. Иделдә баржага төялеп баралар, ике баржа бәрелешә. Безнең якташлар төялгәне бата башлый, халыкта паника куба – кайсы суга сикерә, берсен-берсе ба-

тыра, кайсы елый, кайсы кычкыра. Тәҗрибәлерәкләр, күпне күргәннәр халыкны тынычландыра, ярдәм итә. Боларны катерлар килеп коткара. Авылга тишек чабаталарын иңнәренә асып, җәяүләп кайтып төшәләр. Аларның җәрәхәтләрен авыл «академиклары» – фельдшер Сания (Казиле кызы), үзебезнең Мәрфуга апалар дәвалый. Ул вакытта медпункт Тәфкил абыйлар каршында, иске мәдрәсә бинасында була.

Сугышка, окопка алынмаганнар Казан заводларыннан килгән разнарядка нигезендә эшче итеп алына, ФЗО мәктәпләренә җибәрелә, ә алардан да калганнар – урак ура, көлтә бәйли, башак, дару үләннәре җыя. Пионер лагеренда ял итүче балалар да төрле эшләргә йөри. 4 нче класстан башлап һәр мәктәп укучысы 1 м^3 утын әзерләргә тиеш. Мәктәп ишегалдында эш кайный.

Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә мемориал. 8 май 2009 ел

А осенью 2009 г. в селе отмечали его 125 летний юбилей. На это мероприятие из Казани и Ульяновска приехала тогда большая делегация видных артистов и общественных деятелей. Например, по направлению Министерства культуры Республики Татарстан на этом мероприятии участвовали народные артисты, известные музыканты Кирам Сатиев, Рамил Курамшин, ведущий сотрудник Дома народного творчества Ильгиз Кадыров. А из представителей Исполкома Всемирного конгресса татар были Миляуша Гумерова, Ривкат Ахмедулов, Исхак Халимов, поэтесса Флюра Тарханова. И мы с женой и сыном Булатом, заслуженным работником культуры Татарстана, лауреатом премии им. Кол Гали, участвовали на этом мероприятии, организованном после опубликования моей

документальной повести «Их, гармонь, гармонь», посвященной своему земляку. Повесть была издана сначала в журнале «Казан утлары», а потом включена в мою книгу «Кичке шэфэкъ» (2009). Это мероприятие вёл глава района Ильяс Мустакимов. И участвовали там работники культуры и просвещения как из района, так и из областного центра, кому был дорог их знаменитый земляк.

Вторым более-менее известным лицом за пределами села в 1930-х гг. была активная колхозница Гаян апа Сагдеева, прозванная сельчанами «Цика Гаян». От имени трудящихся Средневолжского края она была избрана депутатом Верховного Совета СССР. Мы одногодки с Гайсой Сагдеевым, из этого дома, с детства играли и учились вместе. На передней стене дома, меж двух окон, красовалась большая коллективная фотография, где Гаян апа восседала недалеко от главы Верховного Совета Михаила Ивановича Калинина. На той же стене над фотографией тикали часы, подаренные ей в Москве. С Гайсой и другими одногодками мы начали учебу в обновленной новой школе с 1 сентября 1941 г. Нас, первоклассников, было тогда полных три класса. А в начале нового века, при открытии вновь построенного здания школы, нам сообщили, что в последние годы полнокомплектного одного класса не набирают.

Третьим известным лицом села Советского периода является доктор исторических наук, профессор Зямиль Ибрагимович Гильманов. Участник Великой Отечественной войны, награжденный орденами за героические поступки на поле боя и медалями «За победу над Германией» и «За победу над Японией». За героическое сражение при освобождении города Вратимова в Чехословакии он также был признан Почетным гражданином этого города.

Правда, он родом из соседнего Теплестана, но с семи лет рос у нас. Его мать и отец более тридцати лет учительствовали в Тюгальбуге. Ибрагим ага долгое время был завучем, а с 1947 по 1963 гг. являлся директором средней татарской школы. В 1952 г. он был награжден орденом Ленина.

В настоящее время в селе работают средняя школа, Дом культуры. Новое здание школы в центре села недавно было построено при содействии губернатора области С. Морозова. В 1990-е гг. было построено новое здание мечети. Сельчане трудятся в нескольких фермерских хозяйствах и на небольших предприятиях поселка Новочеремшанск, расположенного рядом с селом. Этот поселок возник на месте чувашского базарного села Большой Салаван в начале 1930-х гг., а Новочермешанским стал с середины 1960 гг. Там имеются небольшие предприятия с лесоперерабатывающими цехами и завод «Дубитель». Часть мужского населения нашего села и до войны работала на этих предприятиях.

До начала 1950-х гг. в Тюгальбуге был и свой производственный цех, прозванный сельчанами «кирпичным заводом». Кем и когда был он организован – я не уточнил. Но с пяти-шестилетнего возраста мне эти места знакомы. С ранней весны до поздней осени безостановочно горевшая печь этого «заводика» находилась на южной окраине села, на берегу вышеуказанной речушки с обширным прудом. Мальчишки с нашего конца села с весны до осени играли на его территории: купались в пруду, бегали-прыгали на пустующих временно сушильных площадках кирпичей. Три больших сушильных сарайчиков без стен, но с тесывыми крышами, очень нравились нам в жаркие дни лета. Для нашего удовольствия, из трех этих «риг» какая-либо часто пустовала. Высохшие здесь, затем обожженные в печи кирпичи из этих сарайчиков вывозили люди и из окрестных сел. Впервые мы там слышали пока нам мало понятные слова русской, чувашской и мордовской речи.

Вообще на этой территории чуть южнее от границ Татарстана раньше в основном компактно проживали татары, чуваши и мордва. И летом 1920 г., после появления в газетах карт территории новосозданной Автономной Республики Татарстан, население многих поселений восточнее города Мелекеса взбунтовалось. Их тоже иногда именуют мятежниками-вилочниками. А делегацию из пяти Героев Гражданской войны, направленных в Самару с ходатайством о включении их сел в территорию Татарстана, на какое-то время арестовали. Об этом с указанием имен этих героев и организаторов «бунта» я написал очерк и когда-то напечатал. Вообще-то, татарское, мордовское и чувашское население, составляющее большинство в этом регионе, до сих пор мечтает о присоединении их к территории Республики Татарстан.

Рәшит Минһаҗ

САФАҖӘЙ ҮЗЕ БЕР ДӘҮЛӘТ СЫМАН

(Уңышлы татар авыллары сериясеннән)

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында илебездә барган үзгәртеп корулар, җәмгыяви-икътисади шартлар татар авылларының күбесенә җимергеч тәэсир ясады. Нәтиҗәдә күмәк хуҗалыклар (колхоз-совхозлар) таркалып, шактый күп авыллардан халык, эш урыны, яхшырак көнкүрмеш шартлары эзләп, шәһәр җирләренә, район үзәкләренә күченде. Шул ук вакытта Россиядә халкы сибелми-таралмыйча калган, әле киресенчә, ишәеп-артып тереклек иткән уңышлы татар авыллары да бар. Мондый булдыклы авылларны нигездә ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төркемгә – Нижгар өлкәсенең Пилнә районындагы Сафаҗәй авылы кебек күмәк хуҗалык итү рәвешен саклап калганнарын, икенче төркемгә Чуашстан Республикасының Комсомол районындагы Тукай авылы шикелле мәхәллә (иҗтимагый киңәшмә) оештырып, Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы 131 нче федераль законга таянып, туган авылларының җир-суларын читләргә бирмичә, борынгыдан килгән традицион яшәү рәвешен саклап калганнарын кертергә була.

Шулай итеп, без, Бөтендөнья Татар конгрессы җитәкчелегенең фатихасын алып, әлеге уңышлы татар авылларының яшәү механизмын эчтән торып өйрәнү, башкаларга үрнәк-өлге итеп тасвирлап, күрсәтеп бирү максатында, шушы төбәкләрдә берничә көн торып, очерклар язарга булдык.

Нижгар өлкәсендәге иң зур авыл

Сәфәребез Сафаҗәйдән башланды. Нигә иң әүвәл анда юл тоттыгыз дисезме? Әлеге гамәлгә – уңышлы татар авыллары тәҗрибәсен өйрәнүгә этәргеч бирүче нәкъ менә шушы Сафаҗәй фидакаре, Киров исемендәге авыл хуҗалыгы кооперативы рәисе Шамил Нуриманов булды. Татар конгрессы чараларын, тәгаен алганда, ел да март аенда Казанда уздырыла торган бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыеннарын даими рәвештә матбугатта яктыртып баручы журналист буларак, мин аны ике дистә елдан артык беләм. Шамил Әнәс улы озак еллар Бөтендөнья Татар

конгрессы (БТК) эшендә даими катнашты, ул яшәгән карьяда БТК башкарма комитетының күчмә утырышы үткәрелгәне дә истә. Мәгълүм ки: Ш. Нуриманов Түбән Новгород өлкәсенең Татар милли-мәдәни мөхтәрияте эшчәнлегендә актив катнашып килә. Мөхтәриятнең иң саллы иганәчеләреннән булуыннан да хәбәрдармын. Мин анда 2022 нче елның 12–19 нчы ноябрь көннәрендә булдым.

Бүгенге Сафаҗәй – Нижгар өлкәсендәге 35 татар авылының иң зуры. Хәер, өлкәдә моннан ишлерәк башка авыл юк (район үзәкләре бу исәпкә керми). Аның урамнары гына да утыздан артык. Карьяның барлыкка килү тарихы шактый ерак заманга, 1451 нче елга карый, ахры. Сала ир-атлары 1552 нче елны Казанны басып алырга барган Явыз Иван гаскәрләренә хәлдән килгән кадәр каршылык күрсәткән диләр. 2001 нче елда сафаҗәйлеләр зурлап авылга нигез салынуның 550 еллыгын уздырган, юбилей тантанасында Нижгар өлкәсенең ул вакыттагы губернаторы Иван Скляров катнашкан. Әлеге факт бу туфракларда татарның борынгы заманнардан бирле яшәвен, моны рәсми хакимиятләрнең тануы турында сөйли. XX башында аның халкы, күршедәге Петряксә (заманында волость үзәге булып торган) атлы татар авылыннан гына калышып, алты меңгә җиткән. Карьяның атамасын сафаҗәйлеләр берничә төрле аңлата. Берәүләр, авылга нигез салучы Сафаҗәй исемле кешегә бәйле, диләр. Икенчеләр, XV гасырда Сабачай атлы бабабыз яшәгән, дип гөманлый (сер түгел «ф» авазы телебезгә соңрак кергән). Бу җәһәттә пенсиягә чыкканчы авыл советын җитәкләгән Вафа Камалетдиновның (күптән түгел ул җитмешен тутырган) үз фаразы бар. «Әүвәл авыл Сабачай исемен йөрткән булырга тиеш. Бу сүз йә чиста суны аңлата, йә сабачы, аяк киеме тегүче дигән мәгънәдә», – дип исәпли ул. Заманында күрше-тирәдәге урыс авылларында аны Собачий Остров дип тә йөрткәннәр. Хәзерге вакытта рәсми кәгазьләрдә, урысча Красная Горка дип атала ул. «Красная» сүзеннән аңлашылганча, советлар вакытында бирелгән атама гына бу. Тирә-яктагы урыс авылларында әлеге карья әле дә Сабачай дип телгә алына.

Төптән уйлап карасаң, бер авылның ике төрле исем йөртүе – бик сәер нәрсә. Мәгълүм ки, борынгылар адәм балаларын «без» һәм «алар» дип бүлгән. «Без» дигәннәре – үз, якын кешеләр, «алар» дигәннәре – чит-ят күргәннәр. Ни кызганыч, югарыда, хакимият кәнәфиендә утыручылар мондый вәзгыятьнең җирле халык белән ике арада киртә хасил итүен аңлап бетерми. «Әйдә, алар безне «Красная Горка» дип атасын, без – барыбер «Сафаҗәй». Татар авылы кешесенең күңел түрендә менә нинди караш яшәп килә. Мөгаен, ул моны – дөньяны шушы рәвешле кабул итүен аерым-ачык әйтә дә алмас. Әмма хакимият дилбегәсен тотканнар моны аңларга һәм авыл атамасын җирле халык үзе йөрткән исем-калыпка мөмкин кадәр

туры китеререргә тырышырга тиештер шәт (бу очракта Сафаджай рәвешендә). Ни кызганыч, мондый хәл – бер авылның ике төрле исем белән йөртелүе, ягъни татарча үз атамасы булып, рәсми телдә урыслар кушканча язылуы – илебездә шактый еш таралган күренеш. Тәгаен алганда, Пермь краенда мондый күңелсез хәлгә аеруча еш тап буласың.

Йөремсәклек кенә түгел бу

Сафаҗәйлеләрнең шактые XVIII–XIX гасырда, яхшырак тормыш, иркенрәк җир эзләп, Кама, Урал буйларына, Уфа губернасына күченгән. Шул ук вакытта, игеннәрне җыеп алгач, көз-кыш айларында, читкә чыгып, акча эшләп кайту Сафаҗәй ир-атларының канында бар. Моңа тимер юлның якын булуы да тәэсир итми калмыйдыр. Район үзәге Пилнә авылдан 25 кенә чакырым. Андагы тимер юл станциясендә бик күп маршрутлар кисешә. Беренче чиратта мондый хәл авылда имана җирләре бүлеп бирүнең бик кискен торуы турында сөйли. Шуңа карамастан егеменче гасыр башында, алда әйткәнебезчә, авыл халкы алты меңгә җиткән. Әмма йөз елдан, егерме беренче гасыр башына сафаҗәйлеләр өч мәртәбә диярлек кимегән. Моның тирән сәбәпләре бар. 1910 нчы елда төбәктә котырынган холера эпидемиясе, егерменче елларда Идел–Кама буйларында яшәүче татар халкына каршы оештырылган ясалма ачлык аркасында байтак сафаҗәйле Орехово-Зуево, Щелково, Серпухов, Подольск, Ногинск, Наро-Фоминск сыман Мәскәү тирәсендәге кечкенәрәк шәһәрләргә күченгән. 1941–1945 нче еллардагы Бөек Ватан сугышы сафаҗәйлеләргә аеруча нык «суккан». Яуга алынган меңләп ир-атның яртысы чит туфракларда ятып калган. Ярты мең ир-егет фронттан кайтмый калган икән, бу бит йөзләгән тол хатын, ничәмә-ничә тумый калган сабый дигән сүз! Сугыш вакытында ачтан үлүче хатыннар, картлар, балалар байтак исәпләнә. Әлеге афәттән соң үксез балалар шундый күп җыела: хәтта ятимнәр йорты ачарга мәҗбүр булалар. Сугыштан соңгы михнәтле елларда күп кенә сафаҗәйлеләр әлеге дә баягы Мәскәү тирәсендәге шәһәрләргә, башкаланың үзенә, Свердловск, Омск калаларына күчеп китә.

Халык саны алу мәгълүматларына игътибар итик. 2010 нчы елның 31 декабрендә авылда яшәүчеләр 2256 кеше исәпләнсә, ахыргы җанисәп нәтиҗәләре буенча, ягъни 2021 нче елның 31 нче декабрендә сафаҗәйлеләр 2225 кеше тәшкил итә. Дөрес, тирә-яктагы Петряксә һәм Мәдәнә авыллары үз заманында ишлелеге ягыннан Сафаҗәйне уздырса, бүген инде алар өлкәдәге татар авыллары арасында 2–3 урынны бүлешә. Бер караганда 11 ел эчендә 31 кешегә кимү әлләни югалту түгел. Әмма бу татар, авыл файдасына сөйләми.

Таблица 1

Ике җанисәп арасында Сафаҗәйдәге үзгәрешләр күрсәткече

№		2010 елның 31 декабренә	2021 елның 31 декабренә
1.	Халык саны (яшәүчеләр)	2256	2225
2.	Ихаталар саны	1152	1174
3.	Урамнар саны	29	31
4.	Туучылар саны	16	15
5.	Үлгәннәр саны	47	31
6.	Барча терлек саны	1358	1100
7.	Шул исәптән сыерлар	265	391

Таблица 2

Сафаҗәй авылы биләмәсендә 2017–2021 елларда туган һәм үлгән кешеләр саны

Ел	Туган	Үлгән
2017	15	28
2018	12	31
2019	17	23
2020	12	34
2021	16	31

Эшсөярләр бирешми

Узган гасырның туксанынчы елларында илебезнең авыл хуҗалыгы тармагында башланган сәясәт–тиз арада колхозларны таркатып, авыл хуҗалыгы нигъмәтләре җитештерүне зур агрохолдингларга, крестьян-фермер хуҗалыкларына йөкләргә тырышу омтылышы, йомшак кына әйткәндә, илдә көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының бүлек мөдире, тарих фәннәре докторы Рафаил Шәйдуллинның раславына караганда, бу чорда илебездә егерме меңнән артык авыл юкка чыккан. Бу вәзгыять–авыл хуҗалыгы сәясәтендәге үзгәрешләр–Сафаҗәйгә ничек тәэсир иткән соң? 1995 нче елда Киров исемендәге колхоз рәисе булып сайланып, 28 ел буе шушы хуҗалыкны җитәкләп килүче Шамил Нуриманов: «Мин бу вазифага алынганда, өч дистә ел элек бездә алты йөз колхозчы исәпләнә иде, бүген даими рәвештә 54 кеше хезмәт куя; дөрес, җәен, вакытлыча эшләп алучыларны кушсаң, кайбер елларда йөзләп кеше җыела»,–дип сөйли. Шушы вакыт эчендә

күмәк хуҗалыкта эшләүчеләрнең ун тапкыр азаюына кырчылыкта, терлекчелектә җитештерү барышында яңа, заманчыл технологияләр кулланыла башлавы (әйтик, бер сыердан алтышар мең кг. сөт, хәтта артыграк та савып алучылар бар), үз илебездә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә ясалган, шактый кыйммәтле, катлаулы һәм куәтле техника эшкә җигелүе (чит ил комбайннары, унсигез метр киңлекне алдыручы культиваторлар һ. б.), барыннан да бигрәк кул көченә ихтыяҗның нык кимүе сәбәпче. Эшсөярләрнең «якка тайпылуында», билгеле, **үз җиремдә, үземчә, үземә эшлим**, дип хыялланган егермеләп фермер-крестьян хуҗалыгының да өлеше бар.

Кул көченә ихтыяҗ кимегән кимүен. Әмма дә ләкин соңгы елларда бу проблема икенче яктан калкып чыккан. Яшьләр, бигрәк тә кызлар, мәктәпне тәмамлауга, шәһәргә агыла, эшләүчеләр олыгая бара. Шул сәбәпле соңгы елларда, берәр савучы авырып китсә, фермага пенсиядәге апаларны җәлеп итәргә туры килә. Механизаторларның да мотлак күпчелеге урта һәм пенсия алды яшендә (35 яшькә чаклы өч кенә кеше бар). Яшьләрнең авылда калырга теләмәвен: «Мәскәү бик якын, магнит кебек тартып тора,» – дип аңлата өлкән сафаҗәйлеләр. «Безгә берәр яшьрәк механизатор эшкә килсә, җәен мәскәүче гадуклары ялга кайта да кодалап үз яннарына алып китә», – ди сөйли бу уңайдан хуҗалыкның баш агрономы, идарә әгъзасы Рәис Аймалетдинов. Соңгы елларда яшь сафаҗәйлеләр Мәскәү, Түбән Новгород белән беррәттән Казанны да үз итә башлаган. Әйтик, бүлекчә башлыгы, хуҗалыкның идарә әгъзасы Хәнвәр Хөсәеновның өч баласы да (ике кызы, бер малае) Татарстан башкаласына барып урнашкан. «Мәскәүнең магнит сыман тартып торуына өлкәннәр үзләре гаепле. Соңгы елларда, балалары мәктәпне тәмамлаганчы ук, оланнарга җиңел булсын дип, Мәскәүдә фатир алып куючылар күбәйде. Бу бит инде – балам, Мәскәүгә бар, укы да шунда кал, дигән сүз. Әлеге хәлнең өлкәннәр әле үзләре дә аңлап бетермәгән тискәре ягы бар. Безнең кордашлар башкалада фатирны үзләре бил бөгеп, тир түгеп алды. Болар әзергә бәзер барып урнаша да, әти-әнисе җибәреп торган акчага вузда укып, ялкаулана, эштән бизә», – дип уфтана Сафаҗәйдә ит һәм камырдан ярымфабрикатлар ясаучы «Авыл Дан» ширкәте ачып җибәргән өч егетнең берсе – Айрат Абдуллов. Ярый, әлегә монысын бер чигенеш дип кабул итик.

Берничә ел элек миңа эре җир биләүче бер бай белән әңгәмә корырга туры килде. Мин аңа җирле халыкның: «Кыр эшләренә, урып җыюга читтән кеше китерәләр, хәзер бездә үзбәкләр, таҗиклар сөрә-сукалый, урып җыя», – дигән дәгъвасын җиткердем. «И-и-и, угрылар, эчкечеләр бит алар! Күзәтеп-карап тормасаң, бөтен нәрсәне урлап бетерәләр!» – дип зарланды ул авыл халкыннан. Шамил Нуриманов та колхоз рәисе вазифасына алынган елларда шушы угрылык проблемасына тап булган. Тик,

әлеге байдан аермалы буларак, ул бу тискәре күренешнең төбенә төшә һәм аны уңышлы чишә алган.

Мылтык тотып, сагалап

–Урлашуны ничек туктатырга–бу вазифага алынган мәлдә үзәктә шушы мәсьәлә иде. Халыкның күпме урлаганын якынча санап чыгардым. Минимум 300 тонна ашлык урлана. Бәлкем ике мәртәбә күбрәктер. Аптырагач, басудан иген урларга килүче машиналарны, кирәге чыга калса, дип, мылтык тотып, сагалап торырга туры килде. Беренче тотканыбыз үземә туган тиешле кеше булып чыкты. Икенче, өченчесе–комбайнчылар. Игеннәрен «токта» (ындыр табагында Р.М.) бушаттырып, машиналарын сатуга куйдык хәтта,–дип сөйли бу җәһәттән Шамил Әнәс улы.

Бал тоткан бармак ялый, диләр. Барыбер чәлдерәләр, туктамыйлар. Һәрберсен сагалап, янында утырып тора алмыйсың, дип колхоз рәисе хуҗалыкта эшләүчеләргә **иген белән дә түләргә һәм өстәмә алырга теләгәннәргә арзан бәядән сатарга кирәк**, дигән фикергә килгән. Чынлап та, ашлыкның килосын 9–10ар сумнан сатып алып терлек тота алмыйсың. Әле күптән түгел генә монда эшләүчеләргә игеннең кайбер төрен 2шәр сумнан сатканнар. Хәзер 4–5 сум тирәсе. Солы, арпа, бодайның биредә беркайчан да, корылык елларында да бишәр сумнан югарырак булганы юк. Билгеле, колхозда эшләмәгәннәргә–базар бәясе. Бүген биредә комбайнчыларга, суктыруларына карап, процент белән түлиләр. Әйтик, шоферларга тоннасына 8 кило иген бирелә. Көненә 100 тонна ташыса, 800 кило ашлык дигән сүз бу. Тракторчы биш гектар сукаласа, биш кило ашлык ашлык ала; 50 гектар сукаласа–500 кило. Моңарчы ел әйләнәсе эшләгән кешегә 2шәр тонна гына ашлык бирә торган булганнар. Башкасын–сатып. 2 тонна ашлык та, пай җире өчен бөртек. Бик аз ич бу! Кабатлап әйтик: хезмәт хакының бер өлешен хуҗалыкта эшләүчеләргә игенләтә биреп һәм арзан бәядән сатып кына урлашуны туктата алганнар. Авыл халкы нигә урлаша дигән сорауга ап-ачык җавап бу!

Таблица 3

Сүз уңаеннан, Киров исемендәге а/җ җитештерү кооперативының төп җитештеү күрсәткечләре:

№	Аталышы	2021 ел	2022 елның 9 аена
1.	Бөртеклеләр мәйданы	1900 г	1900 г
2.	Җитештерелгән ашлык	3503 тн	5710 тн
3.	Эре мөгезле терлек саны, шул исәптән сыерлар	711 баш 312 баш	711 баш 312 баш

№	Аталышы	2021 ел	2022 елның 9 аена
4.	Барлык савылган сөт	1824 тн	1535 тн
5.	Сатылган сөт	1683 тн	1376 тн
6.	Эшчеләр саны	52 кеше	54 кеше
7.	Җитештерелгән ит (тере авырлыкта)	83920 тн	52516 тн
8.	Уртача хезмәт хакы	28 485 сум	36 968 сум
9.	Еллык хезмәт хакы	14,033 мең сум	16,615 мең сум

Сафаҗәйдә эшчән, кәсепле, тәвәккәл, гаярь халык яши (шунысы кызык: авыл халкы арасында Гаярь исеме кешеләр шактый еш очрый). Монда балалар, яшьли кул арасына кереп, мал-туар тирсендә кайнашып, өлкәннәргә булышып үсә. «Әле мин кияүгә чыкканда да Шамилләр итек баса иде. Бу эш миңа да эләкте. Мунчада итек бастык. Әни мунча пиченә яга. Катырак ягылса – яна, азрак булса, кипми иде итек», – дип сөйли, авыл халкының кәсепле булуына мисал итеп, Шамилнең хатыны Фирдәвес ханым. Сабый чактан эшкә өйрәнеп үскән, «кара эштән» чирканмаган, тәвәккәл кешенең колхоз рәисе вазифасына алынуы очраклы хәл түгел дип әйтмәкче булам моның белән. Кечкенәдән кыю, үҗәт, тырыш булганга, олыны – олы, кечене кече күреп, ихтирам иткәнгә, булышлырга тырышканга, 1995 нче елны Киров исемендәге хуҗалык колхозчылары аны яшерен тавыш бирү ысулы белән үз рәисләре итеп сайлаган да инде. Булдыклы, намуслы, хикмәтле кеше булмасаң, әйткән сүзеңдә тормасаң, Сафаҗәй кебек авылда өч дистә ел рәис кәнәфиендә утыра алмыйсың. Кировлылар бүген авыл хуҗалыгы нигъмәтләре җитештерүдә район күләмендә генә түгел, өлкә күләмендә алдынгылар сафында бара. Яуланган үрләр – әлеге эшсөярләрнең җиң сызганып эшләве һәм, әлбәттә, Шамил Нуримановның да фидакарьлеге нәтиҗәсе. Шушы казанышларын танып, хакимиятләр аңа Россиянең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исемен биргән икән, әлеге мактаулы исем барча хуҗалык эшчәннәренә дә югары бәя булып тора. «Яңа вазифага керешкәннең беренче елында ук ике гаиләгә – Зәйнәп һәм Абдулбәр Хәйретдиновларга, Хәния һәм Каюм Магҗановларга колхоз хисабына кечерәк кенә йорт салып бирдек. Болар гомер буе колхозның төрле эшендә эшләп, шактый олыгаеп килүче өлкәннәр иде. Шуларның хәер-фатихасы, рәхмәте миңа юл ачып, көч-куәт биреп тора», – дип әүвәл рәислек иткән елларын кабат-кабат хәтерендә яңарта хуҗалык җитәкчесе.

Аерма зур, шактый ук...

Фермерлар пәйда булуга ничек карыйсың? Алар күмәк хуҗалыкны – колхозны алыштыра аламы? – дип сораштырам.

– Әлбәттә, фермерлар да яшәүгә хокуклы. Җирдә альтернатив хуҗалык итүнең бер ысулы ул. Дөрес, колхоз системасында чатаклыклар шактый күп булды. Кайбер колхоз председательләре, төрле башбаштаклыклар кылып, тәмам алпавытка әйләнде. Әмма бөтен җирдә дә вәзгыять бер төрле түгел бит. Һәрхәлдә колхоздан фермерлыкка күчеш чоры дәвамлы булырга, берничә дистә елга сузылырга тиеш иде. Кисәк кенә тотынып, бездә уңышлы эшләп килүче колхоз-совхозларны да тар-мар итеп ташладылар, – дип Шамил Нуриманов фермер хуҗалыкларында социаль яклау мәсьәләсенең бик үк әйбәт куелмавына гыйбрәтле мисаллар китерде.

Социаль яклау дигәннән. Биредә башкалар үрнәк алырлык бик яхшы күренешкә тап булдым. Ел саен хуҗалык унбиш-уналты кешесен, ял итеп, сәламәтеген ныгытып кайтсыннар дип, санаторий-шифаханәгә җибәрә икән. Бу уңайдан Шамил Нуримановның соңгы елларда язын Казанда уздырыла торган татар авыллары эшкуарлары җыеннарының берсендә: «Тракторның, комбайнның да моторы туза, аны алыштыру яки даими карап, майлап тору зарур. Тракторның да, Фаилнең дә «моторын» бакмасаң, карамасаң, мөшкел хәлдә калуың ихтимал. Фаил елына ун-унике көнгә санаторийдә хәл җыеп, дәваланып кайтырга лаек түгелмени?! Лаек, билгеле», – дип чыгыш ясаганын әле күпләр хәтерли булыр.

Сер түгел, байтак кына җирдә колхозчыларның гомуми җыелышлары анда-санда, бик сирәк үткәрелә. Биредә «колхоз» атамасын «авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы» дип үзгәртсәләр дә елына икеөч тапкыр гомуми җыелыш уздырмыйча калмыйлар. һәрхәлдә елына ким дигәндә бер мәртәбә гомуми җыелыш үткәрәләр, барча җитди мәсьәләләрне уртага салып киңәшләшәләр. Ай саен алты кешедән, баш белгечләрдән торган колхоз идарәсе җыелышы җыела. Идарәнең вәкаләте җитмәсә, четереклерәк мәсьәлә булса, ул гомуми җыелыш каравына чыгарыла. Биш ел саен хисап-сайлау җыелышы уздырыла. Аның чираттагысы 2024 нче елда булачак. Кыскасы, уставта ничек каралган, биредә шулай яшәп яталар.

Мәйдан тотучылар авылы

Татарны илгә, дөньяга танытучы бик күп көрәшчеләр тәрбияләп үстерүче авыл бу. Бу уңайдан беренче чиратта билбау көрәше буенча икешәр мәртәбә дөнья чемпионы исемен яулаган Рамил Нуриманов белән Марат Усмановны атап китү зарур. Рамил 2004 нче елда – Төрки-

ядә, 2005 нче елда Казанда уздырылган бәйгедә дөнья чемпионы, 2001, 2002, 2003, 2004, 2005 нче елларда ил чемпионы исемен яулаган. Марат 2016, 2017 нче елларда – дөнья чемпионатында, 2014, 2015, 2017, 2020 нче елларда илебездә баш батыр калган. Ринат Сабитов 2019 нчы елда Вильнюста дөнья кубогын откан, 2010 нчы һәм 2019 нчы елда ил чемпионы исеменә лаек булган. Маратның энесе Айрат 2005 нче елда яшьләр арасында ил һәм дөнья чемпионатында җиңү яулаган. 2006, 2008, 2009 нчы елларда зурлар арасында призлы урыннарны биләгән. 2009 нчы елда Мәскәүдә уздырылган Шазам Сафин исемендәге халыкара турнирда чемпион исемен алган.

Сафаҗәй яшьләре баскетбол, волейбол уйнарга мәктәпнең спорт залына килсә, Мәдәният йортында билне, аяк-кулларны язу, билбау көрәше белән шөгыльләнү өчен заманчыл спорт җиһазлары, яхшы маталар бар. Мондагы тренерлары, алда әйткәнемчә, Илгиз Измайлов. Хоккей, футболны да үз итәләр биредә. Мәктәп балалары кышын спорт залында туп типсә (мини-футбол), авыл яшьләре бу уен белән җәен генә шөгыльләнә. Хоккей мәйданчыгы – шугалак мәктәп балалары, авыл яшьләре өчен дә уртак. Бозны һәр көнне монда билгеләп куелган «Беларусь» тракторы чистартып тора. Колхоз, кәшәкә сугучыларга кием алыштыру һәм тамак ялгап алу өчен уңайлы булсын дип, шугалак янәшәсенә җылытыла торган ике вагончык кайтартып куйган. Аңлашыла ки, районда сафаҗәйлеләрне җиңә ала торган команда юк. Инде килеп, Пилнәдә Боз сарае булмагач, алар күршедәге Сеченово районына барып, шундагы яшьләр белән көч сынаша.

Мәдәният тормышы

Сафаҗәйнең мәдәният-клуб эшчәнлеген Илгиз Измайловтан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Мәдәният йорты директоры спорт остасы булу белән белән бергә гитарада да уйный, җырлый, концертлар оештыра, музыкаль тамашалар, спектакльләрдән өзекләр, сәхнәләштермә-постановкалар әзерли (әле аның ютубта үз блогы да бар). Авылның хор коллективы елның-елында район үзәгендә оештырыла торган «Битва хоров»та, ягъни, хор коллективлары ярышында беренчелекне алып килә. Моңа Илгизнең әнисе Венера ханым нык булыша, дип сөйләделәр миңа авыл һәвәскәрләре, Сафаҗәй мәктәбендә укытып ялга чыккан Венера Измайлова туып үскән авылы Петряксәдә инглиз теле укытучысы булмагач, бүген шунда укытып та йөри икән әле. Илгиз 2017 нче елны – өлкә буенча «Авыл җирендәге иң яхшы мәдәният учреждениесе» грантын, 2018 нче елны «Иң яхшы авыл мәдәният йорты хезмәткәре» грантын откан.

– Мәдәният йорты директорының хезмәт хакы зур түгел, спорт инструкторы булып эшләгәнгә ярты ставка гына түләнә, дисең. Бу акчага

ничек яшисең?–дип Илгизгә уңайсыз сорау бирәм. «Әти-әнием белән бергә яшибез. Печән-саламны, игенне сатып алабыз. Туар асрыйбыз. Безгә җитә. Бөтен нәрсәне акчага гына кайтарып калдырсаң, яшәве кызык булмас иде. Ни кызганыч, соңгы елларда, күпләр шәһәргә киткәч, яшьләрдән команда җыю кыенлаша бара,»–дип ул сүзне читкә бора.

Авылның мәдәни тормышы турында сөйләп, Сафаҗәйнең аяклы тарихы, үзешчән шагыйре, элеккеге авыл советы администрациясе рәисе Вафа Камалетдиновны берничә җөмлә генә булса да искә алмасак, хата булыр. Ни кызганыч, ул хәзер, инсульттан соң, авылның иҗтимагый тормышында актив катнаша алмый. Ул миңа үз акчасына Түбән Новгородта бастырган дүрт шигырь китабын бүләк итте. Аның «Яшисе килә» дигән шигыренә язылган җырны Салават Фәтхетдинов башкара икән. Авыл аксакалы Россиянең демографик халәтен шактый тулы чагылдыручы «ревизия сказкалары», ягъни шуларның Сафаҗәй авылы тарихына караучы сәхифәләре (барысын булмаса да күбесен) күчермәләрен кайтартуын, аерым алганда, Хөсәен Фәизхановның ерак бабаларын ачыклавын, Нәҗип Җиһанов, Кави Нәҗми шәҗәрәләренең Сафаҗәйгә кагылышы булуын бәян итте.

Дини яшәеш

Авылда биш мәчет эшләп килсә дә, Сафаҗәйне Мордовиянең –Белозерье, Аксюн, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән карьялары белән чагыштырганда ислам дине нык алга киткән җир дип әйтеп булмый. Әйтик, миңа 18 нче ноябрь көнне Азат хәзрәт Алимов имамлык иткән 5 нче мәчеткә җомга намазына бару насыйп булды. Унбишләп кеше генә җыелдык без ул көнне. Җомганы имам ярдәмчесе Гаярь хәзрәт укытты. Азат хәзрәт ул көнне ниндидер мәшәкате килеп чыгып Казанга китеп барган икән. «Җомга көнне биш мәчеткә барысы йөзләп кеше җыела»,–диде мәчет картлары. Мондый хәлнең сәбәбен имамнар үзләре, әле безнең халыкта мин-минлек, тәкәбберлек зур, беренче чиратта шул нәрсә комачаулый, дип аңлатты. Югыйса, ирләр, хатын-кызлар өчен сабак бирү оештырыла, укучы балалар өчен мәчеттә якшәмбе мәктәбе эшләп килә икән. Берничә ел элек, ел ярым эчендә ике имам аерылышкан, диделәр. Күрәсең, имамнар халыкка үрнәк булып җитә алмыйдыр. Үзең аерылгансың икән, гаиләне сакларга кирәк, дип ничек вәгазь сөйләмәк кирәк?! Гомумән, авылда буйдак ир-егетләрнең күп булуы, аерылганнарның шактый җы-

елуы күңелле хәл түгел. «25–50 яшь арасындагы никахта булмаган яки өйләнеп аерылган 67 кеше бар», – диделәр миңа авыл Советында.

Телнең дәрәҗәсен ничек күтәрергә?

Сафаҗәйнең балалар бакчасында, мәктәбендә булып яшь буынның ни-нәрсә уйлавын, сүз, фикер сөрешен чамаларга өлгердек. Балалар бакчасында – 57 сабый, мәктәптә 151 бала тәрбияләнә икән. Күпме бу, азмы? Кемнәр белән чагыштырасың бит. Әйтик, күршедәге Петряксә авылы белән чагыштырсаң, анда бүген 107 бала укый. Анда да Сафаҗәйдәге кебек 640 балага исәпләп төзелгән, өч катлы мәктәп. Ни кызганыч, анда бала туу, гомумән, бала саны шактый нык кимегән. Әле шунысы да бар: бу укучылар – Иске һәм Яңа Мучәли авылларыннан, Калиновкадан да килгән, ягъни дүрт авыл баласы. Инде Чуашстанның Комсомол районындагы Тукай авылы белән чагыштырганда Сафаҗәйдә хәлләр әллә ни мактанырлык түгел. Чуашстанның әлеге мәшһүр авылында Сафаҗәйдән 300 кешегә азрак – 1925 кеше яши. Шул ук вакытта мәктәп балалары ике мәртәбәдән дә артык – 348 укучы! Балалар бакчасына 75 сабый йөри. Тукай мәктәбендә дә читтән килеп укучы юк. Петряксә белән чагыштырганда Сафаҗәйнең хәле яхшырак анысы. Билгеле, мәктәбеңдә 100 укучы балаң да юк икән, уңышлы авыл турында сүз йөртү авыр. Сыйныф саен унар укучы утырсын өчен генә дә 110 бала таләп ителә.

Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты ни дәрәҗәдә укытыла соң? (Сүз уңаеннан. Петряксәдә татар теле укытылу тукталган. Белгечләр юк, диделәр). Сафаҗәй мәктәбендә I–III сыйныфларда – икешәр сәгать, дүртенчедә 0,5 сәгать, ягъни бер атнада татар теле, икенчесендә татар әдәбияты, V–VIII сыйныфларда атнага икешәр сәгать, IX, XI сыйныфларда дүртенчедәге кебек атнага 0,5 сәгать, X сыйныфта атнасына ике сәгать татар теле һәм әдәбияты дәресләре укытыла. Билгеле, бик аз бу. Моның белән әлләни зур үрләргә ирешеп булмый шул. Хәер, сафаҗәйлеләр үзләре, Казанда татар теле буенча үткәрелә торган мәртәбәле халыкара ярышларда катнашып киләбез, дип белдерде.

2024 нче елда Сафаҗәй мәктәбен капиталь төзекләндермәкчеләр. 1975 нче елны салынган мәктәпнең әле зур төзекләндерү эшләре күргәне юк икән. «Моңа 150 миллион сум акча бүлеп бирeләчәген хәбәр иттеләр инде. Ремонт вакытында безне бер елга Петряксә мәктәбенә күчереп тормакчылар,» –диде сөйләде миңа Рамил Мусин. Дөрес, моның бер куркыныч ягы бар. Гадәттә бездә күчерү дигәннәре кушу-берләштерү булып чыга. Икътисадның кысылган мәле. Акча бүген бар, иртәгә булмавы ихтимал бит...

Йомгак урынына

Сүз башым бит шүрәле, дигәндәй хикәяләвебез ахырында, Сафаҗәй авылының уңышка ирешү юлларын тагын бер кат, кыскача гына күздән кичерик. Болар, беренче чиратта, күмәк хуҗалык булып яшәүләрендә, абзар-паетларын тутырып мал асрауларында. Биредә һәр ихатада диярлек абзар тутырып мал асрыйлар. Болар, нигездә, бәйләп ашатыла торган үгез, елкы малы. Биш, ун, унбиш, хәтта егерме баштан артык эре терлек тотучылар бар. Һәр йорт диярлек тавык, каз тота. Елкы итеннән казы-казылык ясаучылар йорт саен диярлек мөмкин. Берничә сыер асраучылыр аз. Бу мәшәкать, нигездә, хатын-кызлар җилкәсендә.

Икенчедән, үз эшләрен ачып җибәргән хатын-кызлар аз түгел Сафаҗәйдә. Әйтик, Зифа Исхакова, Зөлфия Айнетдинова, Ләйлә Баһаветдиновалар бик тәмле торт пешерә, Гөлсем Сәүбанова белән Гөлсинә Сөләйманованың да камыр ашларын бик яратып сатып алалар, читтән дә заказ биреп пешертәләр икән. Надирә Айнетдинова, Фатима Зиннәтуллина, Гөлнара Маликова тегү-кисү эшенә бик маһир, диделәр безгә.

Өченчедән, җирдә эшләп, үз мал-туарына җитәрлек иген үстерүче, терлек асраучы егермеләп крестьян-фермер хуҗалыгы бар. Аларның күбесе – гаилә фермалары, башкаларны яллап эшләтүчеләре аз. Әлеге хуҗалыклар нигездә мал симертү белән мәшгуль. Сафаҗәй фермерлары арасында сөтчелек белән шөгыльләнүчеләре, шикәр чөгендере игүчеләре дә бар.

Дүртенчедән, үз авылларыннан, тирә-яктан терлек җыеп алып, суеп-эшкәртеп сату белән шөгыльләнүче кассапчылар шактый күп җыела авылда. Болар нигездә адреслы эшли. Мәскәүдә, Нижгарда яшәүче авылдашларын ит белән тәэмин итеп тора. Алар гадәттә үзләре дә абзарында мал тота, сатып та ала. Мәскәүдә яшәүче сафаҗәйлеләрне, башка таныш-белешләрен шулай ук адреслы рәвештә ит, сөт, бәрәңге, чөгендер кебек азык-төлек белән тәэмин итеп торучылар да аз түгел. Гадәттә алар шәһәрдән буш кайтмый, авылдашлары заказ биргән барча нәрсәне ала кайта. Мәскәү дигәннән, тагын бер кызыклы нәрсәгә игътибар иттем. Башкала зоопаркында байтак сафаҗәйле эшли икән. Аерым алганда, Казандагы Ислам дине кабул итүнең мең еллыгы исемендәге мәдрәсәне тәмамлагач, 3нче мәчет имамы Рөстәм хәзрәт Каюмов әлеге зоопаркта, бертуганы янәшәсендә бер ел каравылчы булып эшләп алган.

Бишенчедән, ярымфабрикатлар җитештерүче «Авыл Дан» ширкәтен аерым бер яңа юнәлеш дип әйтергә мөмкин (бу эш белән өч гаилә шөгыльләнә).

Алтынчыдан, мондагы гаиләләрнең күбесе, берсеннән берсе уздырып, казы-казылык ясый. Күп хезмәт соралса да, шактый яхшы төшемле тармак бу.

Җиденчедән, алдарак, заманында әлеге карья тирә-якта җәдитче мәдрәсәсе белән дан казанган, дип язган идек. Сүз уңаеннан, 2023 нче елның 26 нчы гыйнвар көнне Сафаҗәйдә җәдитче мәдрәсә ачарга күп көч куйган олуг мәгърифәтчебез Хөсәен Фәезхановның тууына 200 ел тулуга багышланган конференция уздырылды. Белозерье, Аксюн, Урта Әләзән кебек кадимче авыллар ябылыбрак яшәргә һәм шул рәвешле мәхәллә үзен, милли һәм дини йөзен сакларга тырышса, җәдитче муллалар дөньяга күбрәк ачылган, җәдитчелек киң таралу аркасында, авыл халкында индивидуализм хисе ныграк тамыр җибәргән. Бүгенге Сафаҗәй имамнары нигездә Мәскәү, Нижгар, Казан шәһәрләрендә гыйлем эстәсә, Мордовия Республикасы, Пенза өлкәсе яшьләре гарәп илләренә барып укуны өстенрәк күрә дигән фикергә килдем. Сүз уңаеннан. 2023 нче елның 16 нчы гыйнварында Казандагы Россия Ислам университетында Идел буе Болгарстанында ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгы җәһәтеннән нәшер ителгән «Россиядә ислам тарихы» дигән саллы хезмәтне тәкъдим итү тантанасы булды. Шунда мин РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшиннан: «Хәзер байтак кына зыялыларыбыз, җәдитчелек белән мавыгу зыянга булган, кадимчелек милләтебезне саклап калган, дип сөйли, яза башлады; әйтик, мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов шулай исәпли иде, Сез ничек уйлыйсыз?» – дип сорадым. «Галимнәр – җәдитче, муллалар кадимче булырга тиеш,» – дип кыска гына җавап бирде ул. Авыл җирендә җәдитче мәдрәсә ачу хата булган, дип аңларгамы инде моны?

Сигезенчедән, тагын бер әһәмияте нәрсә. Сафаҗәйдә яшәүчеләр бүген 2225 кеше исәпләнсә, анда 1174 йорт бар. Гади генә әйткәндә, ике кешегә бер йорт туры килә. Моны ничек аңларга соң? Хикмәт шунда: Мәскәүгә яки Түбән Новгородка барып урнашкан шактый күп кенә яшь сафаҗәйлеләр, җәен кайтып торыр, ял итәр өчен, ындыр артында үзләренә йорт салып куя. Авыл Советыннан бирелгән кәгазьләрнең берсендә, Сафаҗәйдә – 2220 кеше, икенчесендә 2025 кеше яши, дигән саннарны күргәч, боларның кайсы дөрес, дип сорадым. «Икенчесе дөресрәктер», – диделәр миңа. Хикмәт шунда: Мәскәүдә теркәлеп, ягъни пропискада торып, авылда яшәүче өлкәннәр, авылда пропискада торып, Мәскәүдә эшләүче, фатир арендалап яшәүче яшьләр бар икән. Закон моңа мөмкинлек бирә: хәзер Россия кешесе бер җирдә теркәлергә, икенче җирдә яшәргә мөмкин. Әле шунысы да бар: өлкән кешеләр өчен Мәскәүдә теркәлү матди яктан отышлырак. Анда пенсия яшендәге кешеләргә мәр өстәмәләре, төрле льготалар бирелә. Улларына, кызларына Мәскәүдә фатир алып биргән өлкәннәргә, нигә башкалада пропискага кердең, дип, табигый, беркем дәгъва белдерә алмый. Чуашстанның Батыр районындагы Татар Согыты авылында да мондый күренешнең шактый киң җәелгәнен ишетергә туры килгән иде. Хакимиятләрдән ярдәм алу җае бар икән, нигә аннан баш тартырга, дип уйлый гади кеше, һәм, ул үзенчә хаклы да.

Җыеп әйткәндә, сафаҗәйлеләрнең уңышлары бер эштән дә куркып тормауларында, минемчә. Бүген дә мондагы һәр гаилә үз юлын, яхшырак белгән эшен, кәсебен табарга тырыша. Заманында авылның үз сөт, кирпеч заводы булган. Хәтта кирпечне Казан ягына ташыганнар. Куен дәфтәремә авылда элек булган кәсепләрнең кырыктан артык төрен, әйтик, балта осталары, кирпечән, таштан йорт салучылар төркемнәре яшәп килүен теркәп куйдым. Шулар янәшәсендә вак-төяк төзекләндерү-ремонт эшләре белән шөгыльләнүче аерым төркем-бригада барлыкка килүе дә игътибарга лаек.

Инде кабат кайтып, сафаҗәйлеләрнең үҗәт, тәвәккәл, куш йөрәкле булуларына, һич өметсезлеккә бирелми яшәүләренә, баш бирмәс холык-фигыльләренә бүтән дәлил китереп тормыйм. Кискен үзтәнкыйть тоелса да, ахырда авылдагы бер эшкуарның, без мишәр халкының акчага күзе тонган, үлгәнче акча эшләмәкче булалар, дигән сүзен искә төшереп китәм. Хәер, бу гыйбарә дә – аларның үтә эшлекле, булдыклы, уңышлы булуына мисал.

(Язма кыскартылып бирелә. Тулы вариантын БТК сайтыннан укый аласыз).

МИРАСЫБЫЗНЫҢ ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАГЫЛЫШЛЫСЫ

НАШЕ ИСТОРИКО-КРАЕВЕДЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ

ТАТ. ПАРҖЫ ТАРИХЫ[1]

1. Тат. Парҗы урыны.

Удмурт җөмһүриятендә, Глазов районында ст. Глазовтан 18 км төшлек тарафында, иске заманда Казанга ат белән йөри торган юл өстендә, Парзи елгасына утыргандыр.

Беренче тапкыр Парҗыга кемнәр вә кайчан килгәннәр?

Парҗы авылына иң элек килүчеләр хакында менә шул хәбәр бар.

Атогородта (Бу авыл Отогурт дип атала. – Г. Ушмави искәрмәсе) Мария Николаевна дигән Баженова фамилияле бер карчык бар. Бу карчык 1885 нче елларда туган булып, шактый гына аңлы да уяу кешедер, күргән-ишеткән нәрсәләре хакында дәмсе белән сөйлидер. Ир кешесе дә укытучы булган икән. «Менә бу карчык болай сөйли», – дип, минем иптәшемнең атасы әйтә иде.

Парҗыга 1-й килеп утыручылар Адәм авылыннан булган, дип. Адәм авылы Чепса (*Чыпца*) елгасының уң ягында, Глазовтан ерак түгел бер авыл икән. Әле бу вакытта, «Адәм» авылыннан беренче килгән вакытта удмурт халкы динсезләр булып, фәкать ата-бабадан калган гореф, гадәт, җола, келәүләр белән генә маташалар икән дип карчык сөйләгән иде. Карчык бу сүзләрне 1953–1954 елларда сөйләде. Тагы шул сүзләрне дә әйтте, ул вакытта, ягъни динсез вакытларында – ата-бабадан калган гадәт белән маташкан вакытларында басуларында келәү итә торган агачлыклары булган, җәй көннәрендә шул агачлыкка барып, хайваннар суеп, иске гадәт белән келәү иткәннәр икән, ягъни гыйбадәт кылганнар. Бу басулардагы иске вакытта халыкның келәү итә торган урыннарын «Кирәмәт» дип атап йөрткәннәр. Бу вакытта һәр авылның каберлеге дә үз басуларында булган. Удмурт халкы 16–17 нче гасырларда чукындырылып, христиан диненә кертелә башлагач, үлекләрен кайда чиркәү бар, анда илтеп күмәргә башлаганнар да, иске гадәт тә әкренләп беткән.

---

[1] Бу тарихны Т. Парҗыда торучы Г.Х. Ушмави 1958 нче елда тәмамлап, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына җибәргән булган. Алынды: Милли-мәдәни мирасыбыз. Удмуртия татарлары. Казан, 2013. Б. 23–30.

Парҗы дип ни өчен аталган? Парҗы авылы буласы урынга иң элек Адәмнәнме, йә башка җирдән булса да башлап килүче Парзи исемле кеше булырга кирәк, башлап килүченең исеме авылга исем булган, соңра авыл исеме белән елга да Парҗы елгасы дип аталып калган.

Парҗы елгасы

Бу елганы борын заманда Чибашур дип атап йөрткәннәр. Удмурт халкы Чибашур диләр икән, ягъни матур елга дигән сүз буладыр (чибәр дигән сүз удмурт белән татар арасында уртак сүз булып, әз генә аерма белән татарлар «чибәр», арлар «чибер» диләр. – *Г. Ушмави искәрмәсе*).

Чөнки тарих галимнәренә мәгълүм ки: һәрбер җиргә, суга, күлгә, урманга, шәһәргә, тауларга исем кушылмыйдыр, иң элек шул урыннарда кешеләр йөрмичә. Беренче тапкыр урыннарга кем булса да килеп йөрсә, йә килеп утырса, шул кешенең исеме, яки хайванның исеме исем булып каладыр, яки ул урынга якын шәһәр, яки тау исемнәре булып каладыр. Яки мәшһүррерәк исемнәр табылу сәбәпле, искерәк исемнәр онытылып та каладыр.

Удмуртлар авылларны күбрәк елга исеме белән атап калдырганнар. Хәзерге көндә «Верх. Парзи» дип язылa торган авыл бик иске вакытта Чибашур дип йөртелгән. Иәгъни Парзи елгасының борынгы заманындагы исеме белән атап йөрткәннәр. Адәм авылыннан Парзи исемле кеше Парҗыга килеп утыргач кына, Парҗы елгасы дип атала башлаган. Чибашур авылын елга башында булганга күрә генә Югары Парҗы дип яза башлаганнар, ягъни, Парҗы авылы утырган елга башындагы авыл, дигән сүз буладыр. Әле дә бу Югары Парҗыны удмуртлар үзләре генә сөйләгәндә Чибашур дип сөйлиләр.

Адәмнән ни өчен күчеп килгәннәр, вә кайчан килгәннәр

Адәм авылыннан күчеп килүләренә сәбәп нәрсә икәне ачык мәгълүм булмаса да, бөтенләй билгесез дә түгел.

Чөнки дөньяда бик иске заманнардан ук шәһәрләрнең һәм авылларның күбәюенә сәбәп булган нәрсәләр адәмнәрнең тормышларына кимчелек китерә торган нәрсәләр чыгуыдыр.

Кешеләрнең искедән үк тора торган җирләрендә тормышка беренче зарар китерә торган нәрсә итеп җир искерүе, азаюы һәм урман юклыгы, яки ераклашуы саналган. Аның өчен кешеләр бик иске заманда җир белән урманны тормыш алып бара торган беренче нәрсә итеп санаганнар, хайван асраганнар, шуннан тормышка кирәк бар нәрсәне дә ясаганнар, аларга башка бер нәрсә дә кирәк булмаган. Уку, язу кирәк булмаган, тамгалар белән генә аны-моны санаган вакытларында шома таякларга киртекләр ясап хисаплаганнар. Шәһәрләргә барырга хаҗәт төшмәгән (әле мин кечкенә вакытта да таяк киртләп хисап алу, санау бар иде. Без-

нең авылда Гәрәй абзый яз көне хайван көтәргә алганда, өч таяк тотып, йорт саен кереп, ничә хайванның бар, дип сорап, бер таякка сыер, икенче таякка сарык, өченчесенә кәзә санын алып йөри торган иде. 1900 нче елларда), чөнки алар бөтен тормышка кирәк нәрсәләрне үзләре ясаганнар. Тырышрак кешеләр бай булганнар. Баеракларга тагын яхшырак урын кирәк булганда Адәм авылыннан көчлерәкләре Парҗыга яхшырак җир эзләп килгәннәр булса кирәк. Менә шулай тыныч кына торганда, ни булса да бер сәбәп белән күчеп китеп, Парҗы авылын дөньяга китереп чыгарганнар...

Парҗы удмуртларының динсез булып, фәкать иске ата-бабаларыннан калган гореф-гадәт, җола, келәүләр белән генә маташканнары мәгълүм. Моның галәмәтләре:

1. Исемнәре ничек туры килсә, аның белән балаларын атаганнар. Мәсәлән: Парза, Ато, Килән, Ахикбай, Мешкән, Кибә шикелле исемнәр.

2. Христиан диненең исемнәре – Иван, Питр, Симен шикелле исемнәр – чукындырылгач кына кушыла башлаган.

Парҗыга татарлар килүе

Парҗыга татарлар килүе, кайдан килгәннәр, килүләренә нәрсә сәбәп булган вә кайчан килгәннәр.

Парҗыга татарларның кайдан килүләре хакында Парҗы картларының ата-бабаларыннан калган сүзләре вә хәбәрләренә караганда, Парҗыга беренче тапкыр татарлар килүе Кожя авылыннан икән.

Бу Кожя авылы борынгы Вятка губернасы, Глазов өязе (Удмурт җөмһүриятендә) Балезино станциясеннән ерак түгел Чепса (*Чыпца*) елгасының сул ягында урнашкан. Менә шушы авыл бик иске вакытта татар авылы булган икән. Татарларның бу авылдан күчеп китүләренә сәбәп – 16 нчы гасырның соңгы яртысында Иван Грозный законы белән дингә кысу тынычсызлыгы. Колеядан берничә гаилә татар Парлда авылына, удмуртлар янына урман арасына поплардан качып килеп утырганнар.

Адәм поселкасындагы удмуртлар килеп, Парҗы авылы ясап, XVI гасыр ахырында Кожядан татарлар килеп, удмурт белән татар катыш авыл булып калган.

Соңыннан бу Парҗыга башка урыннардан да берничә татар семьясы килеп утырган булырга кирәк. Нократтан һәм Әгерҗедән, Татарстаннан килгәнне әйтәләр.

Парҗыга татарлар килгәч, удмуртларның яхшырак тормышлылары, татарларны яратмыйча, башка авылларга күчеп киткәләгәннәр. Мәсәлән, Парҗыдан Ото исемле кеше белән Килән исемле кеше Оть авылына китеп, Отогорд дигән авылны ясаганнар. Азикбай дигән кеше күчеп, Азикбай авылын ясаган вә башка иске авылларга барып кушылып утырган-

нар. Удмуртлар үзләре сөйлиләр, фәлән авыл да Парзидан күчеп киткән, төгән авыл да Парзидан күчеп киткән, диләр.

Глазов өязендә ст. Балезинога ерак түгел Чепса (*Чыпца*) елгасының уң ягында Ужа дигән удмурт авылына 1570–1580 нче елларда бик зур гына чиркәү салынып, анда дүрт миссионер поп килеп, шул тарафтагы удмуртларны, бер уңайдан, туры килгән мөселман татарларны да чукындыра башлаганнар. Менә шул заманнарда Колея авылы мөселман татарларына да бу чукындыру афәте килеп баскан. Тормышлары тынычсызланган. Соңра Кожя татарлары бу тынычсызлыктан качып, кайсы кайда киткәннәр. Чөнки Кожя Ужадан ерак түгел. Берничә семья Парҗыга да килгәннәр. Колеядан күчә алмыйча калганнары, чукындырылып, керәшен булганнар да, бисермән дип аталып, удмуртлар белән катышып, бөтенләй йотылганнар, югалганнар да удмурт авылы булып калган.

Удмуртлар XVI гасырның ахырына кадәр язычник, ягъни динсез каүм булганнар. Россия хөкүмәте удмуртларны христиан диненә кертергә башлаганда, беренче эшен менә шушы Ужа авылына чиркәү салдырып башлаган.

Бу хәбәрне Глазов шәһәрендә торучы Михаил исемле поп сөйләде. 1958 елда, июньдә. Хәзер мин 70 яшьтә, ди. Ул болай дип сөйли «Мин село Балезинода школьник вакытымда Вяткадан архейри килеп, шушы Ужа чиркәвенең башлануына 300 ел тулуына моливын (юбилей) ясаган иде. Димәк бу поп ул вакытта 10 яки 15 яшьләрдә булса, чиркәү башлануына 4 гасыр туларга якын буладыр».

Бисермән дигән сүз – удмуртлар мөселман дигән сүзне үзгәртеп *бисермән* дип, кайсылары *бичерман* дип, кайсылары *почырман* дип тә әйтәләр. Ягъни аларча «чукындырылган мөселман» дигән сүз буладыр. Удмуртлар татарларны «бигер» дип, кимсетергә теләгәндә әйтәләр. Болгар дигән сүз була, ягъни Шәһри Болгар кауменнән дигән сүз буладыр. Нитәки удмуртларны кимсетелгән урыннарда «ар» дип, «вотяк» дип тә әйтәләр иде.

Кистем авылына да поплар килеп, дингә кыстап йөри башлаганнар. Кистем авылы зуррак та булып, татарлар поплардан курыкмыйча, дингә көчләүчеләрне кыйнап, кисеп җибәргәләгәннәр икән. Соңра кыйнаучылар базарларда, җыеннарда (ягъни кунак атналарына башка авылларга кунакка барган вакытларында): «Ну соң, иптәш, мин фәлән пупны кистем (ягъни кыйнадым)», – дип мактанганнар икән. Шуннан соң кунак итүче хуҗалар берсенә берсе, сезгә кайсы авыллар килде, бездә «кистем»нәр бар, диләр икән. «Кистем» дип мактанган сүзләре авылга исем булып калган, һәм авыл исеме елгага да исем булган, – дип Урьякала авылының Талиб Рәхим углы Касыймов дигән карт сөйләгән иде. Бу карт 75 яшендә

1954 елда үлде. Укый-яза белә иде, ата-бабаларыннан ишеткән тарихи вакыйгаларны күп сөйли иде.

Уръякала[1] авылының халкы, яртысы чукындырылып, бисермән булып калганнар. Мөселманнарны чукындыру кыенрак булган, чөнки алар динле, ә удмуртларны чукындыру асат булган, динсез булганнары өчен.

Удм. Парзи авылыннан Герасим Александрович Жуйков дигән карт 1957 ел җәй көнендә үземә сөйләде. 1957 елда тимерчедә идек. Ул болай ди: «Безнең Парзяга татарлар килгәч, удмуртларның яхшылары китеп беткәннәр. Парзяда начарлары гына, бурлары гына калган», – ди. Шулай дигәч, тимерче Егор бабай: «Үзебезне бигрәк тә бетердең ич», – диде. Егорга ул: «Карт бабайлар шулай әйтәләр иде», – дип җавап бирде.

Нәтиҗә: Парҗыдан күчеп китүләре дөрес икән. Бу карт ул чакта 70 яшьләрдә иде. Янә Григорий Андреевич Владыгкин дигән карт сөйләде: «Безнең Филипп бабай Баләзинәдән килгән бабай. Килгәндә Парзыда удмуртлар 5 кенә гаилә булганнар. Әти Андри 1860 елда Парзыда туган». Димәк, удмуртлар 19 нчы гасыр урталарында Парзыдан күчеп китми калганнары 5 семья гына калган икән. Григорий Андреевичка бабасы сөйләп калдырган. Авыл җыелышларында бер дә киңәшкә килми торган, киреләре генә калган икән. Бер дә киңәшкә килмәгәндә, татарлар удмуртларны кыйныйлар икән дә, соңыннан риза булалар икән. Бу сүзне татар картлары сөйлиләр. «Күп вакытларда килешеп, кунакларга йөрешеп, бәйрәмнәрне бергә ясый торган идек», – дип сөйлиләр.

Патша хөкүмәтенең дә күбрәк әһәмият биргән эше бөтен Россиядә халыкны христиан диненә кертү, чукындыру булган. Бигрәк тә мөселманнарны чукындырырга тырышкан. XIX нчы гасыр башларында патша хөкүмәте, хөкүмәткә кайбер файда яки зарар якларын күзәтеп, мөселманнарга тыштанрак кына булса да дингә иркенчелек биргән булып, кайсыбер урыннарга мәчетләр салырга рөхсәт итә башлаганнар. Кистем авылына да мәчет салынып, мөселманнар мәхәлләсе ачылгач, бу Парҗыдагы мөселманнар да Кистемгә ияргәннәр. Парҗы удмуртлары, чукынып, чиркәүгә ияргәннәр... Шулай булса да Татарстанда соңгы елларда да чукынмаган удмуртлар күп иде әле. (Алар хәзерге Балтач, Кукмара районнарында сакланганнар).

XIX гасырда Парҗы авылы да бик наданлыкта көн иткән. XIX нчы гасыр урталарында Җөрек авылыннан (Киров өлкәсе, Малмыж районы авылы) Насыйбулла бине Гыйсмәтулла бине Фәйзулла дигән кеше Парҗыга укытучы булып килгән. Н. Фәйзуллин Парҗы татарларының дини эшләрен эшләгән. Бу вакытта уку-укытуга кирәкле әсбабларның, шартларның булмавы сәбәпле, Н. Фәйзуллин да зур эш эшли алмаган.

[1] Гурьякала, Гордино авылы күздә тотыла – ред.

Парҗының татарлары да, удмуртлары да: «Безнең авылда ике генә адрес яза белүче кеше булган, башка язу белүче булмаган», – диләр.

1. Фәйзуллин Сафиулла дигән укытучы, Насыйбулланың улы. Бу кеше армиядә әзрәк өйрәнеп кайткан була.

2. Әюб Сәфәр углы Чәчәков дигән кешедер. Бу кеше Глазовта байлар хезмәтендә йөреп, почта хезмәтендә дә йөреп самоучка, бераз гына язу өйрәнгән булган.

19 нчы гасырда Парҗы халкының хайваннары күп булган. «Җәй көнендә хайваннарны басуга көтүчесез генә җибәрә идек», – дип сөйлиләр картлар. Басу өчкә бүленеп, араларында киртә тотылган. Бу киртәне йорт башыннан бүлеп тотканнар. Парҗы татарлары иген эшләре бетеп торган араларда, удмурт авылларында йөргәләп, алыш-биреш белән канәгатьләнгәннәр. «Удмуртлардан атлар, колыннар алып суеп, гел ит кенә ашап тора идек, – дип сөйлиләр. – Эш юк иде, акча табуы кыен иде, – диләр. – Өске киемнәр начар, алача штан, кыш көннәрендә бик читен була иде», – дип сөйлиләр. Соңгы елларда Парҗыга да Татарстаннан итек басучылар, китап сатучылар, көмешчеләр килеп йөри башлаганнар икән.

Чын бәдәви халык шикелле яшәп кенә торган Парҗы татарларында да мәдәният чаткысы беленә башлады. XX нче гасыр башларында Парҗыга яхшырак укытучылар килеп укыта башлаганнар.

Татарларга бераз җан керә башлаган, хәрәкәтләнә башлаганнар. Ниһаять, Кистем безгә ерак, үзебезнең Парҗыга мәчет салырга кирәк, дип, патша хөкүмәтеннән рөхсәт сорый башлаганнар, ләкин хөкүмәт рөхсәт бирмәгән. Парҗы удмуртлары ислам диненә керерләр, дип, урыс хөкүмәте курыккан.

Парҗы татарлары белән удмуртларның аерылышулары

Дөньяда Татар Парҗысы һәм Удмурт Парҗысы дигән авылларның килеп чыгуы. Парҗы мөселманнары һаман да рөхсәт сорауларыннан туктамаганнар. Бу эш 1900–1902 елларда буладыр.

Ахырда 1903 нче елларда патша хөкүмәте, удмуртларны 1 яки 2 чакрым читкәрәк аерып утырту шарты белән, мәчет салырга рөхсәт бирәдер. Бу вакытта Парҗы удмуртлары 14 семья (174 душ) булганнар икән...

Милли җанлы, бай гореф-гадәтле борынгы татар авылы – Кошманда (Кайбыч районы, ТР), динле, денле гаиләдә туып, аның җылы хисләр тулы, кайгыртучан мохитендә тәрбияләнеп үстем. Газиз туган телемнең әдәби-мәдәни җәүһәрләре, кабатланмас аһәңнәре анам сөте белән каныма сеңгән. Балачагым хатирәләре исемә төшкәч, җаныма җылылык тула. 1959 нчы ел. Миңа җиде яшь. Аркамны җылы мичкә терәп утырып, әбекәемә йон язышам. Диварга беркетелгән түгәрәк тәлинкәдән, өй эчен нурландырып, гаҗәеп моң агыла. Яшьли тол калган, якыннарын югалту газапларын, ачлык-ялангачлыкны, кимсетүләрне күп кичергән Нурсафа дәү әнием ап-ак яулык чите белән яшьле күзләрен сөртә. «Балакаем, тыңла әле, Фәридә апаң Кудашева җырлый! Тавышы иллә дә моңлы соң! Җаныма үтеп кереп, тәнемне чемердәтә. Кайгы-хәсрәтләрне күп күргәндер ул, мөгаен. Юкса, бу чаклы үзәкләрне өздереп җырлый алмас иде. Сайрар сандугачларың бер якта торсын!» – ди.

Әбекәем белән икәүләп моң дәрьясына чумабыз. Ирексездән күзләрем йомыла. Шулай тыңлавы рәхәтрәк. Тумыштан җыр-моңга мөкиббән сизгер күңелем тантана итә. Фәридә апаның гаҗәеп матур тавышы мине иркәли-юата, гөнаһсыз сабый күңелен алгысыта. Аның җырында үзебезнең авылның Аныстау чишмәсе челтерәвен, Кошман инеше буендагы камышлар пышылдавын, Утташ чатындагы юкәләр, усаклар лепердәвен, урман кошлары чутылдавын, тагын әллә нинди әлегә таныш түгел, әмма күңелемә үтә дә якын, тылсымлы аһәңнәрне ишетәм. Әбекәй өйдә юкта, сәкегә менеп, түгәрәк тәлинкәне сыйпыйм. Самими балалыгым белән могҗиза булуына өмет итәм. Радионың берәр нәрсәсен боргаласам, матур итеп җырлап безне сөендерә торган Фәридәсе, Әлфиясе, Илһамы килеп чыкмас микән?–дип хыялланам. Үзләре чибәр, йөзләре көләч, күзләре нурлыдыр ул әртисләрнең. Их, бер генә мәртәбә булса да, якыннан күреп калсаң икән аларны! Теләгем фәрештәләрнең «амин» дигән вакытына туры килер, гомер көземә аяк басар алдыннан Казанга күченермен, бу мәшһүр шәхесләр белән якыннан аралашырмын дип кем уйлаган? Әлфия апага атап язган шигырем, мәкаләм, аның «Үзем турында» дигән автобиографик китабында дөнья күрде. Илһам абыйга багышланган мәдхиям «Синең хакка гына түзелгән» дип аталган шигырьләр җыентыгымда, аңа багышланган күмәк җыентыкта басылып чыкты. Легендар шәхес–Фәридә апа белән очрашу, берничә кич дәвамында озаклап гәпләшеп утыру бәхете 2005 елның алтын көзендә насыйп булды миңа. Аңа багышлап язган саллы мәкаләләрем, интервьюларым затлы журналларда, хөкүмәт басмаларында дөнья күрде. 85 яше тулуы уңаеннан, аңа зурлап Идел буендагы шифаханәгә юллама бүләк итеп, Казанга кунакка чакыручы, «Таттрансгаз» идарәсенең генераль директоры Рәфкать Кантюковка әлеге игелеге өчен мең рәхмәтлемен.

Бу күркәм күрешүдән соң 17 ел вакыт узса да, Фәридә апаның тыйнак елмаюлы мөлаем йөзе, нурлы күзләре, канатлы гыйбарәләргә тиң акыллы фикерләрен, салмак кына, сүзләрен таслап тезеп кенә әйтеп куюлары, балачак хатирәләрен яңартканда сөйләгән тапкыр-шаян сүзләре, ихластан кеткелдәп көлеп куюлары әлегәчә хәтеремдә. Олыгайса да, шәм кебек төз гәүдәле иде ул. Зәвык белән киенүе, чисталыгы-пөхтәлеге һәммәбезгә үрнәк булырлык. Хәтере шәплеге, зирәклеге исең китәрлек. Бай репертуарындагы йөзләгән җырның сүзләрен, көйләрен олыгайгач та исендә тота алуы гаҗәеп хәл. Фәридә апа өч мең җыр белгән, диләр. Хыялый авыл баласының сизгер күңеленә эстетик зәвыкны табигать үзе салган, күрәсең. Шунлыктан ул гомер буена ихлас, тирән хиссиятле, гади булып калган. Юкка гына зирәк халкыбыз: гадилектә–галилек, дими. Фәридә апабыз данлы иҗади гомер юлы үтеп, дәүләт бүләкләренә, мактаулы, дәрәҗәле

исемнәргә лаек булса да, анда һаваланунының эзе дә юк иде. Күкрәк сугып, борын чөеп, үзенә дан-шөһрәт дауламаган ул. Аңа күпләрнең холкын бозган йолдыз чире кагылмаган иде. Эчке тәрбиялелек, зыялылык, тыйнаклык, зирәклек, кеше хакын хаклый белү, һәрдаим белемгә омтылыш, тырышлык, максатчанлык – гаиләдән килгән асыл сыйфатлар булыр. Ул чакта Фәридә апа белән якыннан аралашу борчулы күңелемне тынычландырды, эчке рухымны ныгытты, гомумән, җан рәхәте булып тоелды.

Зыялы нәселнең затлы баласы

Күренекле татар-башкорт җырчысы, РСФСРның атказанган артисты (1972), Башкортстан АССРның (1968) һәм Татарстанның халык артисты (1990), Рәшит Ваһапов исемендәге премия лауреаты, «Сөембикә беләзеге» иясе Фәридә Кудашеваның нәсел тамырлары кая барып тоташа? Тылсымлы-моңлы җыр бишеген кем тирбәткән? Халык сөеклесе булып зур сәхнәгә күтәрелгәнче, нинди гыйбрәтле юл үткән? Нинди табыш-югалтулар кичергән? Гаҗәеп зур хезмәте үзе исән чакта тиешенчә бәяләнгәнме? – дигән урынлы сорауларга тәфсилле җавабым «Туган җир»не укучыларны кызыксындырмый калмас, дип өметләнәм.

... 1920 ел. 15 декабрьнең күз ачкысыз буранлы төне. Башкорт АССРның Уфа губерниясенең Уфа өязендә (хәзерге Чишмә районы), Дим елгасы кочагына сыенган гаҗәеп матур табигатьле Келәш авылында яшәүче Яһүдә Кудашев гаиләсендә курчак кадәрле генә нәни кызчык тәүге мәртәбә дөньяга аваз сала. Кендек әбисе, бисмилласын әйтеп, нарасыйның кендек бавын кисеп, тәүге мәртәбә коендырып, биләүсәгә төреп, җайлап кына әнисе Рәхимәнең куенына яткыра. Мең газап эчендә кырык кылы өзелеп, яңа гына тулгак газапларыннан котылган ана: бигрәкләр ябык бит бәләкәчем, имүенең дә юне юк, исән генә калса гына ярар иде дип, ихластан борчыла. Нарасыена бәхетле озын гомер сорап, Аллаһка ялвара. «Кайгырма әле бичәм! Кечкенә булса да, төш кенә бугай ул. Үзе орчык чаклы гына булса да, тавышы әнә нинди көр! Ил-көнгә игелекле булып, нәселебезне данга күмеп, барыбызны да сөендереп, балакаебыз озак яшәр, Аллаһ боерса», – дип юата ире.

Келәш гади генә авыл түгел ул! Биредә бер үк чорда татар һәм башкортның өч талантлы шәхесе: илкүләм танылган халык шагыйре Мостай Кәрим, мәшһүр халык җырчысы Фәридә Кудашева һәм аның этисенең энесе, халык шагыйре Сәйфи Кудаш дөньяга килгән. Замандашлар бер үк саф һаваны сулап, бер үк чишмәнең татлы суын эчеп, авылның яшел чирәмендә тәгәрәп, Акманай күлендә коенып, талчыбыктан үрелгән мурда, иске челтәр белән балык сөзеп, табигать гүзәллегенә сокланып, аннан илһам җыеп үскән. Фәридәнең этисе Яһүдә – морзалар нәселе[1]

---

[1] Чынлыкта бу татар бәкләре нәселе, тарихи »Мещера җирләреннән» чыгучылар (ред.).

дәвамчысы. Картәтиләре Фәттахетдин, аның уллары Яһүдә, Әхияретдин, Нуретдин, Шәйхәттар Кудашевлар, көн итәргә маһирлыклары, тырышлыкларыннан тыш, сәләтле дә: тирә-юньдә данлыклы гармунчы, мандолиначы, җырчы булулары белән аерылып торалар. Үзешчән актер Нуретдин җырлы рольләрне бик оста башкара. Туганнар бергә җыелганда, авыл гөрләп тора, көй-моңнар төп йортка сыймыйча, урамга тарала. Әнисе Рәхимә–уңган хатын. Яшь ана, моңлы тавышы белән борынгы озын башкорт-татар көйләрен көйли-көйли, талбишек бавын аягына элеп, баласын тирбәткәндә, кулларындагы энәсе күз иярмәслек тизлектә ялт-йолт килә. Нәни кызчыгына киертергә дип, үзе теккән бәби күлмәге изүенә бизәк чигә ул. Күргәнегезчә, татар-башкорт халыкларының илһамчысы булачак Фәридәбез, җырлы-моңлы бишектә тирбәлгән. Затлы-зыялы әти-әнисенә кушылып, кечкенәдән озын көйләр көйләгән, гыйбрәтле, дәртле, моңсу халык җырлары тәэсирендә, чын милли мохиттә шәхес буларак җитлеккән. Сандугачны җырларга өйрәтмиләр, дигән гыйбарә нәкъ менә аның турында әйтелгәндер кебек. Фәридәгә кече яшьтән табигать җене кагылган. Басынкы табигатьле, кызыксынучан, хисле бала еш кына ялгызы сахрага чыгып, хуш исле печәнгә чалкан ятып, болытлар агылганын күзәтергә яраткан. Шул күперенке ап-ак «мендәрләргә» кырын ятып дөнья иңлисе, әллә кайларга китәсе, түбәнгә карап, кинәнеп гүзәл җирне күзәтәсе килә аның. «Колагымны туган җиремнең сайрар кошлары тавышы иркәли. Челтерәп аккан чишмә тавышын, чикерткәләр чөкердәшүен, бал кортлары безелдәшүен, үләннәр кыштырдавын, аллы-гөлле болын чәчәкләренең җил уңаена чайкала-чайкала үзара серләшүен сихерләнеп тыңлыйм, сокланып күзәтәм. Башларын суга игән бөдрә таллардан чык тамчылары түгел, әсәемнең калфагына чигелгән энҗе бөртекләренә охшаш асылташлар коеладыр кебек тоела. Миңа аеруча сары чәчәкләр ошый, алардан кояш төсе, җылылык бөркелүен тоям. Шул мизгелдә күңелем дертләп уянып китә, тыелгысыз рәвештә җырлый башлыйм. Миңа табигатьтәге һәрнәрсәдән музыкаль аһәңнәр агыла кебек тоела иде. Беренче сыйныфта укыганда, укытучы апам кушканга, ояла-тартына үзебезнең авыл клубы сәхнәсенә менеп, «Салкын чишмә»не җырладым. Сеңлем Хуршидә белән икәүләп, әтинең энесе Сәйфи агабызның шигырьләрен яттан сөйләдек. Халык гөрләтеп кул чапты. Тамашачы каршысында алган тәүге чирканчыгым эзсез узмады. Үзешчән сәнгать мине үз эченә бөтереп алды. Мәктәптә яхшы укыдым. Бәйрәмнәрдә теләп катнаштым. Соңрак җирле Кыйгы радиосыннан еш җырлаттылар»,–дип хатирәләрен уртаклашкан иде Фәридә апа. Тормышларын бөтәйтергә өметләнеп, Кудашевлар гаиләсе Дүртөйле районына күченә. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, сәләтле кыз Фәридә Уфа сәнгать техникумында дүрт ел белем ала. Дипломлы яшь

белгеч, Дүртөйлегә кайтып, колхоз-совхоз театрында илһамланып эшли башлый. Җырлы-моңлы драматик рольләрне тамашачыларны хисләнеп елатырлык, дулкынландырырлык, уйландырырлык итеп башкара. Табигый сәләте өстенә, зиһене көчле, тырышлыгы зурдан була аның.

Җырчы булу – һөнәр генә түгел, ә яшәү мәгънәсе

Фәридә Кудашеваның халык арасында ныклап танылуына Башкортостан радиосы сәбәпче. 1947–1956 нчы елларда ул дәүләт радиосында солист буларак хезмәт куя. 1956 нчы елда Башкорт дәүләт филармониясенә эшкә чакырыла. Гаҗәеп кызыклы, гыйбрәтле, югалту-табышларга бай, дистәләгән елларга, меңәрләгән чакрымлы озын юлларга сузылган бетмәс-төкәнмәстәй тоелган күпсанлы гастрольле, купшы чәчәк бәйләмнәренә, овацияләргә, тамашачы мәхәббәтенә коенып, көндәшләренең мәкерле күз карашларын, астыртын интригаларын күрмәмешкә салышып, яраткан тамашачысы каршысына елмаеп чыгып басулар 66 ел дәвам итә. Элеккеге СССР киңлекләрен кат-кат ураган, затлы башкалаларның шәп акустикалы, бик иркен концерт залларын яңгыраткан, кечкенә башкорт-татар авылларының кысан, салкын, караңгы клубларын нурландырып, башкаладагы һәм җыйнак саладагы тамашачысына тирән ихтирам, зур хөрмәт белән бердәй хезмәт күрсәткән мөхтәрәм зат ул Фәридә ханым. Европа һәм Урта Азияне бер итеп, Себер киңлекләрен иңләп, Мәскәү, Санкт-Петербург тамашачысын моңлы тавышы белән әсир итеп, Финляндиядә гомер кичерүче татарларга кадәр барып җитеп, халыклар арасында дуслык – татулык җепләре сузган, сәяси-мәдәни күперләр салган, йөрәк җылысы аша дистәләгән төрки халыкларның күңел дөньясын сугарган, туган телебезне, милли рухыбызны саклап калуга үзеннән ифрат зур өлеш керткән сәнгати илче дә иде ул. Туган җирләреннән куылып, хаксызга рәнҗетелеп чыгып киткән, җанының тирән төпкелендә җирсү, өзелеп сагыну хисләрен саклап йөрткән меңәрләгән мөһаҗирләрне тарихи Ватаннарына бәйләп торучы, кан хәтерләрен яңартучы, йөрәк сагышларына дәва бирүче, хисләрен сафландыручы, чит җирләрдә башка халыклар тарафыннан йотылу куркынычы янаган мәлләрдә, милли хиссиятләрен, телен, динен һәм денен, гореф-гадәтләрен саклап калуга этәргеч ясаучы, юатучы, коткаручыларның берсе ул.

Мондый шәхесләр гасырга берәмләп кенә туадыр. Милләтебезнең асылташлары: Фәридә Кудашева, Әлфия Авзалова, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакировларның сәнгати-тәрбияви-тарихи миссияләре таң калырлык, уйланып гыйбрәт алырлык, сокланып баш иярлек. Фәридә Кудашева исеменең, татар белән башкортка гына түгел, үзбәк белән казахка, таҗик белән кыргызга, уйгур белән балкарга бердәй якын һәм кадерле булуы очраклы хәл түгел. Ул алтын бәһасенә торырлык табигый сәләтен тулы-

сынча ачу, аны гомер буе баету, тугандаш татар белән башкортның һич тутыкмас рухи җәүһәрләрен берәмтекләп җыеп, илаһи моң белән бизәп, сугарып, төрки халыкларның күбесенә кайтарып бирү бәхетенә ирешкән бәхетле шәхес! Фәридә апа белән әңгәмәбез вакытында бер мөһим нәрсәне ачыкладым: аның өчен җырчы булу–һөнәр генә түгел, ә яшәү мәгънәсе, җан таләбе булган икән. Күренекле җырчы ханымның: «Сәнгати югарылыкта ихластан башкарылган милли җырның ифрат зур көчкә ия булуын онытмыйк. Ул тамашачының рухын ныгытучы, яралы күңелләрне дәвалаучы көчле тәрбия чарасы булу белән беррәттән, халыклар арасында дуслык һәм туганлык күперләре салырга сәләтле ышанычлы корал да. Сәхнәдән яңгыраган ике-өч ноталы тозсыз такмазалар тамашачының зәвыгын бозса, гыйбрәтле эчтәлекле милли моңнарыбыз аларны тыңлаучыда кешелеклелек сыйфатлары тәрбияли, киләчәккә өмет уты кабыза, тормышта бик авыр хәлләргә юлыкканда югалып калмаска ярдәм итә»,–дип сөйләгәне бүгенгедәй хәтеремдә.

Ф. Кудашева үз репертуарын гомер буе баеткан. Җырлары төрле темаларны колачласа да, аларга мәгънәви бөтенлек, ихласлык, көй белән җыр текстының гармониясе, тирән эчтәлекле тәрбияви кыйммәте хас. «Үземә атап язылган җырларны, композиторларның әсәрләрен махсус өйрәнүдән тыш, кая гына гастрольгә барсам да, җирле халык җырларын отып, күңел сандыгымда туплый бардым. Бигрәк тә башкорт белән татарның тирән мәгънәле озын көйләре йөрәгемә уелып калды. Аларны халык алдында аерым бер җаваплылык тоеп башкардым. Тамашачым әсәрләнеп, ләззәтләнеп тыңлаганда, сәхнә белән залның бербөтенгә әверелүенә, бер хиссият дулкынында тибрәлүенә сөенә идем. Җырда «эреп киткән» мәлемдә, әйтерсең лә, аякларым аз булса да сәхнәдән күтәрелә! Мин җыр канатында өскә күтәрелеп, җыр бишегендә тирбәләм сыман. Беркайчан да концертыма соңга калмадым. Сәхнәгә чыгар алдыннан рольгә кереп, бөтен хиссиятем белән җырны тоеп, җиренә җиткереп башкару өчен, үземне рамкада тотарга, игътибарны башкага юнәлтмәскә, бүлгәләнмәскә тырыштым. Артист залның рухын тоярга, беренче җырлары белән үк аның игътибарын яулап алырга, бөтен осталыгын җигеп, тамашачының күңеленә сукмак салырга, аны башкарыла торган әсәренең эченә бөтереп алып кереп китәргә тиеш. Шул очракта гына зал белән сәхнә бербөтенгә әверелә. Бу инде кәсеп түгел, ә чын рухият, кеше күңелендә җыр тантанасы! Җырчының бәхете шунда түгел мени?»–дип тыйнак кына елмайды ул. Фәридә ханым, гап-гади авыл тумасы булса да, гаҗәеп матур тавышы гына түгел, үзе дә үтә дә затлы икән. Үз-үзен тотышы, килеш-килбәте күңелгә ятышлы. Затлы француз мадамнарын көнләштерерлек югары зәвык бар иде аңарда. Талантыннан яман көнләшеп, аяк чалучы хөсетле бәндәләрнең астыртын эшләгән этлегенә җавап биреп,

мөнәсәбәтләр ачыклауга энергиясен түгеп, кадерле вакытын әрәм итмәгән. Үз дәрәҗәсен беркем алдында да төшермәве, яраткан тамашачысы каршында күңел сафлыгын саклый алуы, гади, сөйкемле, кешелекле гүзәл зат булып кала алуы – үзе үк могҗиза. «Әрсезләнмәдем, оятымны югалтмадым. Көнче-гайбәтчеләрнең авыр сүзләреннән өстен була алдым. Артистның сәхнәдән әйткән һәр сүзен, мимикасын, күз карашын, кием-салымын, үз-үзен тотышын гади халык, аеруча яшьләр, үзенә өлге кебек кабул итә. Шунлыктан, үзе телиме-юкмы, сәнгатькәр тәрбияче ролен үтәргә мәҗбүр. Бу аның ил алдындагы вазыйфасы. Артистка артыгын кыланырга, кирәкмәгән затсыз сүзләр сөйләп, сәхнәне кадерсезләргә ярамый. Сәнгать әһеле, халыкка ярыйм дип, очсыз мода артыннан куып, аңа ияргә тиеш түгел. Киресенчә, үзенең нечкә эстетик зәвыгы, рухи матурлыгы белән гавамны үз артыннан ияртергә, аның хисләр дөньясын калыплаштырырга тиеш. Халык күңеленә үтеп кереп, анда үз урыныңны яулау өчен, тамашачыга җан азыгы бирерлек, моңлы, тирән фәлсәфи мәгънәгә ия җырлар башкаруы зарури. Халык җырын җырламаган, аны башкарырга хәленнән килмәгән «җыручы»ның милләттәшләренең күңелен кузгата, аның мәхәббәтен яулый алуы шикле», – дигән сүзләре бүгенгечә актуаль.

Авырлыклар холкымны чарлады...

Фәридә Кудашеваның кайбер хатирәләре сизгер җанымны тетрәндерде. «Иҗатымда бик бәхетле булдым. Кайда гына чыгыш ясасам да, башкортым да, татарым да үз итте. Әмма тормыш юлым сикәлтәле булды. Ачы хәсрәтләрне күп кичердем. Язмыш мине уттан алып, суга салып, кан-яшь түктерә-түктерә, кат-кат сынады. Шул рәвешчә холкымны чарлады. Әүвәле газиз әнием вафат булды. Унөч яшемдә ятимлек газабына дучар булдым. Беренче никахымнан уңмадым, нарасыемны кочаклап, ялгыз калдым. Өч айлык сабыемны куеныма кысып, җаным өзгәләнгән хәлдә гастрольгә чыгып киттем. Зыянчура районы Муйнак авылы клубында концерт куйган көнне сугыш чыгу хәбәрен ишетеп тетрәндек. Бу афәт һәр йортка диярлек кайгы-хәсрәт китерде. Егерме яшьлек сеңлем Хуршидә яу кырында ятып калды. Толлар, ятимнәр соңгы тиеннәрен ябык учларына йомарлап, концертыбызга агылып килә, билет алып керә иде. Салкын, ярымкараңгы клубларда җырлаган чаклар еш булды. Халык үзе ач-ялангач булса да, соңгы телем икмәген безнең белән бүлеште, хәл кадәренчә кадер-хөрмәт күрсәтергә тырышты. Алардан килгән уңай энергия, халык мәхәббәте аякка бастырды мине. Әле дә яшәү көче бирә. Олыгаеп килгән мәлдә толлык ачысын кичерергә язган икән. Егерме җиде ел үзара хөрмәт итешеп, ярты сүздән аңлашып яшәгән икенче ирем – Бәхти Гайсинны вакытсыз югалту хәсрәтен кичердем. Бердәнбер кызым Ренара фаҗигале төстә якты дөньядан китте. Аның да сабые ятим

калды. Аллаһы Тәгалә яраткан колыма сынауларның зурысын бирермен, дигән бит. Күрәсең, мин–Илаһымның яраткан колыдыр... Якыннарым артыннан кара җиргә кереп ятардай авыр чакларым аз булмады. Тамашачы мәхәббәте генә дөнья белән бәйләп торды. Халкымны коточкыч зур хәсрәтләргә, авыр югалтуларга дучар иткән Бөек Ватан сугышы вакытында, аннан соңгы ачлы-туклы елларда башкарган җырларым белән тамашачымны юата, аңа рухи азык бирә алуымны, милләтемә кирәклегемне тою янәдән тернәкләнеп аякка басарга ярдәм итте. Эчем тулы хәсрәт уты бәгыремне көйдергәндә, ачы күз яшьләремне эчкә йотып, тураеп басып, башымны югары тотып, елмаеп сәхнәгә чыгып басу–үзе зур сынау иде»,–дип сөйләгәндә, мөлаем йөзле ханымның нурлы карашы моңсуланды, соры күзләре яшьләнде. Милли җанлы, татар, башкорт телләрен су урынына эчкән Фәридә апабыздан: зыялы-затлы нәсел дәвамчыларыгыз бармы? Алар кайда яши? Сәнгать юлыгызны дәвам итәләрме? Милләтебезгә хезмәт итәләрме?–дип кызыксындым. «Бу дөньяда оныгым Славяна белән торыннарым Михаил белән Варварадан башка кан-кардәшләремнән беркемем калмады. Якыннарым Мәскәүдә яши. Телефоннан чылтыратып, ара-тирә хәлемне белгәлиләр»,–дигән җавапны ишеткәч, әллә нишләп киттем.

Кызганыч, татар һәм башкорт халкының йөзек кашы, данлыклы сәнгатькәре, зыялы, иманлы Кудаш морза оныгы–динле, денле Фәридә апабызның дәвамчылары затлы нәсел кыйбласыннан читкә тайпылган. Алар татар, башкорт телләрен, бу халыкларның күркәм гореф-гадәтләрен белми, дәү әниләренең моңлы җырларын тыңламый. Чит мохиттә тәрбияләнеп, ят менталитетны үзләштереп, ныклы нәсел тамырларыннан аерылганнар...

Сәхнә түрендә пар былбыллар

Сүз дә юк, данлыклы җырчының гомер юлында шатлыклы мизгелләр дә күп булган. Үзен аңлаган яхшы кешеләр янәшәсендә яшәгәндә кабаттан уянган иҗат дәрте ташып торган, тамашачысыннан рухи көч җыйган. Аның төп таянычы–гомер юлдашы, виртуоз музыкант, аккордеончы, композитор Бәхти Гайсин. Аларга өч дистә елга якын бергәләп иҗат итү бәхетен татырга насыйп булган. «Бәхтием–бәхетем, арка терәгем булды. Күп җырларны уртак тырышлык белән тудырдык. Сәхнә түрендә пар былбыллар шикелле сайрашып иҗат итүебездән кара көнләшүчеләр бар иде. Бәхтиемнең көйләренә үз «нотка»ларымны куеп, мелизмнар белән баетып җырлый идем. Иллә дә шәп аккордеончы-музыкант иде ул. Көйне җаны белән тоеп, җиренә җиткереп уйнады. Бервакытта да җырчыны авыр хәлдә калдырмады. Музыкаль аһәңнәрне дөрес яңгыратты, тональностьне дөрес алды, ноталарга хилафлык китермәде. Шунлыктан, бик катлаулы көйләрнең бормаларын алганда да, тавышым өзелеп калмады. Сәхнәгә

чыгып баскач, аркамның чак кына кыймылдап куюыннан ук, нәрсә әйтергә теләвемне аңлап ала иде, мәрхүмкәем. Фәридәкәем, сиземләвең көчле, синнән шәп композитор чыгар иде. Көйләрне бизәп, баетып башкарасың. Шунлыктан халык аларны үз итә, күтәреп алып, үзенеке итә», – дип үсендерүе исемдә, дигән иде Фәридә апа. Бәхти ага, Фәридәсе җырлаганда, аның тын алышына, авызын ачуына, күз карашына тиклем тоя торган була. Талантлы музыкантның аккордеонда уйнавын беркемнеке белән дә чагыштырып булмый. Композитор буларак, башкорт, татар халык иҗатының борынгы үрнәкләренә нигезләнгән җырларын тыңласаң, һәр әсәре халыкчан һәм заманча яңгырый. Бәхти Гайсинның тырышлыгы белән, яраткан Фәридәсе өчен, яңадан-яңа интонацияләр, ритмик бизәкләр белән баетылган, заманча аранжировкалардан төзелгән репертуар барлыкка килә һәм җырчы иҗатында яңа юнәлеш туа. Бәхти ага җитәкләгән инструменталь ансамбльгә кушылып, Фәридә апабыз башкарган җырларны, очрашуыбызның соңгысында ул бүләк иткән дисклардан кат-кат тыңладым. Җырчының милли мелизмнарга бай ягымлы аһәңнәре һәм музыкаль инструментларның тылсымлы тавышлары сихри дөньяга алып кереп китә кебек. «Ике аккош», «Кайтырсың шикелле», «Кермә төшләремә», «Су буйлап» әнә шундый камил яңгырашлы чын җәүһәрләр. «Йөрәк сере»ндә Фәридә апабыз дәрья суыдай ташып аккан сүнмәс рухлы йөрәк авазын җыр аһәңе – моң аша тамашачысына тулысынча ачып бирә. Фәридә Кудашеваның табигатьтән куелган ягымлы тавышын итальян мәктәбенә хас белькантога тиңләүчеләр бар. Аның иҗат юлы озын булса да, аккомпаниаторлары күп булмый. Иҗатының башлангыч чорында үзенчәлекле композитор, баянчы Таһир Кәримов белән хезмәттәшлек итә. Радиодан яңгыраган тәүге җырлары аның белән язылган. Төрле вакытта күренекле музыкантлар – баянчылар Әлфәрит Солтанов, Рәис Сафиуллин, курайчы Азат Аетколов, Бәхти Гайсин җитәкчелегендәге инструменталь ансамбль, фортепианода Александр Ключарев, Радик Хәбибуллин, Рөстәм Яхин аккомпаниментында да җырлаган ул. Баянмы, аккордеон яки фортепианомы, синтезатор яки тулы ансамбльме – җырчыга комачауламыйча, аның белән бер үк дәрәҗәдә образ тудыру өстендә эшлиләр, бердәй гармоник дуэт хасил итәләр. Фәридә ханым башлыча лирик җырларны үз итә. Һәр җыры – бер мини-спектакль. Ул халык җырының классик традицияләрен дәвам итеп, бер үк вакытта концерт эстрадасының башкару сәнгатенә оригиналь яңалыклар алып керә. Андагы җырлау культурасы, репертуар байлыгы күп җырчылар өчен үрнәк булырлык, бәрхет тембрлы тавышы, авазларның ачыклыгы, сөйләмнең төгәллеге осталык эталоны булып тора. Кудашева җырның кульминация урыннарында тавыш көчен чамадан тыш арттырмыйча, матур тембрын саклап җырлый.

Бер канатым–Уфада, икенчесе–Казанда

Фәридә Кудашеваның Казанга тәүге гастроле 1959 нчы елда була. Дистәдән артык мәдәният сараенда, М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет, Г.Камал исемендәге драма театры сәхнәләрендә чыгышлар ясый. «Казан тамашачысы мине күтәреп алды, чәчәкләргә, алкышларга күмде. Радиодан җырларым агылды. Концертларым аншлаг белән узды,–дип искә алды Фәридә апа.–Тукай клубында олпат язучылар, шагыйрьләр, журналистлар белән очрашу вакытында күзем ап-ак күлмәкле, чал чәчле, ябык озын гәүдәле, Хозыр Ильяс хәзрәтләре кыяфәтендәге берәүгә төште. (Ул Хәсән Туфан була–авт. Х.Г.) Бөтен барлыгы белән мин башкарган халык җырының тирән моң дәрьясына чумган. Аның күзләрендәге сагышны, хәсрәтне күреп тетрәндем. Әгәр карашымны башка тамашачыга күчереп өлгермәсәм, белмим, нәрсә килеп чыккан булыр иде. Минем җырыма кушылып, аның җаны җылый иде бит...». Танылган җырчы Мәгафур Хисмәтуллин ул чакта: «Котлыйм, Фәридә, Казанны яулап алдың! Хәзер синең белән санлашырга була»,–дип әйтә. Ярты гасыр дәвамында милли сәнгать илчесе Уфа–Казан юлларын кат-кат урый. ТРның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев: «Балачагымда радиодан башкорт музыкасын тыңлап үстем. Фәридә Кудашева–башкорт мәдәниятендә тулы бер чор»,–дип бәяли. «Халкым–миңа, мин халкыма рәхмәтле булдык,–дип канәгать елмайды Фәридә ханым.–Хезмәтемне хөкүмәт тә хөрмәтләде. Татарстанның һәм Башкортстанның халык, Россиянең атказанган артисты исемнәрен бирделәр. Мин болай уйлыйм: әгәр кеше ачтан үлмәсә, бөтенләй дә ашамыйча торыр идем. Рухи азыкны өстен куяр идем. Ансыз яшәү-яшәү түгел! Бер канатым–Уфада булса, икенчесе–Казанда. Кая барсам да үз тамашачым!»

Биздермәгез җанны! Мәсхәрәләмәгез тамашачыны!

Фәридә апа белән ихлас әңгәмәбез вакытында, бүгенге заман эстрадасына мөнәсәбәтен белдерүен үтенгән идем. Олпат җырчыбызның нурлы йөзеннән караңгы күләгәләр йөгерешеп узуын күреп алып, хөрмәтле кунагыбызның кәефен кыруыма уңайсызландым. Ул уй-хисләрен яшереп тормады. «Радио тыңлыйм, телевизор карыйм, эстраданы даими күзәтеп барам. 1990 нчы еллар башында ук аңа милләтебезгә хас булмаган затсызлык бәреп керүенә көенәм. Мәгънәсез такмазаларны кат-кат кабатлап, ярым-ялангач көе сәхнәдә сикерешкән, авазлары синтезатор һәм компьютер ярдәмендә ясалган фонограммаларны бар көченә әйләндереп, үзләре микрофон каршында авызларын кыймылдатып торучы зәвыксыз, тавышсыз, моңсызларны артист дияргә телем бармый. Алар изге сәхнәне хурлый, халыкны алдап, хәрам акча җыя. Бу–милли моңның тамырына балта чабу, тамашачыны мәсхәрәләү, миңгерәйтү, уйлый алмас хәлгә

җиткерү, кыргый экстазга этәрү. Моның ахыры тамашачыны азгынлыкка, физик, рухи сәламәтлекне җуюга илтеп җиткерәчәк. Яшьләрне күрәләтә аздырып, җинаятьчелеккә төртеп төшерү юлы бит бу! Кайда монда мәгънә? Шул булдымы халыкка мәдәни хезмәт күрсәтү, аның эстетик зәвыгын, уй-фикерен, рухи дөньясын формалаштыру? Халык алдына чыгып, киң диапазонлы тавышы булмаган көенчә, бүртенә-бүртенә кычкыручы кайбер опера артистларына: «Биздермәгез җанны! Мәсхәрәләмәгез тамашачыны!» – диясе килә. Җырчының дикциясе чиста, һәр авазы аңлаешлы булырга тиеш. Кайвакытта җырны тыңлыйсың, ни әйткәннәрен аңлап булмый. Акча түләп, рухи азык алырга, күңелен хушландырырга, җанын савыктырырга өметләнеп килгән тамашачының таләбе канәгатьләндерелми икән, ул сәнгатьтән бизә. Татар һәм башкорт эстрадасында чын режиссура юк дәрәҗәсендә. Концерт программаларын дилетантлар төзи. Дүрт сәгатьлек тамаша буламы? Кайчан бетә инде бу мәхшәр? – дип, залдагылар кыбырсып утыра икән, хезмәтең бушка китте дигән сүз. Гомер-гомергә сәнгать рухият илһамчысы булды. Җыр сәнгате – аеруча нәфис, нәзберек өлкә. Аны ни битең белән кәсепкә әверелдермәк кирәк? Әгәр артист билет сатучыга, гәҗит чыгаручыга, зал арендалаучыга, эшкуарга әверелсә, иманым камил, аның иҗади образлар өстендә эшләргә, репертуар баетырга вакыты да, хәле дә калмаячак. Нигә аңа Мәдәният министрлыгы түрәсе, администратор, продюсер йөген сөйрәргә? Хикмәт акча юклыкка гына барып терәлсә, безгә сугыш вакытында, ярым ач килеш авылдан-авылга ат, трактор чаналарына, йөк машинасы әрҗәләренә төялеп ката-туңа йөреп, аена унтугызар концерт кую җиңел идеме? Иҗатка бирелгәнлек белән түзелгән. Җырчының вазыйфасы – җырлау гына булырга тиеш. Аның матди хәлен Хөкүмәт кайгыртырга бурычлы, дип уйлыйм. Җырда милли рух, милли сәясәт, яшәеш чагылыш таба. Милләттәшләрем, ишетегез җан авазымны, җыр – кәсеп түгел ул, ә хиссият, рухият!» – дип өзгәләнгән иде олпат җырчыбыз Фәридә ханым. Мөхтәрәм ханымның җан авазы бүген дә актуаль яңгырый, тик аны ишетүчеләрнең көннән-көн азая баруы гына кызганыч...

P.S. Фәридә Кудашева олыгайган көнендә Уфадагы иркен фатирында ялгыз яшәде. Аңа социаль хезмәткәр ярдәм күрсәтте. Хөкүмәттән персональ пенсия билгеләнде. 2010 елның 9 октябрендә Уфада вафат булды һәм шәһәрнең мөселман зиратында олылап җирләнде.

З.А. Тычинских

СУДЬБА УЧИТЕЛЯ

2023 г. в России отмечается как Год Учителя. Судьба сельской учительницы Махмуды Рахимчановны Аминовой схожа с судьбой тысяч учителей послевоенного времени. Это те люди, благодаря профессиональным и человеческим качествам которых – преданности делу, самоотверженности, благородству, долгу и чести, воспитываются новые поколения, сохраняются и передаются нравственные основы, лучшие традиции нашего народа.

Аминова Махмуда Рахимчановна родилась 29 августа 1941 г. в д. Нижние Аремзяны Тобольского района Тюменской области. Детство ее пришлось на тяжелые военные и послевоенные годы. В семье было 6 детей, но четверо рано, еше в детстве, умерли. Отец, Рахимчан Рахимович Бахметов, 1911 г.р., не вернулся с Великой Отечественной войны. Он пропал без вести в 1943 г. в боях под Сталинградом, до войны работал в колхозе, как и мама Махмуды Рахимчановны – Танзиля Мухаметкаримовна.

4-летнюю школу Махмуда Рахимчановна окончила в родной деревне – Нижних Аремзянах.

Потом семья переехала в д. Уки, где Махмуда апа окончила 7-летнюю школу. После окончания ее она поехала учиться в Тобольск, где в школе № 15 окончила 10 классов. Семья девочки осталась в деревне, а в Тобольске она жила уже в общежитии. Училась хорошо, активно участвовала в общественной жизни, в художественной самодеятельности. После окончания школы поступила учиться на филологический факультет Тобольского педагогического института.

После окончания института М. Аминова поехала работать в д. Митькино Вагайского района. Там она проработала всего 3 месяца. Директор школы с. Казанка заприметил молодую учительницу немецкого языка и пригласили работать в Казанскую среднюю школу. Именно там она и познакомилась со своим будущим мужем, своей судьбой – Мансуром Ами-

новым. Его назначили в соседнее с. Тукуз директором школы. Туда вскоре после свадьбы и переехали молодожены. Там они вместе проработали четверть века. Мансур абый – директором школы, Махмуда апа – учительницей русского и немецкого языков и неизменной помощницей мужа во всех делах. Как она вспоминает, работали с раннего утра до позднего вечера: ставили вместе с учащимися спектакли, организовывали концерты и праздники… Школа всегда была центром культурной жизни села. Люди в Тукузе были очень доброжелательные, отзывчивые, душевные. Махмуда апа говорит, что ей очень нравилось жить и работать в Тукузе именно благодаря живущим там людям. Видимо, эта любовь была взаимной. Прошло уже 35 лет, как Аминовы переехали в Тобольск, но и сегодня бывшие ученики не забывают любимую учительницу – постоянно звонят, навещают.

За свою добросовестную работу Махмуда Рахимчановна неоднократно была награждена грамотами разного уровня, принимала участие в областных съездах учителей. Была депутатом Вагайского районного Совета народных депутатов.

Уже на пенсии Аминовы переехали жить в Тобольск. И здесь они продолжают активно участвовать в общественной жизни города. 15 лет назад, когда был создан ансамбль ветеранов-педагогов «Яшьлеккә сәяхәт», Мансур абый и Махмуда апа вошли в состав ансамбля и стали постоянными участниками этого коллектива, а ансамбль с бесплатными концертами объездил почти все татарские деревни Тобольского и Вагайского районов.

Много и горестей выпало на Махмуду Рахимчановну. Она похоронила двух своих взрослых сыновей, несколько лет назад скончался супруг – Мансур абый Аминов. Несмотря на это, она остается по-прежнему доброй, отзывчивой и душевной. В ее доме всегда рады гостям. Махмуда апа накормит всех пирогами и перемечами.

Дай Аллах ей здоровья и благополучия!

Р.К. Бакиева

СЕБЕР ШАГЫЙРӘСЕ ГӨЛФИЗӘР АБДРАХМАНОВА ТУРЫНДА ХАТИРӘЛӘР

Үз төбәгебезнең төбәк талантлы, милләт язмышына җан атып яшәгән шәхесләрен белеп яшәү, алар иҗатын өйрәнү һәм тарату хәзерге кешеләрнең бурычы. Сүзем шигърият дөньясында үз сүзен әйтеп калдырган Гөлфизәр Хәйретдин кызы Абдрахманова турында.

Гөлфизәр Омск өлкәсе, Тевриз районы Байбы авылында 1949 нчы елда туган. Мәктәпне тәмамлаганнан соң Омск кооператив техникумында укып, сатучы товаровед була, елга портында эшләп ала, ләкин авыл кызын туган ягы үзенә тарта. Авылга кайтып ул 27 ел буена мәдәният йортында эшләп талант чишмәсен киңәйтеп җибәрә. Сүз осталыгы, шигъри җаны аңа тынгылык бирми.

Язмыш җилләре аны 2000 нче елларда Тобол шәһәренә алып килә.

Менә шушы чорда инде аның берсе артыннан берсе иҗат җимешләре дөнья күрәләр. 2003 нче ел «Себер ягым», 2006 нчы ел «Нәни дусларга», 2009 нчы ел «Изге Сүзге моңнары», 2011 нче ел «Аркаим – таулар иле», соңрак «Сәяхәт дәрес» һәм «Сүнмә, яшьлек» китаплары басылып чыгалар.

Автор «Себер як», «Себер, Себер» һ. б. шигырьләрендә Себер җиренең байлыгын, гүзәллеген, данлы тарихын сүрәтли.

«Әй, Себер як, Себер як,
Нефть, газга тулган як,
Бөтен милләт халыкларын
Берләштерә торган як».
«Тамырларың көчле, үзең горур,
Үткәннәрең җилле, давыллы,
Сүзгеләрең, Кучумнарың белән
Тарихларың белән син данлы», – дип дан җырлый ул Себер җиренә.

Гөлфизәр – замана баласы буларак мәчет юлларыннан да ераклашмый, дингә дә тартылып, аны өйрәнеп яши. Ул еш кына Тобол районы Саба-

нак авылы мәчетенең көтелгән кунагы булып, анда дини мәҗлесләрдә, бәйрәмнәрдә катнашып торды. Мәчет кунаклары авторның шигырьләрен яратып тыңлыйлар иде.

«Мәчет ишекләрен ачкан чакта,
Күңел көзгеләрем яктыра,
Сулышларым иркенәеп китә,
Бөтен борчуларым онтыла», – дип яза ул «Мәчет тынлыгы»

шигырендә.

Гөлфизәрнең догалар белән, аларның көчен тоеп, кайбер авыруларны дәвалап йөрүе дә әһәмияткә иядер.

Автор үз заманының күренекле шәхесләрен яратып, аларның иҗатын халык арасында тарату юлларыннан да туктамады.

«Тыныч йокла, Булат,
калган эшләреңне,
Башкарырлар сездән калганнар.
Махиянов, Якуб Зәнкиевлар,
Ильясовлар, Әнәс, Корманнар».

Моңа өстәп куясы иде: С. Сагитовлар, Зилә Абайдуллина, С. Бекенин, Гөлнур Хайруллина, Ф. Утяшева һәм дә башкалар.

Күпме талант, тел остазы булырга кирәк Ершовның «Сүзге» поэмасын шигъри юлларга салып тәрҗемә итәр өчен...

Гөлфизәрнең күп кенә шигырьләре җирле композитор тарафыннан көйгә салынганнар һәм ансамбльләр аларны башкарудан туктамыйлар. Мәсәлән, «Җилләр белән», «Изге Сүзге моңнары», «Пар аккошлар», «Себер, Себер», «Соң инде», «Тапталган яшьлегем» һ.б.

Шагыйрәне кайда гына китсә дә, туган авылы – Байбысы үзенә тарта, шуның өчендер дә фанидан китәсен сизенгәч, ул үз туфрагына – авылына кайтып китә, шунда, 2018 елның 18 мартында вафат була, Байбыда җирләнә. «Авылым тарихы» шигырендә авылының табигате матурлыгын, килеп чыгышын (1606 еллардан башлана) сүрәтләп ул менә нәрсә яза: «Авыл елга буенда урнашкан була, еш кына аны су алган (Иртыш). Байбахты исемле бабай урын эзләп матур тау каршына килеп чыккан да, «Эх, нинди матур Ер» дип кычкырган. Яңа урынга авыл күчеп, шул бабай исемен алган, «Байбы» дип йөртә башлаганнар, тарихта шул исеме белән калган».

Әнкәйләргә, туган телгә багышлап шигырь язмаган бер генә шагыйрь дә юктыр. «Әнкәй», «Кәккүк ана», «Ана сагышы», «Газиз кешем минем әнием» һ.б. шигъри юлларында аның кайда гына булса да әнисен ярату, сагыну, юксыну хисләре урын алалар.

«Вакыт узар белдермичә генә,
Гомеремнең җитәр көзләре.
Актык сулышкача ишетермен
Әнкәемнең җылы сүзләрен», – дип яза ул «Әнкәемнең
җылы сүзләре» шигырендә.

Туган телне саклау, яклау, белү һәр милләт баласының изге бурычы дип саный шагыйрә.

«Батыр, горур, данлы, серле,
Син иманлы, затлы матур тел.
Онытма син, татар, Тукай телен,
Аның алда башың ия бел».

Тобол шәһәренең милли-мәдәни автономиясе тәкъдиме буенча (җитәкчесе З.А. Тычинских) шагыйрәгә багышланган ел саен оештырыла торган истәлекле искә алу бәйрәме «Яшьлеккә сәяхәт» ансамбле җитәкчесе (Роза Яхина) оештыруында 2022 елның октябрь аенда киң программа белән үтте.

Аның иҗатын саклап калу һәм киләчәк буыннарга тарату максаты белән мондый чараларны һәр ел саен үткәрү традициягә керәчәк дигән карар һәр тарафка җиткерелде.

P.S.: 22-ел октябрь аенда Гөлфизәр Хәйретдин кызы Абдрахмановага багышланган зур чара турында «Яңарыш» газетасында (№47, 18.11.2022) язылган иде, шагыйрәнең иҗатын тулырак итеп сүрәтләү максаты белән тагын язмакчы булдым.

Н.А. Файзуллина

«ДОБРЫЙ СЛЕД НА ЗЕМЛЕ»
(к портрету создателя Ембаевского сельского музея В.А. Биктимировой)

Любовь к своему делу, дому, родному селу… Не это ли патриотизм по отношению ко всей стране…?! Я пишу о хрупкой женщине с огромной душой, педагоге и патриоте. О человеке с большой буквы, чья жизнь является суммой двух слагаемых – патриотизма и труда. О Венере Адиятовне Биктимировой, создателе Ембаевского сельского музея и его первом директоре, слово.

Своим очерком я хочу воздать по заслугам этому замечательному человеку, настоящему подвижнику, творческой личности, незабываемой для односельчан.

Ее труд являлся не просто увлечением, а своего рода одержимостью, неисчерпаемой верностью, покоряющим и восхищающим. До сих пор поражает ее отношение к делу, а результаты ее деятельности впечатляют. Ее музей живет и развивается освещая историю с. Ембаево и с. Тураевой. Она создала и подарила потомкам целое наследие.

Венера Адиятовна родилась в 1931 г. в Тобольске, в семье учителей Саиткуловых – Адията и Бибинур. Ее отец возглавлял татарскую школу им. Нариманова, сейчас это школа № 15. Мать была учительницей начальных классов. Народная мудрость гласит: чем глубже корни, тем крепче крона. Каждый из нас, что бы мы

ни думали о своей уникальности, есть совокупный результат поступков, действий, событий, затраченных сил, связанных с предыдущими поколениями. И Венера Адиятовна гордилась, что она представитель педагогического рода, где рождались сильные духом и телом люди, активные и творческие. И она стала продолжением этой родовой цепи, приумножив наследие предков-педагогов и просветителей.

Наша героиня с отличием закончила Тобольское татарское педучилище, затем Тобольский педагогический институт. В 1960 г. по направлению Тюменского РайОНО она становится заведующей детского сада «Тополек» в с. Ембаево. По ее воспоминаниям, этот детский сад открылся 8 августа 1960 г. Он размещался в неприспособленных деревянных зданиях, специального здания не было. Не было и квалифицированных воспитателей, поэтому Венера Адиятовна была одновременно и заведующей, и воспитателем, и музыкальным руководителем. Постепенно стал складываться коллектив, подбирались квалифицированные воспитатели. Изначально в «Топольке» воспитывалось 9 детей, затем набралось 42 воспитанника.

Главной особенностью Венеры Адиятовны была способность видеть в ребенке личность, чувствовать ответственность за его здоровье и развитие. Она была энергичным, настойчивым, требовательным руководителем. Отличалась умением продуктивно работать. Слаженный труд всех членов коллектива, полное взаимодействие и тесный контакт с родителями, а также с общественностью позволили сделать все необходимое для детей. Одна из главных забот заведующей – укрепление материальной базы и создание необходимых условий труда для работы. В этом ее партнерами стали совхоз им. Калинина, сельский совет и, конечно, родители.

Благодаря ее стараниям, детский сад «Тополек» стал передовым в районе и области. Учреждение превратилось в опытную площадку для проведения районных и областных семинаров. Под ее руководством детский сад воспитал не одно поколение детей.

В.А. Биктимирова была, кроме того, и энергичной общественницей: в течение нескольких лет являлась членом президиума райкома и обкома КПСС и профсоюза работников культуры, членом совета РайОНО, оказывала методическую помощь детским садам района. Она всегда прямо и аргументированно выражала свою точку зрения и широко делилась опытом. За активную работу Венера Адиятовна была награждена знаком «Отличник народного просвещения», Почётной грамотой Министерства просвещения РСФСР, медалями «За доблестный труд в ознаменование 100-летия В.И. Ленина», «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941–45 гг.», «Ветеран труда». Ее имя занесено в районную Книгу Почета.

После ухода на заслуженный отдых, она работала в школе учителем обслуживающего труда для девочек и начальником пришкольного лагеря. Уже в то время «неугомонная Венера»–так называли ее соратники, вынашивала идею создания в селе музея. Разделяли ее и супруг, директор Ембаевской средней школы, Сулейман Колчакович Биктимиров, председатель сельского совета Саид Хамитович Фатхуллин. И Венера Адиятовна смогла воплотить в реальность мечты односельчан.

В декабре 1989 г., когда возникли изменения в общественно-политической жизни в стране, в администрацию Тюменского района обратилась областная Ассоциация татар с предложением открыть музей в Ембаево. В 1994 г. Постановлением главы Администрации Тюменского района В.А. Бугаева был создан районный Музей татарской культуры, а директором музея назначена Венера Адиятовна Биктимира, ветеран педагогического труда, инициатор его появления. Ембаевский сельсовет постановил выделить из Ансамбля мечети с. Ембаево под музей здание бывшего медресе, памятник культуры XIX в.

И опять все пришлось начинать с нуля. Вот как вспоминала об этом событии сама его первая заведующая: «Я пришла на пустое место: не было ни помещения, ни экспонатов. В этом здании тогда находился сельсовет, и нам обещали выделить одну комнату. А в поисках музейных редкостей я пошла по домам, по нашим бабушкам. Они очень доброжелательно меня встречали, каждая старалась чем-то помочь. Чего только не нашлось в домах деревенских старушек!»

На протяжении нескольких лет Венера Адиятовна со своими первыми сотрудниками–Марзией Салямовой, Альфией Яминовой, Марзией Валишевой собрала для музея большую коллекцию подлинных предметов традиционной материальной культуры сибирских татар. Большой вклад в пополнении музейных фондов внесли местные жители, поэтому во всех его экспонатах присутствует частичка души каждого жителя села.

Сейчас в Ембаевском сельском музее собраны ценные предметы старины: самовары, кумганы, кувшины, чугунные утюги, прялки, образцы национальной татарской одежды, самотканые платки, скатерти, различные украшения XVIII–XIX вв. и многие др.

С момента организации музея активно помогала заведующей в пополнении фонда Сарвар Нигматуллина, жительница с. Ембаево. Она ездила в ныне заброшенную д. Кыштырла Тюменского района, чтобы привезти из дома своих родителей старинные вещи. Подарила она музею и семейную реликвию–поднос. На этом подносе ее мать–Сарвар, по заведенной традиции, поднесла молодым свадебный пирог. А самой матери когда-то в столь же знаменательный день на нем поднесла хлеб ее мать. Часы и

кумган преподнесла музею Рачига Муллашева. Фатима Яминова из Тураева подарила медный таз, кумган, деревянные часы с татарским орнаментом. Махмуд Фатхуллин пожертвовал бычий хомут. Многие хорошо помнят, как в тяжелые военные годы пахали на быках: лошадей отправляли на фронт, техники не было. Жена Махмуда Фатхуллина, Альфия, принесла сохранившиеся вещи своего прадедушки – Алиуллы Муслимова, родоначальника рода Муслимовых вЕмбаево. Алиулла был образованным человеком, вел в мечети метрическую книгу на арабском шрифте. Эту книгу предоставила музею М.Р. Файзуллина. В старину люди берегли свои вещи, делали их собственноручно, за качество ручались. Поэтому и не стыдились ставить клеймо мастера. Тот же Алиулла Муслимов мог и деревянную посуду смастерить. На деревянном корыте стоит его клеймо – тамга.

Личное обаяние Венеры Адиятовны, интеллигентность и энергия сыграли положительную роль в новом деле. Ембаевский сельский музей за короткое время стал известен не только в Тюменском районе, но и за пределами РФ. В 2010 г. музей был включен в реестр музеев для посещения туристами со всего мира.

В этот же период времени В.А. Биктимирова возглавляла Совет ветеранов Ембаевского муниципального образования. Бессменный его председатель, находясь в преклонном возрасте, на протяжении 16 лет умела так рассказать о Великой Отечественной войне, о ее героях-фронтовиках, тружениках тыла, с которыми лично была знакома, а главное, о ее детище – музее, что многие ребята бежали в его залы, чтобы снова и снова пообщаться с ней и увидеть музейные реликвии.

В то время мне, как заместителю директора по воспитательной работе Ембаевской средней школы, посчастливилось сотрудничать с ней и вести совместную работу по патриотическому воспитанию молодого поколения на примере односельчан, отдавших свои жизни служению Отечеству. На базе музея и школы проходили конкурсы чтецов на патриотические темы, экскурсии, реализовывались исследовательские проекты, проводились мероприятия патриотической направленности.

За большой личный вклад в укреплении межнациональных отношений, дружбы и согласия между народами Тюменской области, многолетнюю плодотворную работу по сохранению и развитию татарского языка, культуры и областного Совета ветеранов, патриотическое воспитание подрастающего поколения, Венера Адиятовна была награждена благодарственным письмом Председателя Комитета по делам национальностей Тюменской области, благодарственными письмами Тюменской Областной Думы, Главы Тюменского муниципального района, Президента телерадиокомпании «Регион-Тюмень».

Пять лет Венера Адиятовна вела работу как Председатель Ассоциации татар Тюменского района, являлась членом совета областной Ассоциации. Удивительная женщина, и как ее силы и энергии хватало на все! Еще одно ее детище – это фольклорный ансамбль «Милли моңнар», созданный на базе музея в 1996 г. и пользующийся огромным успехом. В состав ансамбля входили: Имбира Рафикова, Марзия Валишева, Разига Алимбаева, Марзия Салямова, Ания Алтынгузина, Роза Алеева, Альфия Сиразутдинова, Миникамал Ахтямова, Альфия Яминова, Амина Туйчина, Рита Колчакова. Популярность ансамбля быстро росла, его состав достиг 15 человек. Музыкальным руководителем ансамбля стала Гульзифа Мирюгина. Коллектив с усердием собирал и изучал традиции, обычаи и духовную культуру сибирских татар. «Милли моңнар» принимал активное участие во всех мероприятиях музея, села, района, области. Был Победителем, Лауреатом, Дипломантом конкурсов различного уровня. В народе его до сих пор называют: «Жемчужина народного таланта».

Детский сад, Ембаевский сельский музей, Совет ветеранов и Ансамбль стали для нее родными, именно здесь к ней пришли авторитет и уважение односельчан. Можно ли найти слова, значение которых будет столь емким, что вместит в себя и любовь этого человека к своему делу, и благородство души, и искрометный задор до последних дней?! Сила духа, твердость характера, желание постоянно совершенствоваться и совершенствовать других, любовь к своей профессии, к творчеству, чувство долга, – вот черты к ее портрету!

Сегодня мы продолжаем те традиции, которые были заложены старшим поколением музейщиков, моими предшественниками. Все в нашей жизни меняется. Изменились общество, люди, государство, конечно же, менялся и наш музей. Все эти изменения происходили при поддержке односельчан, руководства, друзей и партнеров со знаком плюс, с курсом на созидание.

В настоящее время наш музей обладает богатым собранием музейных коллекций, отражающих культурно-историческое своеобразие села, и насчитывает более 3000 экспонатов. Он стал подлинным историко-культурным центром, способствующим сохранению татарского языка, фольклора, традиций и обычаев сибирских татар.

Сейчас жизнь музея насыщена ежедневными заботами и открытиями. Не бывает и дня, чтобы в его стенах не происходили события, каждое из которых можно назвать ярким.

Практически все свое время я провожу в музее. Музей притягивает. Чем больше времени отдаешь музею, тем больше получаешь интересных и важных результатов. Вот уже 10 лет, как нет Венеры Адиятовны, но

каждый день, открывая музей, глядя на фотопортрет его основательницы, я испытываю чувство гордости за нее и мысленно благодарю ее за подаренное нам наследие − Ембаевский сельский музей.

Главная награда для любого человека – доброе слово, память и благодарность тех, с кем сводила тебя жизнь, кому ты отдал частицу своего сердца. Ее дело, патриотизм, творчество – яркий пример преданного служения своему родному дому, своему селу, родной земле, яркий след, оставленный ею на земле!

Использованная литература

1. Алишина Х.Ч. Основатель Ембаевского музея: [о Венере Биктимировой] // Яңарыш. – 2010. – 24 декабря (№ 52).
2. Алишина Х.Ч. Старинное сибирское село: [о Ембаевском краеведческом музее и его директоре Венере Биктимировой] // Татарский мир. – Москва, 2010. – № 7.
3. Алтынгузина А. В древней столице Сибири. // Красное знамя. – 2000.
4. Архив Ембаевского сельского музея. ВФ. 82.
5. Ниязов Н. Жемчужина народного таланта // Яңарыш. – 1998.
6. Садыкова Н. Ямбай музенда // Яңарыш. – 1997.
7. Салихова С. Откуда у человека берется энергия?! // Красное знамя – 1996.
8. Уразалиев Ф. Без сезнең белән горурланабыз. // Яңарыш. – 2000.

ТАТАР РУХЫ

ТАТАРСКИЙ ДУХ

Г.Р. Ахметьянова

КОММЕНТАРИИ К «МУХАММАДИЕ» «ФАРРАХУ АР-РУХ» И ЕГО АВТОР

В свое время одним из самых распространенных религиозных сочинений среди татар была книга турецко-османского автора Мухаммеда Йазыджиоглу «Китабу Мухаммадиййа фи на'ти саййиди аль-алямин хабибилляха аль-азам Аби Касим Мухаммаддини аль-Мустафа» («Книга Мухаммадия, восхваляющая господина миров, великого любимца Аллаха Абу Касима Мухаммада Мустафу») или, как чаще ее называют, «Мухаммадия».

Автограф «Мухаммадии», заглавная страница

Об этой книге И.Р. Мухаметов пишет: «Источники указывают на то, что «Мухаммадия» в свое время была одной из наиболее популярных книг среди татар после Священного Корана. Она была почти в каждом доме и стала одновременно поэзией для души и энциклопедией для ума» [Мухаметов: 2006. С. 3]. До революции было осуществлено 22 издания этой книги как в Стамбуле, так и Казани, в том числе иллюстрированных. «Мухаммадия» написана как поэма в жанре на'т, т. е. восхваления Аллаха и пророка Мухаммада. Хотя эта линия продолжает оставаться основной, по ходу повествования затрагиваются все темы, имеющие отношение к Исламу, в том числе и религиозная история, начиная от сотворения мира, жизнеописания пророков от Адама до Мухаммада, говорится об его сподвижниках, четырех халифах, Рае и его садах, о Судном дне, знамениях его приближения, приводятся толкования отдельных сур, хадисов и многое другое. Одним словом, «Мухаммадия» охватывала практиче-

ски все основные вопросы вероучения ислама и религиозную историю в поэтической форме. Вероятно, это и обуславливало ее широкую популярность. Но стихотворная форма произведения, предполагающая метафоры и поэтические образы, обилие арабских и персидских терминов, а также обращение к специфическим религиозным и суфийским темам, делали «Мухаммадию» временами сложной для понимания.

Учитывая все это, турецкий ученый, толкователь Корана (муфассир), музыкант и суфийский наставник, считающийся одним из самых авторитетных шейхов тариката Джальватия Исмаил Хакки Бурсеви создал комментарии к этому произведению под названием «Шарху аль-Мухаммадия Фарраху ар-рух» («Комментарии к «Мухаммадие» «Радость для души»»). Кем является этот автор, и в чем значение его работы?

Родился этот выдающийся деятель в 1063 г. по хиджре (1652–1653) в Айтос, который сейчас находится на территории Болгарии. Он получил хорошее образование, в молодом возрасте перебрался в Стамбул, где стал учеником шейха тариката Джальватия Атпазари Османа Фазли. Как халифа[1] своего наставника сначала был отправлен в Скопью (ныне Македония), а потом в Бурсу. Так как он долгое время жил в Бурсе, то наиболее известен под своей нисбой[2] «Бурсеви». Позже его учитель сделал его своим преемником и после его смерти Исмаил Хакки возглавил тарикат. По приглашению великого визиря Элмаса Мехмеда-паши Исмаил Хакки Бурсеви участвовал в австрийских походах султана Мустафы II, своими проповедями воодушевляя солдат. Два раза совершил хадж – в 1700 и 1710 гг. Исмаил Хакки Бурсеви общался со многими высокопоставленными лицами – пашами, визирями. На протяжении своей жизни он проживал в разных городах, но под конец жизни, когда ему было 73 года, вернулся в Бурсу, где занялся написанием книг. Здесь он скончался 20 июля 1725 г.

Исмаил Хакки Бурсеви почитается в Турции как святой. В Бурсе на улице Тузпазары располагается его текке[3], именуемое «Исмаил Хакки теккеси» (İsmâil Hakkı Tekkesi). Когда-то это был целый комплекс (куллия), примыкающий к дому, где жил сам суфий. Он состоял из чилехане[4], странноприимного дома (мисафирхане), семахане[5] и мечети. Но до наших дней сохранились только чилехане, гробница святого, небольшое

1 В суфизме «халифа» – это представитель своего шейха, наделенный некоторыми полномочиями своим наставником.

2 Часть арабского имени, обозначающая этническую, религиозную, политическую, социальную принадлежность человека, место его рождения или проживания и т. д.

3 Текке, теккия – распространенное в Турции название для суфийских обителей, приютов.

4 Чилехане – место, где суфии оставались на какой-то срок для совершения уединения – «чиле», отрекшись от земных дел.

5 Семахане – пространство, выделенное для совершения одного из видов суфийского поминания «сема».

кладбище и фонтан. В 1964 г. на месте прежнего семахане была построена мечеть, которая была названа в честь Исмаила Хакки Бурсеви.

Большое влияние на Исмаила Хакки Бурсеви оказал крупнейший представитель и теоретик суфизма Ибн Араби (1165–1240). Аль-Бурсеви сыграл свою роль в распространении в Малой Азии его концепции «единства существования» (вахдат-и вуджуд). На Исмаила Хакки также повлияли такие суфийские авторитеты, как Джалалуддин Руми (1207–1273), Садреддин Коневи (1207–1274), Уфтада (1490–1580), Азиз Махмуд Худаи (1541–1628).

Но каково бы ни было мнение Исмаила Хакки Бурсеви по отдельным вопросам, следует подчеркнуть, что в целом он был строгим приверженцем принципов ислама и монотеизма, а все используемые суфиями методы, такие как «поминание» (зикр), считал помогающими приблизиться к Всевышнему и обрести веру в истинном смысле.

Исмаил Хакки Бурсеви является плодотворным автором – как сообщается, его перу принадлежит более 100 произведений по разным исламским дисциплинам на персидском, арабском и турецком языках. В своих произведениях он использовал более простой стиль по сравнению с цветастой речью его современников. В частности, ему принадлежат труды по толкованию Корана – тафсиры. Собственно, его «Рухуль-байан фи тафсириль-Куран» является наиболее известным его произведением и считается одним из самых выдающихся тафсиров, созданных во времена Османской империи. Также ему принадлежит ряд книг по хадисоведению, исламскому праву, каляму[1], грамматике и т.п. Кроме того, он писал и поэтические произведения. Некоторые из его стихов были положены на музыку. Труды по тасаввуфу, вероятно, являются самыми многочисленными среди письменного наследия Исмаила Хакки Бурсеви. Помимо комментариев к «Мухаммадие», его перу принадлежат комментарии к «Маснави» Джалалуддина Руми, «аль-Усуль аль-ашара» («Десять принципов») Наджмуддина аль-Кубры, к «Фусус аль-хикам» («Геммы мудрости») и «Люб аль-любб» («Суть сути») Ибн Араби. Как отмечается, труды Исмаила Хакки Бурсеви изучались как в суфийских кругах, так и медресе, поэтому его влияние было достаточно сильным.

«Фаррахур-рух» относится к широко распространенному в исламском мире жанру комментариев – шарх. Такие работы составлялись для разъяснения каких-то религиозных произведений, в них раскрывался смысл неясных выражений комментируемых книг, восполнялись имеющиеся в них пробелы по каким-то темам, указывались ошибки и т. п.

[1] Калям – догматическое богословие в исламе.

В исламском мире шархи имеют, вероятно, все более или менее значимые произведения.

Как заявляет Исмаил Хакки Бурсеви в «Фарраху ар-рух», «Мухаммадия» не только поэтична и наполнена глубокими чувствами, но и является достоверной с религиозной точки зрения, так как ее автор является великим исламским ученым и опирается на Коран и такие авторитетные труды, как тафсир «Кашшаф» Земахшари, сборник хадисов «Шифа» Кади Ийяда, а также на такие труды, как «Мукатил» Абу Нуайма Хафи аль-Исфахани, (430/1038), «Ат Тазкира фи ахвал аль-маута ва умур аль ахира» Куртуби, произведения Муджахида, Абу Ляйса ас-Самарканди, наследие Шамса аш-Ширази, Ибн Аббаса и т. п. Также, по словам Исмаила Хакки Бурсави, до «Мухаммадии» в книгах по жизнеописанию Мухаммада уделяли внимание только его «явным» (захири) качествам, между тем как Языджиоглу кроме этого пытается раскрыть и его «скрытые» (батыни)[1] черты.

В ходе комментирования «Мухаммадии» Исмаил Хакки останавливается на каждом слове, которое считает необходимым разъяснить. Например, он приводит смыслы каких-то терминов, указывает источники, раскрывает значение каких-то бейтов, приводит полностью хадисы или аяты, на которых имеются ссылки в тексте. Если Исмаил Хакки разъяснял какие-то бейты, это не значит, что он пояснял их простыми словами. Иногда его комментарии раскрывают какие-то сложные концепции, понять которые может быть даже труднее, чем сами стихи. Например, останавливаясь на смысле часто встречающегося в «Мухаммадие» термина *таджалли* «богоявление», «манифестация божества в мире», он описывает целую космологическую теорию: «Всевышний Аллах по Своей воле и несравненной мощи вывел все существующее из мира божественного повеления (алям аль-амр) в мир творения (алям аль-хальк). Ибо эта Вселенная из уровня единства (ахадиййат) и непостижимой сущности (гайб аль-хувийа) [Аллаха] спустилась на уровень скрытых качеств (шуун аль-гайбиййа), а оттуда – на уровень прообразов вещей в знании Аллаха (а'йан сабита аль-ильмиййа), оттуда – на уровень мира духов и неосязаемых образов (хакаик аль-арвахийа ва мисалийа), оттуда – на уровень осязаемых образов (сувар аль-хиссийа). Все эти выявления (зухурат) имеют в качестве основы «дыхание Божественной милости» (нафас ар-рахмани). Еще до этого проявления (таджалли) в Всевышнем существовало состояния *джиля*, т. е. Он проявлялся в Своей сущности. После возникло состояние истиджаль, т. е. Он проявился в творении» [Yazıcıoğlu: 2005. S. 91].

---

[1] *Захир и батын* – это фундаментальные понятия в арабо-мусульманской философии. Словом батын обозначают «скрытое», термин захир применяется для вещей «явных», воспринимаемых качествами или событиями.

Как уже отмечалось, Исмаил Хакки Бурсеви был шейхом тариката Джальватия, поэтому естественно, что зачастую его комментарии носят суфийский характер. Например, в «Мухаммадие» так описывается состояние Мухаммада после того, как ему в первый раз явился ангел:

«Хотя, увидев его (ангела), наш Пророк немного испугался, он, выказывая свое смятение, никому не стал жаловаться.

Отправившись домой, стал просить: «Укройте меня, я испугался». Хадиджа же стала утешать его:

«Ты поддерживаешь родственные связи, заботишься о сиротах.

Твои разговоры, твоя жизнь преисполнены порядка. Ты берешь на себя весь тяжелый груз (несешь на себе заботы своего народа).

Ты открыт с бедняками, почитаешь гостей. Ты с уважением относишься ко всем.

Внешне ты общаешься с людьми, проявляя прекрасный нрав, в душе же все время занят поминанием (зикр) Аллаха».

Исмаил Хакки Бурсеви находит в этих строках некий тайный смысл в русле суфийского учения о стоянках (макам): «Это указание на тайну [аята] «Разве Мы не раскрыли тебе грудь» (Коран, сура «аш-Шарх», 1). Под раскрытием груди имеется в виду такое состояние, когда пребывание с людьми, с тем, что является различным и множеством, не мешает пребывать с Истинным, который представляет Собой собранность и единственность. Это состояние возникает тогда, когда человек, избавившись от изменчивости, обретает упрочение и избавляется от всех завес. Это уровень посланников и совершенных святых. Кто не дошел до состояния самоуничтожения (фана) и постоянства (бака), тот не имеет никакой доли из этой стоянки (макам)» [Yazıcıoğlu: 2005. S. 271].

Интересно, что как в «Мухаммадие», так и «Фарраху ар-рух» можно найти какие-то научные представления о времени их создания. Йазыджиоглу пишет:

«Если Всевышний Аллах проявит милость, капля воды в горькой реке превратится в жемчуг, если Всевышний Аллах дарует прямой путь, свет пылинки затмит свет солнца».

Все это можно было бы принять за красивую поэтическую метафору, но Аль-Бурсеви находит в этих строках указание на научную истину: «Здесь имеет в виду то, что, как говорят комментаторы Корана (Рум, 30/41), капля воды, попадая в моллюска, именуемого мидией, превращается в жемчуг» [Yazıcıoğlu: 2005. S. 204].

В «Мухаммадие» сообщается:

«Когда какой-то город упорствует в своей непокорности Аллаху, если Аллах захочет его уничтожить, То натягивает его корни, сходящиеся к горе Каф, так возникает землетрясение».

Исмаил Хакки поясняет последнюю фразу, приводя мнение трех разных групп ученых: «Религиозные ученые утверждают, что землетрясение возникает по той причине, что ангел на горе Каф натягивает корни [того поселения]. Но ученые точных наук говорят, что причиной землетрясений является газ (в оригинале – *бухар*), находящиеся под землей. Т.е. когда газ, скопившийся под землей, находит выход на поверхность, то земля начинает колебаться, что приводит к землетрясениям. Согласно обладателям истины (ахль аль-хакика) причина землетрясения в том, что, как иногда трясутся члены человеческого тела, у земли есть свои внутренние части. Их колебание и вызывает землетрясение» [Yazıcıoğlu: 2005. S. 91].

«Фарраху ар-рух» является одним из самых популярных в исламском мире произведений Исмаила Хакки Бурсеви. По мнению некоторых авторов, «Мухаммадию» следует читать именно с комментариями, так как она включает некоторые неоднозначные моменты. Но «Фарраху ар-рух» ценно не только в качестве пояснения, раскрывающего смыслы «Мухаммадии», но и само по себе. Безусловно, она заслуживает более глубокого изучения.

В библиотеках Турции хранятся многочисленные рукописи этой книги. Кроме того, она несколько раз издавалась в своем оригинальном виде на арабской графике еще во времена Османской империи в 1252, 1255, 1256, 1258 г. по хиджре в Каире, а в 1274, 1294 г. по хиджре в Стамбуле. В конце XX в. книга была переведена на латинскую графику Мустафой Уфку и несколько раз издана.

Литература

1. Мухаметов И.Р. Книга Мухаммеда Челеби «Мухаммадия» в контексте татарско-турецких литературных взаимосвязей: автореф. … дис. … канд. филол. наук: 10.01.02. Казань, 2006.
2. Güngör Ö. İsmâil Hakki Bursevî ve eserlerine dair bir bibliyografya denemesi // The Journal of Turkic Language and Literature Surveys (TULLIS). 2020. № 5 (2). P. 199–232.
3. Karadaş C. İsmâil Hakki Bursevi / C. Karadaş, Y. Şevki // TDV İslâm Ansiklopedisi. İstanbul, 2001. S.107–110.
4. Namlı A. Kitâbetle Mübtelâ Olmak: İsmâil Hakkı Bursevî //Türkiye Araştırmaları Literatür Dergisi. 2018. – Cilt 16, № 31–32. S. 333–368.
5. Yazıcıoğlu M. Muhammediye, İsmail Hakki Bursevi'nin [Ferrah'r-Ruh şerhi ile], haz.: Abdülvehhap Öztürk. İstanbul: Çelik, 2005. – 1064 s.

ТӨБӘК ТАРИХЫ БУЕНЧА КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРҺӘМ ОЧРАШУЛАР
ХАТЛАР ҺӘМ КАЙТАВАЗЛАР

КРАЕВЕДЧЕСКИЕ КОНФЕРЕНЦИИ И ВСТРЕЧИ
ПИСЬМА И ОТКЛИКИ

ДАСТАННАРЫБЫЗНЫ ӨЙРӘНИК

Дастаннарыбыз аркылы хәзерге дәвергә кадәр килеп җиткән урта гасыр бабаларыбызның тормышы һәм көнкүреше турындагы информация уникаль һәм тарих фәне өчен бик тә кыйммәтле.

Д.М. Исхаков

Ирек мәйданының Опера һәм балет театры каршындагы бик күркәм урында урнашкан Бөтендөнья татар конгрессы (БТК) бинасына кереп, Мәскәүдә чыга торган «Татар дөньясы» гәзитенең килгән номерларын алып укырга гадәтләнгән идем. Ул гәҗитләрне вахта янындагы өстәлгә куеп, теләгән кешегә алырга рөхсәт итәләр иде.

Чираттагы керүемдә, калын гына итеп эшләнгән бер журналның матур тышлыгына ап-ак хәрефләр белән язылган «Туган җир» исеме күземә чалынып калды да, икенче килүемдә, бер чибәр генә, читтәрәк басып торган кыздан шул журнал турында сорадым.

«Сез журнал турында мәгълүматны Мөнирә апа Хәлимовнадан сорагыз», – дип, ул журнал редакциясенең адресын язып бирде. Редакция якында гына, Пушкин урамының 52 нче йортында урнашкан икән.

Мине баш Мөхәррир Дамир Мәүләви улы Исхаков, җаваплы сәркатип Мөнирә Хәлим кызы һәм алар белән эшләгән редакция хезмәткәрләре бик җылы каршы алдылар.

Шушы көннән башлап мин «Туган җир» журналының төбәк тарихы «дөньясына» кереп чумдым.

– Менә сиңа туган җир, менә сиңа ата-бабаларыбызның гасырлар дәвамында үткән юллары…

– Менә сиңа аларның тормыш юлындагы көрәшләре, җиңүләре, җиңелүләре…

– Менә сиңа алардан безнең буынга калган мираслары, аларның дәвамлы булуы, саклануы; сакланмаганнарының үзәкләрне өзеп, йөрәкләрне әрнетеп торулары…

Кулымда «Туган җир»нең 2022 елгы махсус саны. Бу санда, «Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих» дигән исем астында («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннарына һәм тарихи риваятьләргә анализ)ны Д.М. Исхаков үзе башкара.

Бу, минем фикерләвемчә, халкыбыз өчен, милләтебез өчен искиткеч олуг хезмәттер бит!

Бу язмаларны анализлау түгел, укып кына чыгар өчен дә күпме тарихи белемле булу кирәктер!..

Йә, Раббым Аллаһ!

Халкыбызны ата-бабаларыбызның мирасы булып сакланган динебез исламнан, алар калдырган белем нигъмәтләреннән һәм рухи байлыклардан аерма!?

Балаларыбызны, оныкларыбызны мәктәпләребездә туган телебез – татар телендә укытып, халкыбызның дастаннары аңлаешлы, җиңел телдә язылган уку дәреслекләрен кулларына тоттырып, тарихыбызның чынын күңелләренә сеңдереп, милли рухта тәрбияләп үстерергә насыйп ит!?

Боларның барысында саклап калу һәм үзгәртмичә үстерү юлларын үтеп киләсе буыннарга да тапшыру, безнең изге бурычыбыз бит!..

Күп гасырлар дәвамында
Телең, динең тыелгач,
Әллә инде башың идең
Башка чара тапмагач?
Тыелудан әллә арып
Башың түбән иясең?
Башларыңны аска иеп
Анда ниләр күрәсең?
Бабайларның көрәш юлын
Әллә тузан каплаган?
Ул тузанны туздырырга
Әллә көчең калмаган?
Милли горурлык хисләре
Бабайларда – тумыштан
Ул хисләрне саклап калу
Безнең изге бурычтан!

Мәгариф Раянов, 6 гыйнвар 2023 ел, Казан.

ҺӘР ТӨБӘККӘ АЕРЫМ ТЕЛ КИРӘКМЕ?

Мин, Бакиева Рәшидә Корман кызы, Төмән өлкәсенең Тобол районындагы Маслау авылында яшим. Юкка чыккан Комарау авылы кызымын.

Авыл башлангыч мәктәбендә укып, аннан Саускан җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Тобол татар педучилищесында, Тобол пединститутының РТО бүлегендә белем алдым (Г. Саттаров, А. Әхмәдуллиннардан һ.б. белем алдым). Авыл мәктәпләрендә рус телен, 1990 нчы еллардан татар телен укытып, 44 еллык стаж белән пенсиядә яшәп ятам.

Картайган көндә бездәйләрдән беркемгә дә зарар яки файда булмаса да, дөньядагы хәлләрдән, милләт тормышындагы актуаль мәсьәләләрдән читтә каласы килми. Барсы да борчый, уйландыра. Кайчагында уй-фикерләреңне җәмәгатьчелеккә дә җиткерәсе килә. Мәсьәлә әлеге дә баягы тел турында. Соңгы елларда Төмән якларында милләт өчен җан атып яшәгән, эшләгән шәхесләр белән беррәттән, эш юкта эш, проблема юкта проблема итеп әллә нәрсәләр уйлап чыгаручылар барлыкка килде: имеш, себер (сыпыр) татарлары үз себер телләре белән аерым бер яңа милләт, инде хәзер XXI гасырда яшәп яткан тагын бер милләт килеп чыгамы икән болай булса?.. Барлык җир шарында яшәгән татарлар бер татар телле бер милләт иде бит моңа кадәр. Халык санын алу буенча илдә икенче урына торган татар милләте эчендә таркаулык таратып, телне белмәгән, рус милләтеннән булган түрәләрне, себер татарлары – башка милләт, дип ышандырып йөрмәскә кирәк иде.

Югары органнарга (авыл администрациясеннән алып министрлыкларга кадәр) үз милләтебез вәкилләрен күтәрү кулайрак булыр иде. Төмән өлкәсеннән университет профессоры Хәнисә Алишина, Татар конгрессының Төмән өлкәсендәге вәкиле Ринат Насыйров Тобольск шәһәре һәм районының себер татар автономиясе бүлеге җитәкчесе Зәйтүнә Тычинских һәм башка татар үзәге җитәкчеләре эше безгә үрнәк түгелме?! Алар җитәкчелек иткән, башкарган эшләрнең барысы да телне, гореф-гадәтләрне, сәнгатьне, динне, гомумән, татарлыкны саклап калуга юнәлдерелгән. Киләчәктә аларга лаеклы алмаш әзерләү җәһәтендә уйлану, эшләү урынына милләткә кирәкмәгән башка эшләр эзләп йөрмәсен иде уңган, булган улларыбыз, кызларыбыз. Кем себерчә сөйләшергә тели – сөйләшсен, китап-шигырь язарга тели – язсын, болар барысы да татар милләтенең байлыгы, бер тармагы булып тарихта калыр, сакланыр. Тик аерылырга кирәк түгел, чөнки «аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» дигән мәкальне кем генә белми. Мәсьәлән Ф.Ю. Йосыпов, И. Кадыйровларның 2021 нче елда дөнья күргән хезмәтләре фән ягыннан мөһим эш булса да, аерылып чыгар өчен нигез була алмый. Бу фикер-уйларым себер татарларының бик күп күренекле, укымышлы шәхесләренең шушы мәсьәләгә карашы белән бердәй. Мәсәлән, болай уйлаучы өлкә мәктәпләрендә та-

тар телен укыткан укытучылар, атказанган шәхесләр, шагыйрь-язучылар шактый күп. К. Садыйков, С. Бекенин, Х. Речебакиева, Г. Абайдуллина кебек шундый шәхесләрне биредә шактый озак санарга мөмкин.

Бу яңа тел уйлап чыгаручылар мәктәп елларында татар телен укымагандыр, мөгаен. Аның тәмен-ямен татырга, күрәсең, мөмкинлекләре булмый калгандыр (Тукай әйтмешли, картайгач и эш белү уңайсыз ул).

Дөрес, әдәби телне өйрәнгәндә кыенлыклар булмый калмый, ләкин авырлыклар җиңеп чыкмаслык түгел. Сүзлекләр, телнең грамматик кагыйдәләре һәм башкалар бар бит.

Әдәби телне өйрәнү, белү башка телләрне дә (мәсәлән, рус, инглиз һ.б.) үзләштерүгә ярдәм итә, үзебезнең себер сөйләм телендәге саңгыраулашу (анда яңгырау авазлар юк) бары тик кыенлыклар тудырачак. Әйтик бу бала башка бәла булды, диләр. Моны «пу пала пашка пәлә пулты», дисәк килешми бит. Татар себер диалектын өйрәнү җәһәтендә аз эшләнми. Соңгы вакытта Төмән галимәсе Сания Нәсыйбуллина сүзлеге дөнья күрде. Моннан тыш, себер татарларының һәр төбәктәге сөйләмнәре икенче урында яшәгәннәрдән шактый аерыла. Шулай булгач, һәр төбәккә үзенчә бер аерым тел кирәк булып чыгамы?

Татар әдәби теле ул Казан теле түгел (күпләр юкка гына мин казанча белмим дип әйтәләр). Татарстанның да төрле төбәкләрендә үз үзенчәлекләре шактый күп, хәтта кайберләрен аңлавы да авыр. Шулай булгач, уртак, бөтен дөнья татарларының теле инде ул – әдәби татар теле. Ул бай тарихлы, гасырлар буе яшәп, тулыландырылып бара торган тел дияргә була. «Белем алу – инә белән кое казу ул», – дип юкка гына әйтмәгән халык. Димәк, әдәби телне белү өчен дә укырга, өйрәнергә, эзләнергә кирәк. Шуның өчен дә гаиләдә, балалар бакчасында, яслеләрдә, мәктәпләрдә татарча укытырга, сөйләшергә өйрәтергә кирәк дибез. Татар мохите булмау, телевидение-интернет заманында телне белмәү, аны өйрәнүдән ерак тору куркынычлары – бу инде замана чире, дисәк тә була. Оныкларыбыз, рәхмәт, сау булыгыз, исәнмесез, әби-бабай, дигән сүзләр белән генә чикләнәлә ич хәзер. Ата-аналар да бу хәлләргә кул гына селки, чөнки алар үзләре дә татар телен өйрәнмәгән, күпчелеге мәктәпләрдә укымаган хәзерге заман буын кешеләре. Димәк, г. Исхакый фикеренчә, ике йөз ел үтүгә телебезнең юкка чыгу куркынычы ап-ачык. Алай да, өметсез – шайтан, диләр. Телне саклап калу өчен төрле ысуллар, эзләнүләр дәвам итсен иде. Мәчет-дин белән бәйләнешләр ныгысын, аның уңай якларын татырга Аллаһы Тәгалә ярдәм итсен иде. Дөньяда милләтебезне, аның телен, данын, үзенчәлекләрен күрсәтә алган себер татар язучыларыбыз Булат Сөләйманов, Якуб Зәнкиев, Солтан Садыков, Альберт Урмаев, хәзер иҗат итеп яшәгән төбәк шагыйрьләребез аралашу-сөйләшү үрнәкләрен бирә. Аларның әсәрләрен өйрәнүдән туктамасак иде, чөнки алар әдәби татар телендә язган һәм яза.

Бер сүз белән әйткәндә, төп юнәлештән читләшмичә, төрле проблемалар китереп чыгармый гына, авылдамы, шәһәрдәме барлык татар милләт балаларына татар телен өйрәнергә, аны онытмаска, дәрәҗәсен күтәрергә һәм милләтебез белән горурлык хисләре уяту юлларын (ысулларын) эзләүдә бергә, бердәм булырга кирәк. Төп максатны белү, ычкындырмау, аңа хезмәт итү – барча милләт баласының бурычы.

«Яңарыш» газетасы битләрендә әледән-әле шигырьләрен бастыручы Күкрәнде авылы егете Фәрит Ермышевның бер шигырен дә искә алып үтәм.

Кара йөзләр

«Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр»
Г. Тукай

Килеп чыкты кара йөзләр – «милләтчеләр»,
Татарларны аерырга өндәүчеләр
Йөри алар арабызга ачу кертеп,
Бердәмлеккә, татулыкка утлар төртеп.

Акыралар алар тамак ярып,
Арабызга ызгыш, коткы салып.
Имеш, Казан безгә дошман булган,
Казан безнең телебезне буган.

Әллә телебезне Казан тыйган?
Казан баскан? Безне Казан кырган?
Әллә Казан авылларны яккан?
Казан килеп мәктәпләрне япкан?

Җырларыбыз уртак безнең, уеннар да,
Туган булып береккәнбез буыннарда.
Бергә аккан якты елга китмәс кире
Ят булганмы әллә безгә Тукай теле.

Мәдәният – уртак мирасыбыз.
Читкә этик шушы эче караларны.
Казан теле, себер теле – бертуганнар,
Без юләрме аерырга араларны?

Без яшәрбез барсак кына бергәләшеп
Дуслар булып, көн итешсәк бергәләшеп
Җитәкләшеп, ярдәмләшеп бергә барыйк!

Аерылсак, гафу итмәс безне тарих...

Ноябрь, 2022 ел.

Рәшидә Бакиева
Төмән өлкәсе, Тобол районы, Маслау авылы.

ХРОНИКА

2022 елның 28 октябрендә Әтнә районы Күшәр авылында «Асылташ» этно-фольклор фестивале булып узды. Республиканың төрле төбәкләреннән һәм Мари республикасыннан җыелган фольклор төркемнәре каршында Күшәр авылының борынгы тарихы турында тарих фәннәре докторы, «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире Д.М. Исхаков чыгыш ясады. Авылның урта гасыр чоры тарихы атаклы татар бәкләре һәм морзалары нәселеннән булган Яушевлар белән бәйле булганлыктан, чарада шул нәселдән булган Рәис Яушев һәм Булат Яушев катнашып, халыкка авылның элекке тарихы турында бай мәгълүмат җиткерделәр.

31 октября – 3 ноября 2022 г. в Москве состоялся Международный научный конгресс XVIII Фаизхановские чтения «Ислам в России: прошлое, настоящее, будущее», посвященное 1100-летию официального принятия ислама народами Волжской Булгарии, Году культурного наследия народов России, 15-летию Издательского дома «Медина» и Дню народного единства. В работе форума на секции «Ислам в локальной истории и историческом краеведении» активное участие приняли ученые из Татарстана, в том числе доктор исторических наук, гл.редактор журнала «Туган жир. Родной край» Д.М. Исхаков (тема доклада: «К вопросу о глубинных причинах антиджадидистских постановлений Татарского обкома ВКП(б) 1948 и 1952 гг. (в связи с учебниками по татарской литературе)» и кандидат исторических наук, зам. гл. редактора журнала А.А. Бурханов (тема доклада: «Научно-краеведческие исследования и вопросы сохранения и возрождения татаро-мусульманского наследия (на примере археологических, эпиграфических и архитектурных объектов»).

11–12 ноября 2022 г. в Сибирском институте управления – филиале РАНХиГС, состоялась межрегиональная научно-практическая конференция «Коренные народы Сибири: прошлое и настоящее». На конференции обсуждались проблемы коренных народов, установление межэтнических, научных и культурных связей сибирских народов с другими народами и вопросы национальной политики в РФ. От журнала «Туган жир. Родной край» выступил к.и.н. Ильнар Гарифуллин с докладом о статусе коренных народов согласно международной и российской практике.

Основным инициатором проведения данной конференции стала «Региональная Национально-культурная Автономия Новосибирской области».

По ходу мероприятия представители барабинских татар заявили о создании ими учебных пособий для изучения диалекта чацких татар на уроках изучения родного татарского языка. Пока в планах проведение занятий в местном сельском медресе.

После проведения конференции председатель РНКА Новосибирской области Амир Гареев провел экскурсию по ГБУК НСО «Новосибирский областной татарский культурный центр», где ознакомил гостей с работой данного учреждения. Новосибирский областной татарский культурный центр был реконструирован в прошлом году. Финансирование ремонта и обустройства Центра поделили между собой Республика Татарстан и Новосибирская область. В центре имеются кабинеты для занятий, звукозаписывающая студия, большой зал для заседаний, столовая. Сам Центр стоит на балансе бюджета Новосибирской области. Стоит упомянуть, что подобных обустроенных татарских национально-культурных центров в РФ всего несколько и они расположены в регионах с относительно небольшой численностью татарского населения.

14 ноября 2022 в Тобольске (Тюменская область) прошел «круглый стол» «Валеевские чтения», посвященный памяти доктора исторических наук Ф.Т. Валеева по теме «Татарские поселения Западной Сибири: история и современность». В ходе мероприятия состояласҗ презентация книги И.Ш. Кадырова «Татар халкының туй йолалары. Себер ареалы» (Казан, 2021), подготовленная д.ф.н. И.Г. Закировой. На «круглом столе» по этому случаю приняли участие ученые из Казани: Д.М. Исхаков, д.и.н., гл.редактор журнала «Туган җир. Родной край»; О.Р. Хисамов, к.ф.н., зам. директора ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АНТ; а также научные сотрудники из этого учреждения И.Г. Закирова (д.ф.н.), А.Я. Хусаинова (к.ф.н.).

15 ноября перед студентами Тобольского филиала ТГУ были прочитаны 3 лекции: 1) О татарских дастанах и их исторических основаниях (Д.М. Исхаков); 2) Тюрко-татарская топонимическая система Западной Сибири (О.Р. Хисамов); 3) Национально-культурное наследие: по следам научных экспедиций в Сибирь (А.Я. Хусаинова).

Прошедший при участии местных краеведов «круглый стол» был весьма содержательным, а лекции вызвали значительный интерес студентов. Подготовка данного мероприятия была проведена НКА Тобольска, (руководитель – к.и.н. З.А. Тычинских).

19 ноября 2022 г. в Уфе состоялся съезд Конгресса татар Башкортостана (одна из старейших национальных организаций республики, проводившей в свое время съезды татар). В работе съезда приняли участие

215 делегатов. Выступления оказались весьма информативными. Рассказывалось о том, что делается в республике исходя из скромных возможностей. Атмосфера вокруг татар в Башкирии многократно сложнее, чем в любом другом регионе РФ. Прозвучали выступления и об общих проблемах – о том, что спасение языка невозможно в рамках семьи.

В резолюции и выступлении председателя организации – З. Хакимова прозвучало требование открыть наконец-то татарскую редакцию для передачи на республиканском ТВ–БСТ, содержащемся на налоги, в том числе и татар, проживающих в РБ. Предлагалось построить при содействии государства татарский национально-культурный центр. А подобные центры есть в регионах РФ – в Марий-Эл, Новосибирской области и т.д. Главное, они являются учреждениями, находящимися на балансе бюджета регионов – что справедливо, учитывая, что государственный бюджет формируется за счет уплачиваемых налогов. Порадовало, что делегаты подняли вопрос о включении в резолюцию съезда пункта о необходимости возвращения в республике татарскому языку государственного статуса. Напомним, что это требование является неизменным с момента формирования татарского национального движения Башкортостана в 1980-х гг. Съезд отдельным голосованием поддержал этот пункт. Ясно, что это было решение именно делегатов, а не просто организаторов мероприятия. По сути данный пункт был о субъектности татар и необходимости равноправия трех основных этносов в республике. Без решения этого вопроса другие вопросы в Башкортостане не будут решены.

«Аулак өй-баттл» в Балтасях

23 ноября 2022 г. во Дворце культуры с. Балтаси Балтасинского района Республики Татарстан состоялась очередная интеллектуальная битва сельских команд по популярному в республике проекту «Аулак өй-баттл».

На это праздничное мероприятие были приглашены гости из Казани: автор и руководитель проекта по сохранению и распространению татарского языка «Аулак өй-баттл» Сария Закирова; поэтесса, член Союза писателей РТ, лауреат премии им. Ангама Атнабаева и Сажиды Сулеймановой, педагог высшей категории Казанской гимназии № 5 Галия Гайнутдинова; заведующая отделом газеты «Шәһри Казан», преподаватель КФУ Расима Галиева; член Союзов журналистов РТ и РФ, лауреат премии им. Ангама Атнабаева, главный метролог приборостроительного предприятия АО «Теплоконтроль» Томас Нигаматзянов.

Битком набитый восторженными зрителями зал красивого Дворца культуры в течение трёх часов болел за свои команды, которые на красочно оформленной сцене в различных конкурсах демонстрировали свои

знания по татарскому фольклору и литературе, а также умения петь народные песни и плясать под гармонь.

Было пять сельских команд, наряженных в национальные костюмы разных цветов: «Җәүһәр» из д. Сардек, «Кенәбаш йолдызлары» из д. Княбаш, «Ядкәрь» из д. Кушкетбаш, «Бурбаш» из д. Борбаш и «Субаш йолдызлары» из д. Субаш.

Церемония награждения победителей была предоставлена заместителю главы администрации Балтасинского муниципального района Ильшату Галимуллину, который также выступил с приветственной речью. Всем членам комады, занявшим первое место, Сария Закирова вручила по сборнику стихов разных авторов – подарки ВКТ.

В итоге первое место заняла команда «Субаш йолдызлары», второе – «Борбаш» и «Ядкәрь», третье – «Җәүһәр», а четвёртое – «Кенәбаш йолдызлары».

Томас Нигаматзянов

Уньеллыкка багышлап

2022 нче елның 27 ноябрь көнендә Төмәндә, «Себер татар теле көне» бәйрәме уздырыла башлауның уньеллыгы уңаеннан, «Чимги-Тура (Төмән) шәһәренә нигез салу вакытын ачыклау мәсьәләсенә бәйле чараларны оештыру һәм уздыру» дигән темага түгәрәк өстәл үткәрелде. Аны Төмән шәһәре Себер татарлары милли-мәдәни мөхтәрияте оештырды.

Әүвәл чарада катнашучыларны Төмән өлкәсе Милләтләр эшләре комитеты баш белгече З.Е. Кәлимуллина, БТК вәкиле Р.Р. Минһаҗев, Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте вәкиле Ф.Б. Гарифуллин, «Нәүрүз» Үзбәк милли җәмгыяте өлкә иҗтимагый оешмасы рәисе Б.Д. Түләгәнов котлады.

Аннары җыелган халык алдында Төмән шәһәре Себер татарлары милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе Д.М. Абукин, Б. Сөләйманов исемендәге премия лауреаты («Җәмәгать эшлеклесе» номинациясендә) Ә.Г. Гаитов, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары М.М. Гыйбатдинов, культурология докторы, профессор В.И. Семенова, БТК Төмән өлкәсе буенча вәкиле Р.Х. Насыйров, Үзәк Диния нәзарәтенең Төмән өлкәсе буенча мөфтие И. Җиһаншин, Төмән шәһәре Себер татарлары милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе урынбасарлары Д.А. Шамратова, Р.М. Насыйбуллин, Төмән шәһәре Музей технологияләре үзәге директоры Р.Х. Рәхимов чыгыш ясады.

Түгәрәк өстәл ахырында 2023 нче елны «Сыбырлар: чыганаклар, хәтер, варислар. Россиянең күпмилләтле халкы турында тарихи дөреслек»

дигән халыкара экспедиция әзерләү һәм оештыру елы; 2023 нче елны Төмән шәһәре Себер татарлары милли-мәдәни мөхтәриятенең 15 еллыгы, «Себер татар теле көне» бәйрәме дип игълан ителүнең 10 еллыгы, Себер татарларын үстерү стратегиясен халыкка танытуның 5 еллыгы дип игълан итәргә; 2023 нче елны нигезендә сыбырлар идеясе яткан Төмән туризм платформасын әзерләү елы дип белдерергә дигән карар кабул ителде.

Рәшит Минһаҗ

4 декабря 2022 г. в БКЗ им. С. Сайдашева Казани состоялось мероприятие, посвященное 15-летию электронного издания Бизнес-Online. На нем присутствовал главный редактор журнала «Туган җир. Родной край» доктор исторических наук Д.М. Исхаков. Торжества собрали многочисленную публику и были хорошо организованы. В том числе состоялся очень хороший концерт из произведений Бетховена под руководством известного дирижера А. Сладковского.

8–9 декабря 2022 г. в Тобольске Тюменской области прошел IX Всероссийский симпозиум «Культурное наследие народов Западной Сибири: угры», посвященный 200-летию Сибирской реформы М.М. Сперанского и 250-летию со дня рождения реформатора. В работе симпозиума приняли участие доктор исторических наук, ст.научный сотрудник ТКНС УрО РАН, гл.редактор журнала «Туган җир. Родной край» Д.М. Исхаков, кандидат исторических наук, ст.научный сотрудник того же учреждения, спецкорр журнала З.А. Тычинских (темы их доклада: «Легенда заболотных татар об Илек-алпе и вопрос об угорском компоненте в этногенезе сибирских татар», «Иштяк-тугум: к вопросу о тюрко-угорских взаимодействиях на территории Западной Сибири»). В рамках данной поездки в Тюмени произошла встреча с представителем ВКТ в Тюменской области Р.Х. Насыровым для уточнения структуры формирующегося при участии Татарстана в Тюмени музейно-просветительского центра «Чимги-Тура». Обмен мнениями по этому поводу был связан главным образом с решением дизайнерских аспектов выстраивания настоящего музея.

Саклагыз нигез ташын

2022 елның 17 декабрендә Балтач районының Бөрбаш авылында бик күркәм тәкъдим итү кичәсе булды. Моның сәбәбе шул: авыл фидакарьләре туып үскән карьяларының тарихына багышлап «Саклагыз нигез ташын» дигән китап нәшер иткән.

Кичәне ачып, әлеге тантананы алып баручы һәм бу изге эшнең башында торучы, ТР Диния нәзарәтенең баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе һәм Бөрбаш мәчете имам-хатибы Җәлил хәзрәт Фазлыев, шушы чараның берүк вакытта авыл мәчетенең утыз еллыгы белән туры килүен дә билгеләп үтте. «Авылыбызда 236 йорт-нигез булып, шуларның 84е турыдан-туры Бөрбаш тарихына бәйле булган Карабәк нәселенә карый», – дип белдерде. Аның сөйләве буенча, авылга нигез салган Көчек бабай бирегә XVI гасыр ахырында килеп утырган. Ул заманда авыл Бөрбаш дип түгел, нигез салучының исеме белән Көчек Пүчинкәсе дип аталган. Китап тәкъдим итү кичәсендә катнашкан тарихчы «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире Дамир Исхаков, бу тарафларның узмышын кыскача аңлатып, Карабәк нәселеннән чыккан затлы шәхесләр нигез салганга, авыл бүген дә яхшы хәлдә, дип нәтиҗә ясады.

Китап тәкъдим итү кичәсендә Татарстан Президенты аппараты каршындагы Мәдәниятне үстерү фондының башкарма директоры Нурия Хашимова, Балтач районы хакимияте башлыгы Рамил Нотфуллин, ТР Президенты Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Дини берләшмәләр белән бергәләп эшләү идарәсе башлыгы Альберт Дирзизов, Казан шәһәренең элеккеге мэры Камил Исхаков, БТК Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов һәм башка кунаклар чыгыш ясады. Кичә эчтәлекле булып, яхшы оештырылган да иде.

Рәшит Минһаҗ

Авыл үз тарихчысын зурлады...

2022 нче елның 29 декабре көнне, Яңа Чишмә районының Зирекле авылында күңелле вакыйга булды – шактый вакытка сузылган төзекләндерүдән соң халык иҗаты һәм көнкүреш музее яңадан ачылды. Бу – республикабызда иң билгеле, иң үзенчәлекле милли музейларның берсе, аның эшли башлавына инде 30 ел. Шушы вакыт эчендә музейның җитәкчесе булып Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт Гариф улы Газыймов эшләде. Мидхәт абый бу ел башында үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтте,

ә көз көне, бөтен эшен яшьләргә тапшырып, бакыйлыкка күчте. Бүгенге җыен аның рухына дога булып та яңгырады, Коръән укылды, сөйләгән һәр кеше Мидхәт Гариф улын олылап искә алды.

Әйе, Мидхәт Газыймов, Татарстанда беренчеләрдән булып, үзе җитәкләгән Зирекле авылы музеен республика дәрәҗәсенә күтәрә алды, ул моңа татар халкының милли үзенчәлекләренә, традицияләренә таянып иреште. Биредә дөньяда тиңе булмаган кул эшләре үрнәкләре, милләтнең гасырлар буе сакланган сандык малы тупланган. Мидхәт абый берәмтекләп җыйган чиккән сөлгеләр һәм намазлыклар, кашагалар һәм чигешләр, күкрәкчәләр һәм чигелгән аяк чолгаулары, чулпылар һәм калфаклар Казанда гына түгел, Мәскәүдә уздырылган күргәзмәләрдә дә катнашты, югары бәя алды. Мидхәт Газыймов Зирекле авылы тарихы, аннан чыккан күренекле шәхесләр, имамнар, һөнәрчеләр, сугыш корбаннары һәм ветераннар, туган авылының халык авыз иҗаты, бәетләре, мөнәҗәтләре, географик атамалары, гореф-гадәтләре турында документаль китаплар язып калдырды. Ул, чын мәгънәсендә, авылның елъязмачысы иде! Килер буыннар төбәк тарихын, милләт тарихын аның хезмәтләре аша өйрәнерләр, Гариф улы Мидхәткә догада булырлар, ин ша Аллаһ!

Музей ачылу тантанасында Яңа Чишмә районының башкарма комитеты рәисе, шушы авыл тумасы Ринат Фасахов, авыл имамы Ильяс хәзрәт, Бөтендөнья татар конгрессының татар краеведлары белән эшләү бүлеге җитәкчесе галим Альберт Борһанов, тарихчылар Фәүзия Бәйрәмова, Нурулла Гариф, Әлмәт районыннан Ризаэддин Фәхреддин исемендәге музей директоры Диләрә Гыйммранова, шагыйрә Миңзифа Әхмәтшина, республиканың төбәк тарихын өйрәнүчеләр, районадагы татар авылларының музей җитәкчеләре, Мидхәт абыйның гаилә әгъзалары, хатыны Зәйтүнә апа, балалары, авыл халкы катнашты. Бөтендөнья татар конгрессының төбәк тарихын өйрәнүчеләр оешмасы Зирекле авылы музеена Мидхәт Газыймов исемен бирү тәкъдиме белән район җитәкчелегенә мөрәҗәгать иткән иде. Бу җыенда музей диварындагы Мидхәт Газыймов исеме язылган элмә тактаны ачу тантанасы да булды.

Урамда башланган җыен яңартылган музейның эчендә дә дәвам итте. Дөрес, музей әле тулысында эшләнеп бетмәгән, күп экспонатлар әле һаман сандыкларда ята, бу кадәр күп милли байлыкка урын җитмәгәнлеге күренеп тора. Музейда исәптә торган биш мең экспонатның биредә нибары берничә проценты гына урын алган, аларның гүзәллегеннән күз камаша! Милләтебез хатын-кызлары бу матурлыкны гасырлар буе кышкы кичләрдә чыра һәм лампа яктысында чиккән, дөньяның бөтен гөл-чәчкәләрен, матурлыгын тукымага күчергән, бу милли мирасны кадерләп саклаган, нәселенә васыять итеп калдырган. Музейда чыгыш ясаган сән-

гать белгечләре, тарихчылар Нурулла Гариф, Фәүзия Бәйрәмова, Диләрә Гыймранова һәм башкалар милли чигешләрдә татар халкының рухи дөньясы чагылыш табуын, бу бизәк һәм чигешләрдә милләтнең холкы, затлылыгы күренүен әйттеләр, аларны махсус өйрәнергә киңәш иттеләр.

Язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмованың әйтүенчә, ул бу авылга инде егерме ел буе кайтып йөри икән, Зирекленең тарихын һәм музей эшчәнлеген өйрәнеп, фәнни-популяр хезмәтләр дә язган. «Бу авыл элек-электән бик дини, һөнәрле-булдыклы, мәгърифәтле булган, – диде ул. – Шушы тирәдәге татар авыллары арасында ул бер якты маяк кебек, үзәк булып тора. Моннан күп зыялылар, фән докторлары һәм кандидатлары, хәрбиләр, эшмәкәрләр чыккан, Мидхәт абый аларның барысы турында да язып калдырды. Ул җитәкләгән музей ике үзенчәлеге белән аерылып торды – милли рух һәм фәнни төгәллек. Мидхәт абый авылның шәҗәрәсен төзеде, архивлардан метрикаларның күчермәләрен кайтартты, сугышларда катнашкан һәм үлгән һәр авылдашының исемен торгызды, бу төбәктә иҗат ителгән авыз иҗатын туплап, дистәләгән китап чыгарды. Авылда нигезе калмаган кешеләр туган йорт итеп шушы музейга кайталар, үзләренең нәселләре турында дөнья кадәр мәгълүмат туплап китәләр. Инде Мидхәт абыйның үзе турында да китап чыгарыр вакыт җитте».

Музейның хәзерге җитәкчесе Лидия Лотфуллина әйтүенчә, инде булачак китап өчен материал туплана башланган. Мидхәт абыйның кызы Алсу да әтисе турында китап өчен килгән кунаклардан истәлек язмалары сорады. Халык бу очрашудан рухланып, милләт өчен сөенеп таралды, дөньяда нинди генә хәлләр барса да, тарихыбызны, рухи мирасыбызны сакларга кирәклегенә тагы бер кат ианды. Музей хезмәткәрләренә шушындый бай эчтәлекле очрашу уздырганнары өчен рәхмәт әйтеп киттеләр.

Әйе, дөньяны барыбер матурлык коткарачак! Җаннарыгызга ял кирәк булса, күңелләрегез милли матурлыкка сусаган булса, Яңа Чишмә районының Зирекле авылы музеена килегез, аның ишекләре һәркем өчен ачык!

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге,
2022 ел, 29 декабрь.

В Ижевске 12–13 января 2023 г. прошла встреча руководителей татарских общественных организаций Приволжского федерального округа, входящих в состав ВКТ. Мероприятие проводилось под руководством председателя Милли шуры ВКТ, вице-премьера Республики Татарстан В.Г. Шайхразиева. Кроме планов работ на текущий год, в ходе заседания обсуждалась проблема проведения мероприятий в рамках объявленного ВКТ в 2023 г. «Года национальных дастанов». По этому пункту высту-

пили доктор исторических наук, главный редактор журнала «Туган жир. Родной край» Д.М. Исхаков и кандидат исторических наук Ф.Х. Завгарова. Прошло также обширное ознакомление с состоянием дел в области сохранения татарской культуры и языка в Республике Удмуртия.

Ученые Татарстана высоко оценили деятельность Общества татарских краеведов при Всемирном конгрессе татар

12 января 2023 г. в Малом зале Академии наук Татарстана (ул. Баумана, 20) состоялось совместное заседание руководства Академии наук РТ и Татарстанского регионального отделения Петровской академии наук и искусств (ПАНИ – Санкт-Петербург) с участием известных ученых К(П)ФУ, Казанского государственного университета культуры и искусств, Казанского государственного аграрного университета, Казанского государственного медицинского университета, научно-исследовательских институтов АН РТ и других вузов Татарстана, а также артистов, художников и писателей. Были обсуждены некоторые итоги деятельности и определены перспективы совместной деятельности АН РТ и ПАНИ. Заседание вел вице-президент АН РТ, руководитель ТРО ПАНИ, член-корреспондент АН РТ, доктор экономических наук, профессор В.В. Хоменко, рассказавший об итогах совместной деятельности ученых АН РТ и ПАНИ и основных направлениях развития науки, а также об отчетно-выборной конференции ПАНИ, которая состоялась в Санкт-Петербурге в ноябре 2022 г.

Было принято решение о создании при ТРО ПАНИ историко-краеведческого отделения, которое возглавил академик ПАНИ А.А. Бурханов.

За активную и плодотворную деятельность в развитии науки в Татарстане награждены Благодарственными письмами АН РТ В.Ю. Корнилов, А.Ф. Галиуллина, С.М. Юнусова, а В.А. Ганеева награждена знаком отличия МОН РТ «Почетный наставник». Президент АН РТ академик М.Х. Салахов наградил Благодарственным письмом АН РТ начальника Комитета по работе с краеведами Исполкома ВКТ А.А. Бурханова.

А.А. Бурханов

«Эш атының» олуг юбилее

2023 нче елның 26 гыйнвары көнне Түбән Новгород өлкәсенең Пилнә районындагы Сафаҗәй авылында күренекле тарихчы, мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның тууына 200 ел тулуга (1823–2023) багышланган XIX төбәкара гыйльми-гамәли конференция – «Фәезханов укулары» булып узды.

«Фәезханов укулары».26 гыйнвар 2023 ел.

Анда Түбән Новгород лингвистика университеты прфессоры Ольга Сенюткина, КФУ прфессоры Айдар Хәбетдинов, педагогика фәннәре кандидаты, «Вести FM» радиосы алып баручысы Марат Сәфәров, җирле төбәк тарихын өйрәнүче Вафа Камалетдинов, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, теология фәннәре докторы Дамир Мөхетдинов, «Туган җир» журналы баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы, БТК Милли Шурасы әгъзасы Дамир Исхаков чыгыш ясады. Аерым алганда, О. Сенюткина Х. Фәезхановның шәҗәрәсен барлады. Д. Исхаков галимнең тарихи чыганакларны, тәгаен алганда, Болгар кабер ташларын, Казан, Касыйм, Кырым ханлыклары тарихын, шул заманга караган документларны өйрәнүен, Россиянең беренче шәркыять белгечләреннән булуын, Россия шәркыятьчеләре Вельяминов-Зернов, Казембекның, атаклы татар мәгърифәтчесе Мәрҗанинең бу бөек шәхеснең эш нәтиҗәләреннән киң файдалануларын билгеләп үтте. Д. Мөхетдинов та, әлеге фикерне куәтләп, Хөсәен әфәнденең «эш аты» булуын тәкърарлады, уку-укыту эшчәнлегендә җәдитчелек юнәлешенә нигез салучылардан булуын бәян итте. «Урыс телен мәдрәсәләрдә өйрәнергә чакырганы өчен, Казан имамнары Фәезхановны көферлектә гаепләгән. Хәзер без бу гамәлне татар җәмгыятен артка сөйрәү дип бәялибез. Дөрес: бүген галимнең туган авылында оештырылган чара урыс телендә уздырыла», – диде ул. Конфернцияне оештыручылар, галимнең олуг юбилеена багышланган чаралар әле башлана гына, ел дәвамында тагын үткәреләчәк, дип белдерде.

Конференция кунакларына бүләк ителгән китаплар, журналлар аеруча игътибарга лаек. Бу, беренче чиратта, Х. Фәезханов һәм аның энесе Габделгалләм Фәезхановның бер китапта җыеп бирелгән «Краткая учеб-

ная грамматика татарского языка», «Краткая научная морфология татарского языка» хезмәтләре. Шулай ук Хөсәен Фәезхановның Шиһабетдин Мәрҗанигә язган хатлары.

Дамир Мөхетдиновның «Ислам в современном мире» журналында (2022 елның июнь саны) дөнья күргән «XXI гасыр башында урыс телендә чыккан Коръән тәрҗемәләренә аналитик күзәтү» дигән мәкаләсе әһәмиятле, чөнки егерменче гасыр азагында, егерме беренче гасыр башында да татар телендә байтак Коръән тәфсире нәшер ителде. Тик әле аларга бәя бирергә тырышкан авторлар күренми иде.

Рәшит Минһаҗ

2023 нче елның 2 февралендә Интертат инициативасы белән Кәрим Тинчурин исемендәге театр тарафыннан куелган (режиссеры – Туфан Имаметдинов) «Идегәй» спектакле буенча бер төркем зыялылар катнашында «түгәрәк өстәл» үтте (катнашучылар арасында тарих фәннәре докторы, «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире Д.М. Исхаков та бар иде). Шушы «түгәрәк өстәл» тирәсендә сөйләшүнең төп нәтиҗәсе буларак мондый фикер әйтелде: күләмле һәм катлаулы әсәрләрне сәхнәләштергәнче экспертлар белән сөйләшүләр булырга тиеш.

7 февраля 2023 г. в Уфе в офисе Всемирного курултая татар прошла презентация книги подготовленной Маратом Хаковичем Ибрагимовым, племянником известного татарского писателя Галимджана Ибрагимова. Мероприятие, посвященное роману «Люди», прошло успешно, на представительном уровне. Выступали ученые, общественные деятели, отметившие актуальность и значимость данного труда. Тема голода 1921 – 1922 гг. и связанного с ним литературного наследия Г. Ибрагимова благодаря новой работе получила новый импульс и предстоит дальнешему изучению. Надеемся, что в ближайшее время Марат Хакович поделится своими исследованиями по поводу голода 1920-х гг. и с нашими краеведами.

V-й Поволжский межрегиональный форум татарских краеведов в Ульяновске…

7–8 февраля 2023 г. в Ульяновске на базе Центра татарской культуры Ульяновской обл., при поддержке Совета национальностей при Губернаторе областной ТНКА и Комитета по работе с татарскими краеведами Исполкома ВКТ состоялся очередной V Поволжский межрегиональный форум татарских краеведов. В работе форума примут участие свыше

110 делегатов – ученых, краеведов, учителей, работников культуры из районов и городов Ульяновской области, а также представители Республики Татарстан, республик Чувашия, Мордовия, Кемеровской и Самарской областей. Делегацию Татарстана возглавил А.А. Бурханов, в составе команды ученых и краеведов – заведующий Отделом истории Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, профессор К(П)ФУ Р.В. Шайдуллин, руководитель Общества краеведов Высокогорского района РТ, почетный работник общего образования РФ Р.З. Салиев, краевед-исследователь, мастер по национальным музыкальным инструментам из Казани Р.Х. Сабирзянов, директор школьного краеведческого музея и учитель истории из Рыбно-Слободского района РТ И.Г. Габдрахманов, а также руководитель Общества татарских краеведов Новокузнецка Кемеровской области, имам-хатыйб мечети «Чулпан» А.А. Аширов.

Активистами краеведческих структур и учеными области выпущено более 40 книг по истории татар региона и истории 23 татарских сел. В настоящее время подготовлены к изданию книги по истории 5 татарских селений, идет работа по сбору материалов книг по истории 9 сел и деревень.

В 2022 г. краеведы активно продолжали работу по увековечению памяти наших земляков восстановлению истории татарских сёл.

Большим достижением в жизни татар региона стало издание книги «Чердаклы татарлары» («Чердаклинские татары») (авторы З.С. Хакимов и Н.Ш. Потеева). Хорошо оформленное, большого объёма информация вышла в достаточно большим тиражом. Успешно прошла её презентация в р.п. Чердаклы в районном доме культуры и в библиотеке № 17 Ульяновска.

Издана небольшим тиражом книга по истории деревни Асаново.

Прошлый год стал годом проведения мероприятий по 110-летию со дня рождения Г.Р. Шамукова. В рамках гранта по этому поводу проведены спектакли, издана книга, вывешена мемориальная доска.

Налажено сотрудничество с краеведами соседних регионов.

Активное сотрудничество ведется Комитетом по работе с татарскими краеведами ВКТ, РОО «Общество татарских краеведов» РТ и краеведческими структурами Самарской, Саратовской, Пензенской областей, Чувашии и Мордовии.

А.А. Бурханов.

Нократ татарларын эзләп

Татарстан Республикасы Грантлар үзәге игълан иткән бәйгедә катнашып, Киров өлкәсе татарлары конгрессы оешмасының «Нократ татарла-

ры мәдәни коды» проекты җиңеп чыккан иде. Әлеге проектны гамәлгә ашырып, җирле конгресс вәкилләре 13–14 нче февраль көннәрендә Киров өлкәсенең Слободской районындагы Нократ авылына этноэкспедиция оештырды.

Аның эшчәнлегендә Киров өлкәсе татарлары конгрессы рәисе урынбасары, «Дуслык» өлкә татар газетасы хәбәрчесе Шәмсия Хәлимова, Нократ Аланы шәһәре башлыгы урынбасары Анна Слобожанинова, өлкәдәге «Наследие» дөнья халыкларының мәдәни традицияләрен тергезү берләшмәсе рәисе Марина Колесникова, Киров өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Зөфәр хәзрәт Галиуллин, фәнни консультант буларак, Бөтендөнья Татар конгрессы Милли Шурасы әгъзасы, «Туган җир» журналы баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков, Удмуртия Республикасының Кистем авылы имам-хатыйбы Илмир Касимов катнашты. Экспедициядә катнашучылар Нократ (Карино) авыл җирлеге администрациясе башлыгы Вагыйз Митюков, авыл мәчете имам-хатыйбы Нурзадә Девтяров, мәктәптәге туган якны өйрәнү музее җитәкчесе, тарих укытучысы Әлфия Долгаршиных, авыл китапханәсе мөдире Татьяна Девятьярова һәм башка нократлылар белән очрашып, клубта, «түгәрәк өстәл» янында авыл тарихы, халкының килеп чыгышы, җирле сөйләш үзенчәлекләре турында фикер алышты; Киров һәм Слободской шәһәрендәге туган якны өйрәнү музеендагы ядкәрләр белән танышты.

Рәшит Минһаҗ

Насыйри укулары – Насыровские чтения

Так называлась II Международная научно-практическая конференция, посвященная жизни, деятельности и творчеству выдающегося российского и татарского педагога, ученого, литератора, просветителя и энциклопедиста XIX в. Каюма Насыйри. Она была проведена в Казани 16–17 февраля 2023 г. на базе среднеобщеобразовательной татарско-русской школы № 80 Казани им. Каюма Насыйри в рамках Года Педагога и наставника в РФ и Года национальных культур и традиций в РТ. В работе конференции приняли участие более 120 человек – представители научной, педагогической и краеведческой общественности, органов власти Казани и районов Республики Татарстан, Москвы, Чувашии и других регионов РФ, Узбекистана (Бухара) и Кыргызстана (Ош), а также журналисты СМИ РТ.

17–18 февраля были проведены нижеследующие секционные заседания: «Этнопедагогика» (4 докладчика), «Науки о земле и природе» (11 докладчиков), «Науки о человеке и обществе» (7 докладчиков), «Изящная словесность» (11 докладчиков), «Информационные технологии

в образовании» (5 выступлений), «Секция студенческая» (29 докладчиков), «Секция педагогическая» (10 докладчиков), «Секция научных сотрудников» (8 докладчиков) и «Секция Я талантлив» (в формате – конкурса творческих работ) – 3 работы). Во второй половине дня 17 февраля 2023 г. в актовом зале школы состоялось Пленарное заседание форума.

А.А. Бурханов от имени руководства Всемирного конгресса татар вручил Благодарственные письма за активную научно-педагогическую и общественную деятельность Коллективу среднеобразовательной татарско-русской школы № 80 Казани им. Каюма Насыйри, директору данной школы, кандидату педагогических наук Р.М. Мансурову и вице-президенту РАЕН, академику И.Р. Утямышеву. Исполком Всемирного конгресса татар в качестве подарка для участников конференции и библиотеке школы передал около 200 книг и журналов по истории и краеведению, по татарскому языку и литературе.

А.А. Бурханов

2023 нче елның 20–21 февралендә Төмән өлкәсе Төмән шәһәрендә Урал федераль округындагы татар милли оешмаларының БТК Милли шурасы тарафыннан җыелган киңәшмәсе үтте. Башка мәсьәләләр белән бергә бу киңәшмәдә Милли дастаннар елына багышланган чыгышлар да булды (тарих фәннәре докторы, «Туган җир. Родной крй» журналының баш мөхәррире Дамир Исхаков, тарих фәннәре кандидаты Зәйтүнә Тычинских). Шушы җыелыш рамкасында Себер татарларында таралган милли дастаннар турында бер лекция татар җәмәгатьчелеге каршында Дамир Исхаков тарафыннан Тобольск шәһәрендә дә укылды.

ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ
РЕЦЕНЗИЯЛӘР

ИНФОРМАЦИЯ О КРАЕВЕДЧЕСКИХ ТРУДАХ
РЕЦЕНЗИИ

ЕРАК КӨНЧЫГЫШТАГЫ МӨСЕЛМАННАР ТУРЫНДА КИТАП

Ниһаять, «Мусульмане на Дальнем Востоке России. История и современость» дип аталган китап миңа килеп җитте. Дөрес, аның PDF вариантын мин инде яз көне үк укыган идем һәм китапны чыгаручыларга үз фикеремне әйттем. Ә фикерем – бу энциклопедик дәрәҗәдәге зур хезмәт! Һәм язылышы, һәм бизәлеше профессиональ югарылыкта, тарихи документлар, шәхесләр язмышы, дин әһелләре һәм дини оешмалар, мәчетләр төзелеше, аерым кешеләр белән әңгәмәләр, сирәк фотолар милләтебезнең Ерак Көнчыгыштагы тарихын ачып бирә. «Милләтебезнең», дим, чөнки китапның 80–90% – татарлар турында, ул берничә гасырлык тарихны үз эченә ала. Иркутски, Амур, Магадан, Чукотка, Камчатка, Якутия, Сахалин, Приморье, Забайкалье, Кытай чиге, Харбин-Манчжурияләргә хәтле таралып яшәгән, ислам динен тараткан һәм хәзер дә тотып торган милләттәшләрем турында бу китап. Монда Сахалин утравындагы каторжан татарлар язмышы да, Себергә, Ерак Көнчыгышка сөргенгә сөрелгән дин әһелләренең тарихы да чагылыш тапкан. Габдрәшит Ибраһимның 1908 елда язылган «Дөнья тирәли» хезмәтенең Ерак Көнчыгыш турындагы өлешләре русчага тәрҗемә итеп бирелгән. Минем «Сахалин утравы һәм татарлар» китабыннан андагы татар авыллары турында өзекләр русчага тәрҗемә итеп бирелгән. Болар өчен мин китапны чыгаручыларга рәхмәтле.

656 битлек бу уникаль, гаҗәеп затлы һәм файдалы китап 2020 елны Казанда басылган, әмма ул дөньяга 2021 елда гына чыкты. Казанда уз-

ган дин әһелләре җыенының бер секциясендә аны халыкка да тәкъдим иттеләр. Әмма мондый үзенчәлекле фәнни хезмәтне зуррак мәйданнарда, татар галимнәре катнашында тәкъдим итәргә, презентациясен дә уздырырга кирәк иде. Бу эшне Бөтендөнья татар конгрессы да эшли ала. Шулай ук Ерак Көнчыгышның үзендә дә бу китапның презентацияләрен уздырырга кирәк, дип уйлыйм.

Инде мондый зур хезмәт артында кемнәр торуын да әйтергә кирәк. Проектның авторы һәм җаваплы җитәкчесе – Гарифуллин Артур (Әхмәт) Сирен улы, ул Ерак Көнчыгыштагы мөселманнарның дини идарә рәисе. Китапның баш мөхәррире һәм мәкаләләр авторы – Екатеринбург шәһәреннән тарих фәннәре кандидаты Старостин Алексей Николаевич. Бу хезмәтне дөньяга китап итеп чыгару өчен галимнәрдән, химаячеләрдән, волонтер-ярдәмчеләрдән торган зур төркем булганлыгын да әйтергә кирәк, алар бөтен Россия буенча җыелган.

«Мусульмане на Дальнем Востоке России. История и современность» китабы Россиянең һәм Татарстанның дәүләт бүләкләренә лаек хезмәт.

Фәүзия Бәйрәмова

ВОТКИНСКАЯ МЕЧЕТЬ: ИЗ ПРОШЛОГО В БУДУЩЕЕ…



Так называется книга краеведа-исследователя и общественного деятеля из Воткинска (Удмуртская Республика) Айрата Шаукатовича Газимзянова. Она посвящена истории и общественной жизни мечети Воткинска. Идея написать книгу у Айрата Газимзянова появилась еще в начале 2000-х гг., когда в 2007 г. он познакомился с воткинскими прихожанами-старожилами, которые рассказывали истории, связанные с мусульманским храмом. Однако написание книги началось в 2018 г., после того, как были найдены исторические документы во время реконструкционных работ.

По мнению автора, эта книга позволит сохранить историю о Воткинской мечети и станет ценным историческим материалом для будущих поколений. Читателям книги представлен материал о строительстве мечети,

отражены биографии людей, внесших вклад в ее развитие, воспоминания старожилов, документальные факты из архивных материалов. Помимо основной темы рассматривается также история развития мусульманской общины поселка.

А.А. Бурханов,
председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ

НОВАЯ КНИГА

Р.И. Ахмеров. «Краткий очерк по истории с. Татарский Шмалак Павловского района Ульяновской области». Казань: Изд-во «Бриг», 2021. – 180 с.

Книга представляет собой первый опыт комплексного изучения истории и современной жизни села. Первое письменное свидетельство о существовании села в официальных русских источниках относится к 1651 г. Оно отражает вопросы имущественных отношений, что указывает на уже сложившиеся и длительное время существующие владения жителей села. Исходя из вышеизложенного, есть все основания заявить о не менее чем 400-летней истории с. Татарский Шмалак.

Вильданова Р.К. Симбирские татары. Книжная культура / Р.К. Вильданова. – Ульяновск: УлГУ, 2022. – 124 с.: ил.

К 300-летию со дня выхода первого печатного издания на татарском языке, Ульяновской областной татарской национально-культурной автономией, при поддержке Правительства Ульяновской области, была издана книга «Симбирские татары. Книжная культура» Р.К. Вильданова.

В книге собраны малоизвестные сведения периода XIX – начала XX вв., об истории книжной культуры татар края: рукописных и печатных книгах, типографиях, библиотеках, а также именах их организато-

ров. Даны сведения об уроженцах края, проживавших в Ульяновской области журналистах, поэтах и прозаиках.

Измайлов И.Л. Средневековые булгары: становление этнополитической общности в VIII – первой трети XIII в. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2022. – 736 с.; 16 с. ил.

Книга посвящена этногенезу булгар, становлению их, как этнополитической общности. Она предназначена как для историков, археологов, этнологов, так и широкого круга читателей, интересующихся историей предков татарского народа.

Редакция журнала по этой книге готовит большое интервью, которое будет напечатано в следующем номере. По мнению редакции, данная книга является послденим «гвоздем на гроб» булгаризма. Думается, что интервью раскроет до сих пор не изученные аспекты истории волжских булгар. Следите за нашим изданием.

МИЛЛИ АШЛАР, СӘЛАМӘТЛЕКНЕ САКЛАУ ЮЛЛАРЫ

НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ, ПУТИ СОХРАНЕНИЯ ЗДОРОВЬЯ

ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНА ХАС МИЛЛИ РИЗЫКЛАР

Татар халкы турында «тәмлетамак» дип әйтү бик дөрес булыр. Мәгънәләре охшаш булса да, сүз французларның «гурман»ына туры килеп бетми: француз ашчылары, затлы һәм оригиналь ризык әзерләп шаккатырыр өчен, аның ингредиентларын җир кырыеннан кайтарта, сазлыкта быкырдаган бака тотарга да күп сорап тормый. Ә безнең татар хатыннары хәзинәдә булган иң гади продуктлардан гына да ашап туймаслык ризыклар пешерә! Гурман ризыгын рестораннарда гына әзерлиләр, ә безнең милли ризыгыбыз – бәйрәм-кунак сые да, шул ук вакытта һәркем үз өендә пешерерлек көндәлек тәгам дә.

Әлеге гади һәм шул ук вакытта телне йотарлык тәмле ризыкларны мин 2022 елда Татарстан ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Пенза өлкәсе авылларына комплексны экспедиция вакытында язып алдым. Алар барысы да искиткеч оста куллар тарафыннан пешерелгән иде. Арада Казанда бөтенләй ишетмәгәннәре дә бар. Мәсәлән, арыш салмасы, якмыш, ат итеннән холодец. Ат итеннән холодец ясап булганы турында ишеткәнегез бар идеме? Минем дә юк иде. Гомумән, ат ите, башка төр итләрдән аермалы буларак, оешып кату үзлегенә ия түгел, дигән карашта тора идем. Ләкин Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылында ат холодецын үз күзем белән күреп кенә түгел, татып та карагач, элеккеге карашларым үзгәрде. Татар хатыннары бөтен нәрсәдән тәмле һәм затлы ризык ясарга сәләтле икән!

Пәрәмәчә (пәрәмәч) монда затлы да, көндәлек ризык та. Аны ат итеннән дә, сыер терлеге итеннән дә, кош ите яки мае кушып та пешерәләр. Әче камырдан да, төче (чечели) камырдан да. Майда йөздереп тә, мичтә (духовкада) кызартып та. Вариантлар – дистә түгел, йөзләгән булырга мөмкин! Ләкин бөтен пәрәмәчәнең уртак бер сыйфаты үзгәрешсез кала: аның эчлеге тарттырылган иттән булырга тиеш һәм эчлек куйган камырның уртасы 1–2 сум зурлыгында ачык калырга тиеш. Әлеге тишекне кайсы авылларда «күз», кайсыларында «авыз» дип атыйлар.

Пәрәмәчәне пешерү генә түгел, аны ашавы да үзенә бер сәнгать ул. Әйтик, Пенза өлкәсенең татар авылларында аны табынга май яки кай-

мак белән бирәләр. Пәрәмәчәне майсыз-каймаксыз, бөтен килеш кулына тотып ашаган кешегә «шәһәр урыслары шикелле итенмә әле» диләр. Чөнки монда пәрәмәчәне «күз» эченә акмай салып, камырын ваклап сындырып, һәр кисәген тагын майга яки каймакка манып ашыйлар. Тәмле-тамак димичә, тагын ни дисең инде мондый гурман халыкны?!

Майда кыздырып пешергән пәрәмәчә

Камыр: 1 литр сөт, 2 йомырка сарысы, 3 кашык семечка мае, 2 умар (уч) писук, тәменчә тоз, дураж, он. Он кулга ябышмаслык булганчы, озак изәбез. Каты булмасын, аның өчен онны күп салмыйбыз. Камыр 1,5 сәгать бүлмә температурасында тора. Эрелеп тулгач, басып төшерәбез, яңадан эрелә.

Эчлек: Фаршка 1 кг ит (атныкы яки бозаунык), тоз, борыч алабыз. Суган 2–3 баш (күбрәк булса, пәрәмәчә сусылрак була) мясорубкадан чыгартып кушабыз.

Пәрәмәчә ясыйбыз да уртача утта май эчендәикеягыкызарганчыпешерәбез.Пируд (башта) авызы белән аска каплап пешерәбез. Табаның капкачын капларга кирәк.

Караякова Лилия Кәрим кызы, педагог, авылның урта мәктәбе директоры, Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылы.

Чечели[1] пәрәмәчә

Камыр: 1 стакан катык, 2 йомырка, 1 чеметем тоз, 1–2 аш кашыгы писук, 2 аш кашыгы үсемлек мае, ярты бал кашыгы содага кирәгенчә он алып камыр изәбез. Өйдә йомырка булмаса, сытмасаң да ярый, ләкин йомыркалы камыр тәмлерәк. Соданы иң соңыннан өстәргә, ул катыкны сүндерә. Камырны йомшак кына басабыз. Кисәк-кисәк кискәч, түгәрәкләп җәябез дә әзер эчлекне салып чыгабыз, аннан өстен матурлап бөгәбез.

Эчлек: итне мясорубкада тарттырып, тоз, борыч өстибез. Суганны мин күп салмыйм, ит чыгартканда 1 баш чыгартып кушсаң да житә. (Пәрәмәчәне суган өчен түгел, ит өчен пешерәбез бит). Итнең майлырак жире кирәк, шулай иткәндә фарш сусыл була.

Духовкада кызарганчы пешерәбез.

Тактарова Алия Равил кызы, педагог һәм китапханәче, Пенза өлкәсе Каменка районы Мочалейка авылы.

[1] *– төче камырдан ясалган*

Яңа сауган сөткә изгән камырдан пәрәмәчә

Камыр: 0,5 литр яңа сауган сөт, 2 йомырка, дураж, тоз, оннан камыр изәргә. Кулга ябышмаслык итеп, 15 минутлап басарга. Йеслек (сөлге) белән каплап, өстәлдә 1 сәгать тоткач, әзер була.

Эчлек: фаршка 1 кг майлы ит алырга кирәк, (атныкы яхшырак). Суганны күбрәк алырга, 2–3 баш – ул пәрәмәчәне тәмлертә, итне дә йомшарта. Тәменчә тоз, борыч кушарга, йомшак булсын өчен фаршка ярты стакан чамасы сөт өстәргә кирәк. Майда пешерергә, башта күзле ягын аска таба каратып кыздырырга.

Бареева Арифә Әгъләм кызы, пенсионер,
Пенза өлкәсе Пачелма районы Решетино авылы.

Арыш ипие

Арыш оныннан ипи пешерер өчен башта ачыткы (закваска) ясыйлар.

Ярты стакан җылы суга 4 кашык шикәр комы, 30 г дураж (чүпрә) салып эретергә, аңарга 6–7 кашык арыш оны салып болгап, өстен марля белән ябып җылы урынга бер көнгә куярга. Ул әчерга тиеш. Аннан тагы 1–2 кашык су өстисең, бераз он, тагы болгап куясын. 1 тәүлектән ачыткы әзер була.

Камыр болай әзерләнә. Кичлеккә ярты литр эремчек суына ачыткыны салып 1 кашык коры дураж, 1 кашык шикәр салып арыш онына бераз бодай оны да кушып, апара (опара) ясыйсың. Ул коймакка ясаган кебек сыеклыкта булырга тиеш. Төн буе апара ачый, калка. Иртән аны басарга кирәк. Кирәгенчә тоз, әнис, он салып басарга озак кына кирәк. Тагын калдырып торасың 2 сәгатькә калкырга. Калыккач түгәрәк формасына китереп, җылы майлы табага салып бераз калктырып, өстенә йомырка сөртеп, әнис сибеп мичкә, я духовкага куясың 2 сәгатькә пешәргә.

Дубина Гөлнара Равил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылы.

Арыш салмалы ашти

1 стакан елы (җылы) су, ¼ пачка дураш (чүпрә), тоз бераз, иләгән арыш оныннан камыр изәргә. Бүлмә температурасында 1,5 сәгать ачытырга. Аны онга бәйләп (әвәләп), бераз катырырга морозильникка куярга.

Аннан алгач, кул белән тәгәрәтеп озынча колбаса кебек ясарга да пычак белән бармак башы кадәр кисәкләр кисәргә. Яки кул белән вак-вак кисәкләр-

гә өзгәләргә дә ярый. Аны кайнап торган итле шулпага берәм-берәм (ябышмасын өчен) салырга. Салманы эшти пешәргә 10 минут калганда салырга.

Баткаева Гөлнара Хәмзә кызы, мәдәният йорты хезмәткәре,
Пенза өлкәсе Каменка районы Кикин авылы.

Якмыш

Якмыш – кыстыбый (кыстрымбый, кыстымбый, күзикмәк һ.б.) ул. Дөресен генә әйткәндә, бу тәгамне һәр төбәк татарлары үзенчә атый, ләкин аның мәгънәсе, нигезе бер үк: камыр юка эченә кыстырган бәрәңге боламыгы яки тары боткасы.

Якмышны чечели камырдан пешерәләр. 2 стакан сөткә 2 кашык катык, 2 кашык семечка мае, 1 йомырка, 1 балкашыгы содага кирәгенчә он болгыйлар да камыр изәләр. Хәзер камырны кайнап торган суга да изәбез – эрелебрәк тә пешә, кетер-кетер итә торган була. Ул камырга 2 аш кашыгы семечка мае, тәменчә тоз, он болгыйбыз да сөт урынына 1 стакан кипяток салабыз. Камырны йомшак кына баскач, чәй тарелкасы кадәр түгәрәкләп җәябез. Әлеге җәймәнең калынлыгы чама белән 0,5 см булыр. Җәймәләрне ике ягын да май эчендә кызарганчы кыздырып алабыз. Кайнарлый җәймәнең яртысына, 2 аш кашыгы әзер бәрәңге боламыгын ягабыз («якмыш» сүзе дә шуннан килеп чыккан булса кирәк) һәм урталай бөкләп ике уч арасына куеп кысабыз.

Бәрәңге боламыгын әзерләүнең кыенлыгы юк, 1 кг бәрәңге алсак, анарга 1 баш суган турыйбыз, тоз салабыз да пешерәбез. Пешкәч, 100 г май, кайнаган сөт кушып изәбез.

Бибякова Дания Шәүкәт кызы, Утюшева Люция Әхәт кызы,
Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылы.

Ат холодецы

Алашаның муен, аяк сөякләрен суган, хуш исле борчак борыч, лавр яфрагы салып, ите сөяктән аерылганчы зур кастрюльгә салып пешерергә. Ит пешәр алдыннан тәменчә тозын саласың. Пешкән итне ит тарткычтан чыгарасың. Ит пешкән шулпаны марля аша сөзәсең. Пешкән, чыгарткан итне бульон белән кушасың. Күп бульон кушмаска кирәк. Куерак ясагач, алаша итеннән холодец тыгызланып ката. Сыер ите кушуның да, желатин өстәүнең дә һич кирәге калмый.

Канеева Румия Мөхәммәтхан кызы,
Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылы.

PS. Әлеге шәп рецептлар белән уртаклашкан ханымнарга рәхмәт әйтә-әйтә пешереп, тәмле итеп ашагыз!

Рузия Сафиуллина язып алды,
Алсу Борһанова фотолары.

ЮБИЛЯРЛАР ТУРЫНДА СҮЗ

СЛОВО О ЮБИЛЯРАХ

Б.Л. Хамидуллин

ОБ ОТЦЕ

Хамидуллин
Лирон Хайдарович
писатель, переводчик,
заслуженный работник
культуры ТАССР,
лауреат Государственной премии
Республики Татарстан
им. Габдуллы Тукая,
лауреат премий Министерства
культуры РТ им. Гаяза Исхаки и
Джамала Валиди.

Лирон Хайдарович родился 22 октября (по паспорту 10 ноября) 1932 г. в с. Старая Тюгальбуга Новомалыклинского района Ульяновской области в семье учителей. В годы Великой Отечественной войны вместе с мамой переехал в д. Старая Белогорка Новосергиевского района Оренбургской области. После окончания Старо-Белогорской семилетней школы в 1949 г. поступил в железнодорожный техникум в Актюбинске Казахской ССР. В 1951–1954 гг. служил в Советской Армии. После армии продолжил учёбу в техникуме и одновременно в 1955–1956 гг. руководил радиокружком в Доме пионеров Актюбинска. В 1956–1960 гг. работал бригадиром и старшим мастером путейцев в Орске Оренбургской области. Одновременно учился на вечернем отделении Орского филиала Всесоюзного политехнического института (окончил 4 курса) и двухгодичных курсах университета Марксизма-Ленинизма при Орском горкоме КПСС. С 1961 г. живёт в Казани.

Начиная с 1961 г. его литературные очерки и документально-публицистические статьи печатаются на страницах газеты «Татарстан яшьләре» и журнала «Азат хатын». Первые рассказы также были изданы в те годы в коллективных сборниках. В 1968 г. Лирон Хамидуллин издал собственный сборник рассказов «Юлда». С 1977 г. он член Союза писателей СССР. В 1967–1983 гг. – директор Татарского отделения Литературного фонда СССР, в 1985–1994 гг. – литературный редактор Татарского книжного издательства, в 1998–2005 гг. – научный сотрудник Института Татарской энциклопедии Академии наук РТ.

Лирон Хамидуллин является автором повестей «Дала иртәсе» («Степь пробуждается», 1972), «Офыктагы рәшәләр» («Миражи», 1990), сборников рассказов, повестей и очерков «Ак төннәр хәтере» («Белые ночи памяти», 2002), «Күңелдә калганнар» («Раздумья», 2007), «Кичке шәфәкъ» («Вечерняя заря», 2009), «Барыбыз да көрәштек» («Все мы воевали», 2010), «Буранлы төндә» («В метельную ночь», 2012), «Зарницы на горизонте» (2017), «Еpактагы ак җилкәннәр» («Белые парусники вдали», 2022), фотоальбома с биографическим очерком «Дэрдменд» (2003), документальных повестей «Зарница на небосклоне» (2009), «Дэрдменд» (2010), «Амирхан Еники» (2013), документальных очерков «Победа досталась дорогой ценой» (2015) и «Җиңү җиңел бирелмәде» (2015), ещё одного фотоальбома «Дэрдменд» (2019).

Активно занимался переводческой деятельностью: им изданы более десяти книг в переводе с казахского, каракалпакского, узбекского, русского и др. языков. В их числе: сборник повестей А. Алимжанова «Отрар хатирәсе» (1974), повести и расказы С. Муратбекова «Әрем исе» (1986), роман А. Мухтара «Чинор» (1976), повесть В. Быкова «Һәйкәл» (1984), документальные очерки З. Гильманова «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» (1989), повесть А. Капустина «Беренче җиңүләр» (1995), роман Я. Хамматова «Бөртекләп җыела алтын» (1996).

Государственная премия Республики Татарстан им. Габдуллы Тукая присуждена Лирону Хамидуллину в 2020 г. за книги «Дәрдемәнд/Дэрдменд» (на татарском и русском языках), «Буранлы төндә» и «Зарницы на горизонте».

Награжден медалью «В память 1000-летия Казани», Почётными грамотами Литературного фонда СССР, Академии наук РТ и Министерства культуры РТ, Благодарственными письмами Председателя Государственного Совета РТ и Президента Республики Казахстан.

Рәшит Минһаҗ

МИЛЛӘТ ХӘДИМЕ

Шушы көннәрдә Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитетының Аксакаллар Шурасы рәисе, башкалабыздагы «Милләт йорты» хуҗасы Рәүф Йосыф улы Хәсәновка 70 яшь тулды.

Тәвәккәл, төпле, булдыклы кеше ул. Моннан дистә ел элек туып үскән Башкортстанын, ныклы нигез корган Бәләбәен калдырып килде дә, Казанда яңа тормыш башлады Рәүф ага. Хәер, аның күчеп килүе берничә елга сузылды.

Оя кормыйча күчеп булмый ич инде, дип ул әүвәл Нариманов урамындагы шактый мөшкел хәлгә килгән борынгы типография бинасын сатып алып төзекләндерде, ишле гаиләсе өчен Кабан күле буенда шәп йорт өлгертте. Безнең халык гадәттә кеше кесәсендәге акчаны санарга ярата. Акчасын кайдан тапкан дисезме? Бәләбәй механика заводы хуҗасы ул.

Инженер-механик белеме алган Р. Хәсәнов – озак еллар җитәкче эшләрдә эшләгән шәхес. Магистраль нефть торбалары эшчәнлеген тәэмин итү, банкротлыкка чыккан кирпеч заводларын аякка бастыру... Оештыру, җитәкчелек итү сәләте булмаса, Башкортстан хакимиятләре аны мондый җаваплы вазифаларга куймас иде. Бөлгенлеккә төшкән Бәләбәй механика заводын сатып алып нефть эшкәртү, авыл хуҗалыгы тармакларына кирәкле җиһазлар җитештерүне дәвам иттерүе дә – Ходай биргән оештыру сәләтен, зиһенен бер йодрыкка туплый алуы.

Рәүф әфәнде кайда гына хезмәт куймасын, мәктәптә татар сыйныфлары бармы, мәчет салынганмы, эшлиме, дип кызыксынып торды һәм шунда милли, дини гыйлем бирүне җайга салуга өлеш кертте. Алай гына да түгел, Күгәрчен районы үзәгендә, туган ягында – кендек каны тамган Җидегән авылында, район үзәге Миякәдә Аллаһ йортын салдыруны шәхсән башлап йөрсә, мәчет төзибез, булышмассызмы, дип мөрәҗәгать итүчеләрнең берсен дә нәүмиз калдырмады. Җитәкче кешегә моның ние бар инде, дип әйтергә ашыкмагыз. Әллә ни кадәр мал-мөлкәте булып, затлы кәнәфидә утырып та, милли мәгарифебезне үстерүгә, дин-әхлак тәрбиясен җәелдерүгә сукыр бер тиенен дә кызганганнар аз түгел. Аларны замандаш дип була, шәхес дип әйтергә тел әйләнми.

Алдарак Рәүф ага борынгы типография бинасын төзекләндерде дигән идек. Төзекләндерү эшләрен бетерүгә, ул аны «Милләт йорты» итеп ачып җибәрде. Хәзер милли мәгарифебезне, мәдәниятебезне, динебезне кайгыртуга багышланган бик күп чаралар шунда уздырыла. Татар конгрессы җитәкчеләренең Башкарма комитет каршында Аксакаллар Шурасы оештыруы, аның рәисе итеп Рәүф ага Хәсәновны тәгаенләүләре – аңа ышанулары, кылган гамәлләрен танулары, югары бәяләүләре нәтиҗәсе.

Адәм баласы даими гыйлем эстәп торырга, бер дә тукталмаска тиеш. Белем җыйган саен яшәү матурая, иман камилләшә, күңелдә нур – иман нуры барлыкка килә. Күңелдәге шул нурны сүндермичә, Аллаһ белән араны төзек тоткан кеше бхетле, – дип әйтергә ярата юбилярыбыз. Әйткән сүзенә тугры калып, ул башта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә сабак алды, иншалла, быел язын Россия Ислам университетының Шәригать факультетын тәмамлаячак.

ХУШЛАШУ

НЕКРОЛОГ

Рәшит Минһаҗ

БЕР ГАЛӘМ СҮНДЕ

Бер галимнең үлүе бер галәмнең бетүенә бәрабәр, дигән акыл иясе. Мөгаен, бу гыйбарәне гыйлем әһелләренең барысына карата да әйтеп булмыйдыр. Әмма филология фәннәре докторы Йолдыз Галимҗан кызы Нигъмәтуллина нәкъ менә шундый галимнәребездән иде. Ни кызганыч, «иде» дип әйтергә туры килә.

Бүген, җомга көнне мәрхүмәне башкалабызның Яңа татар бистәсендәге Иске татар зиратында, әнисе янында җирләп кайттык.

Әгәр исән булса, тагын өч айдан, төгәлрәге 29 нчы апрель көнне аңа 94 яшь туласы иде.

Әтисе, әдәбият галиме Галимҗан Нигъмәтинең тикшеренү-эзләнүләрен дәвам итеп, Йолдыз ханым әдәбиятларны системалы-комплекслы анализлау мәктәбе булдырды. Ни кызганыч, Казаныбызда шушылай үз фәнни мәктәбен булдырган, аны СССР күләмендә генә түгел, Европа күләмендә таныткан башка әдәбиятчы галимнәр күренми. Аның методын корал итеп алып, әдәбиятчы галимебез Альберт Яхин «Татар фольклоры системасы» хезмәтен язды. Соңрак Альберт ага фольклорчы гына түгел, татар әдәбияты методисты буларак та танылды. Аның I сыйныфтан алып XI сыйныфка кадәр язылган яңа төр татар әдәбияты дәреслекләре – шушы методология җимеше. Ни кызганыч, соңгы елларда Татарстан Мәгариф министрлыгы бу дәреслекләргә заказ бирүдән туктады.

Әдәбият белеме, фәлсәфә, математика, психология фәннәре, музыка, кино, рәсем сәнгате – менә шушындый төрле тармакларның чатында, киселешендә туган алым-ысул ул – системалы-комплекслы анализ. Берничә ел элек Мәскәүдә уртачыл мәдәниятне (серединная культура) өйрәнүгә

багышланган, шушы ысул нигезендә язылган бер җыентык дөнья күрде. Татар фольклорының бер тармагы булган мәкальләрне өйрәнеп язган мәкалә белән анда миңа да катнашу насыйп булды. Дөнья халыклары мәдәниятләрендәге уртак моментларны өйрәнеп, игътибар үзәгенә чыгарып күрсәтүне максат итеп куйган үтә гуманлы проект бу. Шушындый уртак, берләштерә торган хасиятләребез күбрәк табылган саен, җир йөзендә сугыш учаклары кабыну ихтималы азаер иде. Уртачыл мәдәниятне табу, барлау юнәлешендә тагын бер проект борынлап килә, анда КФУдан, урыс әдәбияты кафедрасыннан Алексей Пашкуров, Швециядән тагын бер филология фәннәре докторы, Йолдыз ханымның күптәнге шәкерте Ирина Данилова, Татарстан китап нәшрияты мөхәррире, язучы Галимҗан Гыйльманов, Алабугадан рәссам Хәмзә Шәрипов, тарих фәннәре докторы Энгель Таһиров чакырылган иде. Татар мәкальләрен тагын да тирәнрәк өйрәнеп мәкалә язу миңа тапшырылды. Безгә юнәлеш биреп торучы, кайдан нәрсә эзләргә кирәклеген әйтеп торучы Йолдыз апа… Инде белмим, нәрсә килеп чыгар?!

Биредә Йолдыз апаның шәхси сыйфатлары – кунакчыллыгы, ярдәмчеллеге, шәкертләренә гаять игътибарлы булуы турында аерым язып булыр иде. Анысын башка вакытта, дип язмабызны тәгәллик. Каберең – якты, рухың шат булсын, остазыбыз!

ПАМЯТИ
Профессора, Заслуженного деятеля Науки Татарстана
ЮЛДУЗ ГАЛИМЖАНОВНЫ НИГМАТУЛЛИНОЙ

2 февраля 2023 г. ушла из жизни выдающаяся женщина, преданно служившая науке и воспитавшая несколько поколений литературоведов – специалистов в уникальном, сложном комплексном анализе художественных произведений в контексте культурного развития.

Сформулированные ею идеи литературного и культурного развития обогатили литературоведение, типологию культурного развития, философию искусства. Самыми ценными и значительными стали идеи и разработанные ею методы:

- Системного комплексного изучения художественных произведений на основе многоуровневой модели (1975–1985), создания единой модели критериев художественности на основе обобщения существующего опыта их изучения, а также изучение типов творчества и типов художественного мышления (1980–1985);
- прогностического изучения русской и татарской литератур, живописи, светомузыки, архитектуры и театра в едином художественном процессе конца XX в. (1985–1990);
- прогнозного картографирования как метода изучения становления, функционирования и взаимодействия в литературном процессе, а также воздействия художественных произведений на читателей (1990–2010);
- типологического изучения культур на фоне цивилизационного развития (1995–2000);
- изучения образного языка модернизма и постмодернизма в литературе и живописи в контексте национальной и мировой культуры (2000–2005);
- введения общенаучного синергетического подхода в практику изучения художественного процесса и творчества отдельного художника (1990–2010).
- изучения срединной культуры как синергийного явления, сохраняющего ценности культуры и примиряющего противоречия, крайности культурного развития в разнообразных измерениях от конкретного произведения до общемирового процесса (2012–2023).

Такое подробное перечисление этапов научного пути Ю.Г. Нигматуллиной необходимо, потому что идеи предыдущих этапов научного творчества становились основой последующих открытий. Таким образом шло постоянное усложнение и укрупнение масштаба понимания и анализа художественных, культурных, цивилизационных процессов. Хотя

идеалом учёного была простота выражения самой сложной мысли, но без упрощения идей.

На протяжении всей жизни в науке и в преподавании сформировалась уникальная школа Ю.Г. Нигматуллиной, главным принципом развития которой был и остаётся синтез предыдущих и последующих концепций, преемственность этапов исследования и осуществление индивидуального вклада каждого участника в общее дело.

Благодаря существованию этой школы, перед нами открыт путь глобального изучения культурных процессов прошлого и современности, возможность синтеза разных слоёв и уровней культуры, самоорганизации культуры в контексте цивилизационного развития (или деградации цивилизации), осуществление срединной культурой определенной роли в преодолении тупиков нравственного и творческого развития человечества.

Движение по этому пути нам завещано Великим учителем и будет продолжено!

Ученики, коллеги, единомышленники Ю.Г. Нигматуллиной.

АВТОРЛАР БУЕНЧА БЕЛЕШМӘ

Әхмәтҗанова Гөлсәрия Рифкать кызы, Россия ислам институтының редакция-нәшрият бүлеге җитәкчесе.

Бакиева Рәшидә Корман кызы, РФ Атказанган укытучысы.

Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

Борханов Альберт Әхмәтҗан улы, тарих фәннәре кандидаты, профессор, Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте Советы рәисенең беренче урынбасары.

Бугарчёв Алексей Игорь улы, ТФАнең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының тикшерүче-лаборанты.

Галләмова Әлфия Габделнур кызы, тарих фәннәре докторы, ТФАнең Ш. Мәрҗани ис. Тарих институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

Гарипова Хамида Лотфулла кызы, педагог-журналист, тәрҗемәче, ТР Журналистлар берлеге әгъзасы.

Гарифуллин Илнар Зөлфәт улы, тарих фәннәре кандидаты, политолог, БТЯФ идарә әгъзасы.

Даутова Энҗе Нурмөхәммәд кызы, төбәк тарихын өйрүнүче, тарихчы.

Исхаков Дамир Мәүләви улы, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, журналның баш мөхәррире.

Кадыйров Илгиз Шәфикъ улы, татар фольклорын тикшерүче, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Камалиева Ләлә Разак кызы, төбәк тарихын өйрәнүче.

Койлакаев Алибек Байморат улы, рәссам.

Минһаҗев Рәшит Рәкыйп улы, журналист.

Мөхәмметҗанова Лилия Хатип кызы, филология фәннәре докторы, доцент, ТФАның Г. Ибраһимов исемендәге ТӘСИның баш фәнни хезмәткәре һәм Гыйльми советы әгъзасы.

Нигъмәтҗанов Томас Тимерхан улы, ТР һәм РФ Журналистлар берлеге әгъзасы, «Теплоконтроль» АҖ Казан приборлар төзү предприятиесе баш метрологы.

Поливанов Евгений Дмитрий улы, профессор, Көнчыгыш телләр магистры, лингвист, шәрыкъ һәм әдәбият белгече.

Раянов Мәгариф Шәйхмулла улы, төбәк тарихын өйрәнүче.

Сафиуллина Рузия Фәһим кызы, филология фәннәре кандидаты, ТФАнең Г.Ибраһимов исемендәге ТӘСИның Халык иҗаты бүлеге хезмәткәре.

Таҗиев Дамир Нәзир улы, Россия журналистлар берлеге әгъзасы, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге бүләк иясе, Әлмәт төбәгенең җәмәгать эшлеклесе, туган як тарихын өйрәнүче.

Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы, тарих фәннәре кандидаты, РФА УрБның Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

Фәйзуллина Нэля Әсхәт кызы, Ямбай авыл музееның фонд караучысы.

Хәмидуллин Лирон Хәйдәр улы, язучы, тәрҗемәче. ТАССРның Атказанган мәдәният эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Хәмидуллин Булат Лирон улы, тарих фәннәре кандидаты, ТФА Татар энциклопедиясе институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге мөдире.

Шаһиева Розалина Гомәр кызы, сәнгать белгече, шагыйрә, тәрҗемәче, рәссам. ТР Атказанган сәнгать эшлеклесе.

Ярхамов Илнур Ирнис улы, журналист, «Туган җир. Родной край» журналының web-редакторы.

СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРАХ

Ахметьянова Гульсария Рифкатовна, руководитель редакционно-издательского отдела Российского исламского института.

Байрамова Фаузия Аухадиевна, кандидат исторических наук, писательница, общественный деятель.

Бакиева Рашида Кормановна, Заслуженный учитель РФ.

Бугарчев Алексей Игоревич, лаборант-исследователь Института археологии им. А.Х. Халикова АН РТ.

Бурханов Альберт Ахметжанович, кандидат исторических наук, профессор, первый заместитель председателя Совета ВОК.

Галлямова Альфия Габдульнуровна, доктор исторических наук, ведущий научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

Гарипова Хамида Лотфуловна, педагог-журналист, переводчица, член союза журналистов РТ.

Гарифуллин Ильнар Зульфатович, историк, политолог, кандидат исторических наук, член Совета ВФТМ.

Даутова Энжи Нурмухамедовна, краевед, историк.

Исхаков Дамир Мавлявеевич, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, главный редактор журнала.

Кадыров Ильгиз Шафикович, исследователь татарского фольклора, заслуженный работник культуры РТ.

Камалиева Ляля Разаковна, краевед.

Койлакаев Алибек Баймуратович, ногайский художник.

Мингазов Рашит Ракипович, журналист.

Мухаметзянова Лилия Хатиповна, доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник, член ученого совета Института ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Нигаматзянов Томас Тимерханович, член Союза журналистов РТ и РФ, главный метролог Казанского приборостроительного предприятия АО «Теплоконтроль».

Поливанов Евгений Дмитриевич, профессор, магистр восточной словесности, лингвист, востоковед и литературовед.

Раянов Магариф Шайхмуллович, краевед.

Сафиуллина Рузия Фагимовна, кандидат филологических наук, сотрудник Отдела народного творчества ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Тазиев Дамир Назирович, краевед, член Союза журналистов РФ, лауреат премии имени Рафаила Тухватуллина, общественный деятель.

Тычинских Зайтуна Аптрашитовна, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

Файзуллина Нэля Асхатовна, хранитель музейных фондов Ембаевского сельского музея МАУ ТМР «ЦКиД «Юность».

Хамидуллин Лирон Хайдарович, татарский писатель и переводчик, заслуженный работник культуры ТАССР, лауреат Госпремии РТ имени Габдуллы Тукая.

Хамидуллин Булат Лиронович, кандидат исторических наук, заведуюущий Центром изучения татарской диаспоры Института татарской энциклопедии АН РТ.

Шагеева Розалина Гумеровна, поэтесса, переводчица, художница, искусствовед. Заслуженный деятель искусств РТ.

Ярхамов Ильнур Ирнисович, журналист, web-редактор журнала «Туган җир. Родной край».

ИНФОРМАЦИЯ ДЛЯ АВТОРОВ

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает что к публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

Рекомендуемая тематика публикаций:

- *методика и методология историко-краеведческих исследований;*
- *история краеведения и историко-краеведческое наследие;*
- *проблемы региональной истории;*
- *новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;*
- *публикация источников;*
- *история конкретных сел и деревень;*
- *история музеев и публикация музейных коллекций;*
- *жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;*
- *использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;*
- *популярные статьи по краеведению;*
- *краеведческая хроника (конференции, встречи и т. д.);*
- *рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.*

Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:

Технические требования к оформлению статей

1. Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом [Аминов: 2017. С. 82.]; [Денисов: 2012. С. 25; Черкас: 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф. 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л. 6.]

2. Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

Источники и литература

1. Аминов Р.Р. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.
2. Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.
3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.
4. Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.
5. Черкас Т.Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***Редакционные требования к оформлению**:*

Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате .doc или .docx;
2. А4;
3. Поля: слева – 3 см., справа – 1,5 см. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа;
4. Шрифт – Times New Roman;
5. Размер шрифта – 14;
6. Межстрочный интервал – 1,5;
7. Абзацный отступ – 1,0.

Требования к иллюстративным материалам:

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п. л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

Сведения об авторе:

1. Фамилия, имя, отчество ____________________
2. Ученая степень ____________________
3. Ученое звание ____________________
4. Занимаемая должность ____________________
6. Почтовый адрес с индексом ____________________
7. Адрес электронной почты (e-mail) ____________________
8. Контактный телефон ____________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии она в случае соответствия всем требованиям передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для приведения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Авторам выплачивается гонорар. Для этого необходимо вместе с материалом прислать сканкопии паспорта, ИНН, СНИЛС, счет со всеми банковскими реквизитами.

Электронная версия журнала размещается на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул. А. Пушкина, 52, офис 303, редакция журнала «Туган җир/Родной край»

Туган җир

Төбәк тарихы буенча журнал

Родной край

Краеведческий журнал
1’2023

Подписано в печать 12.03.2023 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 999 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов

В.Г. Шәйхразиев Ижау шәһәрендә ИФО татар иҗтимагый оешмалары җитәкчеләре очрашуында. 2023 елның 13 гыйнвары.

«Фәезханов укулары». Түбән Новгород өлкәсе Пилнә районы Сафаҗәй авылы. 26 гыйнвар 2023 ел.

Киров өлкәсенең Слободской районындагы Нократ авылы китапханәсенә БТК Башкарма комитеты исеменнән нукрат татарларына этномәдәни экспедиция барышында китаплар тапшыру.

РАЕН вице-президенты, академик И.Р. Үтәмешевка, Казан шәһәренең 80 нче номерлы Каюм Насыйри исемендәге татар-рус мәктәбе директоры Р.М. Мансуровка һәм аның коллективына актив фәнни-педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен БТК исеменнән Рәхмәт хатлары тапшыру.

БТК грамоталары белән Д.М. Исхаков укучылары Зәйтүнә Тычинских һәм Гөлүсә Зиннатуллина бүләкләнә. 2023 елның 21 феврале.

Д.М. Исхаковның Милли дастаннар елы уңаеннан Тубыл шәһәре татар җәмәгатьчелеге белән очрашуы. 2023 елның 20 феврале.

«Туган җир» журналының баш мөхәррире «Шаян ТВ»да балалар белән очрашуда. 27 гыйнвар 2023 ел.

Свердловск өлкәсенең Каменск-Уральск шәһәре татар һәм башкорт мәдәнияте «Дуслык» ансамбле. 2023 елның 14 гыйнвары.

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

BÖTENDÖNYA TATAR KONGRESSI
ВСЕМИРНЫЙ КОНГРЕСС ТАТАР

МИЛЛИ ДАСТАННАРЫБЫЗ ЕЛЫ
2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ ДАСТАНОВ

«ИДЕГӘЙ» ДАСТАНАНДА АНА ВАТАННЫ ТАСВИРЛАУ

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,

Атам кияү булган йорт –
Иелеп тәзем кылган йорт.

Анам килен булган йорт –
Иелеп сәлам әйткән йорт;

Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт;

Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;

Идел-Җаек арасы
Елкы белән тулган йорт,

Казан-Болгар арасы
Кала белән тулган йорт;

Ашлы белән Ибраһим
Ашлык белән тулган йорт,

Ата-бабам тоткан йорт,
Котлы булсын туган йорт!

Алибек Койлакаев рәсеме.